Безнең Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

02

февраль 2019

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ӘНӘС ТУМАШЕВ «БӘСЛЕ КӨН».

Фотолар tatar-congress.org сайтыннан алынды

Милләтебезнең үсеш стратегиясе

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев гыйнвар ае дәвамында Арча, Нурлат, Бөгелмә, Чаллыда татар активы һәм Казан шәһәрендә зыялылар белән очрашып, «Татар халкының үсеш стратегиясе» буенча фикер алышу оештырды, тәкъдимнәрне барлады.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас 12 +

02 (302)

февраль 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

9

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Мөхәммәдьяр**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Төрки халыкларның гомуми тарихы.** *Х.Габәши*
9 **Сәгыйдь.** *Ризаэддин Фәхреддин*
16 **Бер ай частьта.** *Г.Баембәтов*
22 **Татарстанның бишьеллык бәйрәме көнендә**
25 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**
26 **Саралы мең ыруы татарлары.** *Р.Мәрданов*
32 **Мәрҗани ул – Тимерказык!**
36 **«Милләтне без тергезик!»** *Г.Төхфәтова*

ТАТАР ГАМЕ

42 **Без – мираслы халык!**
46 **Чын галимнең сүзе калыр, җуелмас эзе калыр.** *Ф.Җәүһәрова*
50 **Игелекле ханым.** *Р.Зәйдулла*

ДИНИ МИРАС

56 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

62 **Башкорт кызы.** *Х.Сарьян*
72 **Безнең тарих белән кызыксыну арта.** *Л.Хәмидуллин*
74 **Исемле кошлар хуҗасы.** *А.Хәлим*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

78 **Уттан сау чыккан хәтер-хатирә (Фронтовик этием язмалары).** *Р.Мәһдиев*
84 **Әфган дастаны (бәяннан өзек).** *М.Закир*
92 **Нәбиулла солдат кыйссасы**
96 **Истә, һаман да истә!**



26 **САРАЛЫ МЕҢ ЫРУЫ ТАТАРЛАРЫ.**
Рәиф Мәрданов

98 **БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ.**
Ринат Гыйләҗев

СӘНГАТИ МИРАС

98 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

104 **Сүзләр иленә сәяхәт (Лингвистик хикәятләр).** *Г.Рәхим*
108 **Челлә, чиләк һәм челтәр.** *Р.Сафәров*

ХӘТЕР САГЫНДА

110 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
114 **Хотня авылындагы намаз йорты һәм кәшәнә**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Февраль*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89520365448,
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №О-160. Тираж – 1500 данә. Формат 70х108 1/16.
Басарга кул куелды: 28.01.2019.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иреклe.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Ә.Тумашев рәсемнәре – ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Бәсле көн»** (фрагмент). 1972. ***Әнәс Тумашев рәсеме***

Мөхәммәдьяр

(1496 (1497)-1549)

***

Чын кеше шул – сүз гәүһәрен кем сачар,
Бу – мәсәл бер: начар асылыннан качар.

***

Акыллы ир: мин – олы, дип мактанмас,
Андый затта тәкәббер, кинә булмас.

***

Борынгыдан калган мәсәл – колак сал:
«Яманнан син муеныңны сатып ал».

***

Бер нәсыйхәт бирим сиңа, колак сал:
«Иясен сыйласаң, этенә сөяк сал».

***

Аңың булса, иргә итмә явызлык:
«Кое казып – үзе төшкән», – ди халык.

***

Ир дип аталганга – батырлык кирәк.
Галим һәм гадигә юмартлык кирәк.

***

Юлга җитәкчесез атлама ары,
Башта юлы һәм үзе бетәр ары.

***

Борын чөеп, мин-минлекне сатмагыз,
Онга – кибәк, серкәгә су катмагыз.

***

Туйдыр икмәккә кешене, данлы зат,
Мәңге калыр бу җиһанда яхшы ат.

***

Сабыр белән кеше теләккә җитәр,
Сабыр белән кайгыны шатлык итәр.

***

Гафу итү – ир-егетнең ул даны,
Аның бер даны – башканың мең даны. ■

ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ГОМУМИ ТАРИХЫ

Хәсәнгата Габәши

Хәсәнгата Габәши

Мөәллифләр[1] вә мосанниф-лар[2] әсәрләрендә бәхәс итәчәк гыйлемнәрне кавем-милләт йә гомумән адәм угыллары өчен дәрәҗәләренә күрә «файдалы», «кирәкле», «бик кирәкле», «ансыз чара юк», дип бүлерләр. Күп вакыт моны күрсәтергә вә исбат итәргә тырышырлар. Дөрестән дә, гыйлем – «белек вә белмәк» булганлыгыннан, һичкаюсы файдасыз вә кирәксез түгелдер. Белгәннәр илә белмәгәннәр бер үк булырмы? Һәрнәрсәне белмәүдән, әлбәттә, белү артыктыр. Гыйлем – яктылык, нур, белмәү – караңгылыктыр. Ялгыз бер шарты бардыр ки: укуда кирәклеге җәһәтеннән тәртибен игътибарга алып, урынында файдалану кирәк. Болар исә һичкем инкарь итмәслек бик иске хакыйкатьләрдер. Әмма гыйлем бик күп төрле булганлыгы кебек, кавемнәр-милләтләр вә боларның гыйлемнәргә ихтыяҗ нисбәтләре дә шулкадәр төрле-төрледер. Заман вә әхвәл алышыну илә дә бу нисбәтләр алышынмышлар: берзаман вә бер әхвәл теләве буенча файдалы дәрәҗәсендә булган гыйлем, икенче заман вә икенче әхвәл теләве буенча зарур дәрәҗәсенә күтәрелер, киресенчә дә булыр.

Мин дә, мөәллифләр кеби, ошбу әсәремдә вә моның яңа гына бастырылган «Мохтәсар»ендә бәхәс иттегем тарих гыйлемен кавемнәрнең сәламәт вә сәгадәтләре өчен бик кирәк вә зарур, дип беләмен һәм алар, (мөәллифләр) гадәтенә ияреп, моны күрсәтергә вә исбат итәргә тырышамын. Бу урында янә бер-ике сүз әйтеп, ачыграк күрсәтер өчен, бер мисал да китерәмен: үсемлекләрнең терек яшәүләренә туфрак, тамыр вә гәүдә, тармак, яфрак, су кирәк булган кебек, һава илә кояш та кирәк.

[1] Мөәллиф – китап язучы, китап төзүче.
[2] Мосанниф – әсәр язучы.

Әүвәлгеләренең кирәге аз гына күрү вә сынау илә мәгълүм булса да, соңгыларының (һава илә кояш) кирәге ул кадәр җиңел беленми, бәлки байтак гыйлем вә тәҗрибә соңында гына беленәдер.

Инде безләр дә бер заманга килеп җиттектә, бу заманда гыйлемнәрдән бәгъзеләре милләтләр-кавемнәрнең терек яшәүләренә бигрәк тә кирәк. Болардан кайберләренең кирәге күрү вә санау илә дә беленер. Әмма бәгъзеләре байтак гыйлем вә тәҗрибә вә сынау илә генә беленәләр. Кавемнәрнең сәламәт вә сәгадәтләренә һава илә кояш нисбәтендә зарур гыйлемнәрдән бере дә – ошбу тарих гыйлемедер.

Тарих гыйлеменең кирәге вә заруратьы ошбу дәрәҗәдә идеке бик иске заманнан бирле гыйлем әһелләренә озак сынау вә тәҗрибә соңында шиксез беленә килмештер. Шуның өчен тарих гыйлеме бик искедән бирле төрле кавемнәрнең олуг галимнәрен үзе илә шөгыльләндерә килмештер. Шулай ук әһле исламның да имам вә голәмәсе, бөтен галәмгә әсәрләре илә мәшһүр булган олуг галимнәре вә чиксез күп мөәллифләре бик иске заманнан ошбу яңа вакытларга кадәр тарих илә шөгыльләнмешләрдер. Ислам голәмәсе ошбу гасырыбызга кадәр төрле телдә ике меңгә кадәр тарих китабы язмышлардыр.

Тарих гыйлеме искедән бирле ошбу дәрәҗәдә икән, ни сәбәптәндер, безнең кавемебез – Русия төрекләре эчендә бу көнгә кадәр үзенә тиешле урынны ала алмамыштыр. Төрек телендә тарих бик аз язылмыштыр. Соңгы заманнарда исә моның илә шөгыльләнмәк голәмәгә ятышмас бер эш хисап ителмештер. Бу сәбәптән, сыйныфым, тәрбиям хисаплы, моның илә шөгыльләнмәк миңа тиеш, лаек түгел, имеш, әллә кайчан булып беткән искеләр, үтеп киткән заманнар хәлен тикшерү илә газиз гомерне әрәм итү һич тә тиешле түгел, имеш, кеби күп нәсыйхәтләр ишетмеш идем. Дөрестән дә, бетмәс-төкәнмәс иске китаплар, иске әсәрләр илә шөгыльләнү вә аларга якынрак булу өчен, төрле телдә бик күп том китаплар уку, сарыф ителмеш вакыт, түгелмеш күз нурына нисбәттә болардан алынмыш тарих, милләтебез өчен кирәкле мәгълүмат аз вә бәгъзесеннән бер дәрьядан бер тамчы нисбәтендә булмак мине гаҗиз итәр, җанымны хәсрәтләндерер иде. Бик олуг тарих язар өчен сарыф ителмеш унике ел гомерне күпсенүчеләрне күрдегемдә, минем кечерәк кенә тарих язар өчен дә моннан артыграк газиз гомер сарыф итүем янә бәгъремне яндырыр, канымны кайнатыр иде.

Югарыда әйтелгәнчә, ислам голәмәсеннән (иске вә яңа) бик олуглар бу гыйлем (тарих) илә шөгыльләнеп, аларның да юнан, һинд, фарсы, яһүд, франк, чин телләрендә язылган китаплардан файдаланганнары, кайберләренең бер тарих язар өчен егерме бишәр ел гомер сарыф итүләре миңа яхшы үрнәк булып, мине юатырлар иде. Бу аз-аз мәгълүматлар бере янына бере килеп, байтак әхвәлебезне ачулары вә берәр-берәр тамчылар бере янына бере җыелып, кавемебез, милләтебез йөзенә ягылган пычракларны юарга җитәрлек кадәр булуы һәм дә тычкан уты кеби зәгыйфь нурлар бергә кушылып, кавемебез-милләтебезнең асыл тамырларына вә башка әхвәлләренә капланып, караңгылыкны җибәрер вә яктыртыр кадәр булуы хакыйкать! Болар мине шатландырыр вә гайрәтемне дә арттырыр иделәр.

Кичәге көн кавемебез-милләтебез карамагында хикәят вә әфсәнәләр вә кирәкмеш саналмыш тарихның тиз көнннән кирәкле гыйлем вә фән саналачагы (галәмәтләре күренгәне өчен) куәтле, дип өмет итәр идем. Дөрестән дә, тиз көннән: «Тарих! Тарих кирәк!» – өндәүләре вә таләпләре ишетелә башлады. Минем бу фән илә шөгыльләнүемнән хәбәре булган карендәшләрем, күрешеп сөйләшү вә хатлар, хәтта журналлар ярдәме илә миңа мөрәҗәгать итеп, мине тарих язарга ашыктыра башладылар. Мин дә боларның сүзен җиргә салмас өчен һәм дә күпне күтәреп аздан

да мәхрүм итү куркусы булганы өчен, мәгълүматым һаман да аз, тикшерүләрем һаман да камил түгел идекен танып та кулыма каләм алдым. Бик кирәкле дип санаган мәгълүматны бер көн әүвәл булса да карендәшләрем илә уртаклашуны ният итеп, ошбу «Тарихе кавеме төрки» исемендә рисалә яздым вә нәшеренә керештем. Аллаһ безгә тәмам итүне вә карендәшләремә файдалануларын насыйп әйләсен. Амин.

***

Мөәллиф вә мосаннифның бер билгеле максатлары һәм тәртипләрендә тоткан бер юл вә мәсләкләре була. Минем дә ошбу рисаләне язуымнан бер максатым бардыр ки, ул да кавем вә карендәшләребезгә үз ата-баба вә карендәшләрен, ватан вә аларның әхвәлен дөрес вә тугры белдермәктер, вә бу китап илә бөтен галәм тарихчылары җыелышып эшли торган «Тарих фәне» бинасына бер таш салмактыр. Тоттыгым юл вә мәсләк исә ошбудыр: 1) Язган мәгълүмат кем агызыннан ишетелсә дә ишетелсен, кирәк кайсы заманда, кирәк кем тарафыннан язылса язылсын, заманына, шәхесенә вә башкасына карамый, ялгыз хак вә тугры булуына гына күз тотып, көчем җиткәнчә тикшергәннән соң, үзем хак күрдекләремне генә яздым. Шулай да, үземнең аз гыйлемле, хата вә ялгышлардан хали булмаган адәм икәнемне һич онытмадым. 2) Язганнарымны сәяси, милли, шәхси, сыйнфый фанатизмнардан азат итеп, һичкемне кире какмадыгым вә рәнҗетмәгәнем кеби, һичкемгә тарафдарлык та итмәдем. Бәлки салкын кан илә яздым. Язылмыш тарихлардан бәгъзеләренең ошбу хосусларның бере илә гаепләнгән булулары миңа яхшы гына сабак булды. Дөрестән дә, хакыйкать янына янә бер максат катышса, хакыйкать үз хәленчә генә чыкмыйдыр. 3) Мәгълүмдер ки, һичбер фән-гыйлем голәмәсе каршы фикердән котылмадыгы кеби, тарих та моннан котылмады. Тарих голәмәсенең төрле сүзләрен вә төрле фикерләрен язмак илә укучыларның башын әйләндерми, бәлки мизаныбызның куәте җиткәнче, хак күргәннәремне генә алып яздым. Бу сәбәптән, язганнарымның кайберсе бәгъзе китапларга вә бәгъзе фикерләргә, әлбәттә, туры килмәячәк. Бу хосуста мине гафу итсеннәр. 4) Язылмыш мәгълүматым авторлары тарих голәмәсе арасында мәшһүр булганлыктан, исемнәрен язуны хаҗәт күрмәдем. Әгәр мәшһүр булмаса, ул вакыт яздым. Әгәр хосусый үз дәлилем вә фикерем булса, аны да аңлаттым. 5) Тарих өйрәнә башлаганнан ошбу вакытка кадәр булган заманны мин дә өчкә бүлдем. Ләкин, гомуми тарихтагы кебек, Рум инкыйразларыннан түгел, бәлки Болгар вә монгол хөкүмәтләре инкыйразлары илә бүлдем. Башы мәгълүм булмаган бик иске заманнан Болгар хөкүмәте җимерелгәнче, ягъни монголлар килгәнчегә кадәр – 1 нче бүлек яки иске заман; монголлар килгәннән хөкүмәтләре җимерелгәнче, ягъни Казан алынганга кадәр – 2 нче бүлек яки урта заман; Казан алынганнан ошбу гасырыбызга кадәр – 3 нче бүлек яки соңгы заман аталмага тиешле күрдем. 6) Ошбу рисаләне, ана телебезгә ядкәр булсын өчен, ошбу вакыттагы Казан шивәсе – төрки тел илә яздым һәм дә язылган фән китапларында күрелмәдеке өчен, тупас хисап ителгән вә әдәби телдән мәхрүм ителгән төрки сүзләрне мөмкин кадәр кертергә, шуның илә күбрәк карендәшләрем файдалануны ният итеп, кулдан килгәнчә җөмләләрне кыска, гыйбарәләрне ачык вә җиңел итәргә тырыштым. Бу сәбәптән бәгъзе урында аз-маз урынын аңлатып, бәгъзе мөшкел матдәләрне кабат та язгаладым. 7) Уку вә дәрес илә озак шөгыльләнгән карендәшләр киңәше илә бу китапны шәкертләр файдалануны ният итеп, мөмкин кадәр кыска язмыш идем. Әмма бәгъзе хәерхаһлар аның кайбер урыннары артыграк кыска язылганын, кайбер мөгаллимнәр аңламау ихтималы булганын карендәшләрчә миңа белдерделәр. Инде бу рисаләне мөгаллимнәр вә югарырак сыйныф шәкертләр дә файдалануларын ният итеп язамын. Шул сәбәптән, артык озынлыктан һаман да сакланып, һәрбер карендәшләремә белергә тиеш күрелгән тарихи мәсьәләләр караңгы


«مفصل»

تاريخ قوم توركى

جزء اوّل

بارچه قوملرنك قايو اروغلردن ايدوكنى قسقهچه بياندن
صوڭ، تورك اروغى قوملرنك نسل ونسبلرينى وتركلك روشلر
ينى آوروپاده اول ظهورلرى ترتيبى ايله بيان ايدر تاريخ فنيدر.

موءلفى: قزان مضافاتى امامليرندن آخوند وقاضى حسن عطا
ملا محمد اوغلى العبشى.

هر حقوقى صاحبينه عائددر

اوفا، «شرق» مطبعهسى.

У Ф А.

Электро-типографія „Восточная Печать."

1909.

Хәсәнгата Габәшинең «Мөфассал тарихе кауме төрки» исемле китабы, 1909 ел

калмас кадәре генә тәфсиллерәк яздым. 8) Бар гакылым, фикерем вә язганнарның эчтәлеген тугры вакыйгага туры китерү илә мәшгуль булганлыктан, имля вә инша кагыйдәләренә әһәмият итә алмадым. Күңелем әүвәл хозур иткәнчә яздым. Табигый, бу җәһәтләрдә кимчелек күп булачактыр. Ялгыз көч-куәтем вә кодрәтем кадәренчә бер миллияи гыйльмия (милли гыйлем. – *Ред.*) булдыру өчен яздым. Һәр хосуста күреләчәк кимчелекләр өчен укучылардан гафу үтенәмен.

Милли тарих белән шөгыльләнүгә сәбәпче булганнарга, мәгълүматлары вә китапханәләре илә мине файдаландыручы карендәшләргә тәшәккер итеп, рәхмәт укыймын.

***

Тарих – бер гыйлемдер ки, үткән заманда дөньяның бер рәвешеннән икенчесенә дүнүне белдерер. Ул заман халыкларының тереклек рәвешләрен вә башларыннан кичмеш хәлләрен күрсәтер. Кылмыш эшләрен, тотмыш юлларын вә аларның ни хасил иткәннәрен өйрәтер.

Бу гыйлем адәм углына шундый бер тәҗрибә вә гыйбрәт бирер ки, ул тәҗрибә вә гыйбрәт илә алдагы гомерендә мәгыйшәт вә тереклек хосусында юл ялгышып

афәтләргә дучар булудан сакланырга көче җитәр. Дөнья вә ахирәттә бәхетле булырга сәләт хасил итәр.

Тарихны белергә өч төрле юл бардыр. Беренчесе: үткән замандагы эшләр вә кешеләр тугрысында халык арасында хәбәрләр сачелер, атадан – угылына, электән соңгыга әйтеленә-сөйләнә килер, моны «сөйләнмеш әсәрләр» дип аталынадыр. Бу рәвештә хәбәрләр ишетелгәнчә кабул ителмәс, бәлки аркылыга-буйга хисап ителенер, заманындагы вә алдында, вә артындагы булып үтмеш эшләр вә хәлләр илә чагыштырылып каралыр. Алланың дөньяны яралтуында булган сөннәт вә гадәтенә дә күз салыныр, бушка чыгарырдай бер эш күренмәгәндә кабул ителенер.

Икенчесе: үткәндәге эшләрнең өстендә булыр, күзе илә күрер, үзе вә йә бер-ике, вә йә күп кешеләр аркылы ишетер, күргән вә ишеткәннәрен язар, бу язылмышлар безгә ирешер, моны «язылмыш әсәрләр» дип аталынадыр. Бу рәвешле хәбәрләр әүвәлгегә караганда куәтлерәктер. Шулай булса да әүвәлгедәге саклык монда да шулчикле кирәктер, аның өчен бу рәвешле хәбәрләр һәр икәвесе күп вакытны арттыру вә кимeтү илә үзгәртеләдер. Каю вакыт асылы-төбе булмаган, баштанаяк буш уй вә төрле хәбәрләр илә төзелгән коры хыяллар да булып чыгалар. Борынгы тарихлар күбрәктә ошбу ике төрле әсәргә бина кылынып язылмышлардыр.

Өченчесе: иске заманнан калмыш шәһәрләр, кальгалар, үрләр, йортлар, кораллар, акчалар, сөякләр, кабер ташлары, ат вә өй әсбәпләре, киемнәре, зиннәтләр, язулар вә моннан башка Алла яралтмыш йә адәмнәр ясамыш нәрсәләр. Боларны «иске әсәрләр» дип атарлар. Тарихның тугрырак һәм ышанычлырак юлы ошбудыр. Соңгы тарих күбрәк ошбу төркем әсәрләргә бина кылынып язылмышлардыр. Бу төркем әсәрләр көн саен табылып тормактадыр. Иске тарихларның күп сәхифәләрен үзгәртергә мәҗбүр итмәктәләрдер.

ТАРИХНЫҢ БУЛЫШЧЫЛАРЫ

Тарихны сөйгән бер кеше, әлбәттә, ошбу дөньябызның бер тарафында булыр. Бу эшнең йә кешенең урыны билгеле вә ачык беленмәсә, күп вакыт ялгышлыкка төшеленәдер һәм төшелмештер. Моның өчен җир йөзен алдыбызга җәелмеш ашъяулык кеби таный белүе дә бик кирәктер.

Заман дидегебез һәрвакыт яңарып тормакта булган бернәрсәдер, аның яңаруы илә башка нәрсәләр дә яңарыр. Бу сәбәптән җир йөзендә булган нәрсәләр вә халыклар да һәр заман яңарып вә үзгәреп тордыгы кеби, җиребез үзе дә яңару вә үзгәрүдән котылмамыштыр. Һавалар алышынмыш, диңгез сулары күчелмеш, боз астындагы вә диңгез төбендәге җирләр өскә чыкмыш, адәмнәр тереклек итәргә яраклы булмыш. Әүвәлдә адәмнәр тереклек итмеш бәгъзе җирләр су төбендә калмыш, йә сусыз-утсыз сахраханәгә дүнмеш. Тоташ диңгезләр аерылмыш. Аерымнары тоташмыш. Ишетелгән вә укылган хәбәрләрне ялгыш расламак, йә тиешсез ялганга чыгармактан саклану өчен, җир әхвәлен дә белү кирәктер.

Шәригать әһелләре каршында дөньядагы кешеләрнең барчасы Адәм галәйһиссәлам ыругыннандыр. Шулай булса да, заманнарның бик күп үттегеннән, бу көнге күрдекебез кеби халык бик күптөрле ыругларга бүленмеш, вә бу ыруглар да ничә бүлекләргә аерылмыштыр. Телләре дә шулкадәр төрлеләндеке кеби, кыяфәтләре вә тереклек рәвешләре дә шулай ук башкаланмыштыр. Инде хәзерге адәмнәрнең кайсы каю ыругтан вә каюсына якын идекен белергә йөз вә кыяфәт илә телләр вә әхвәл мәгыйшәт галәмнәре дә күп булышлык итәрләр.

Дәвамы киләсе санда ■

Сәгыйдь[1]

Ризаэддин Фәхреддин

ӨЧЕНЧЕ МӘЧЕТ

Сакмар тарафында булган мәчетне 1203 (1789) елда **Хөсәен бине Әбик** исемле сәүдәгәр төзеткән. Бу агач мәчет 1274 (1758) елда янып харап була. Соңрак **Мөхәммәдсадыйк бине Салих** вә ир туганы **Мөхәммәдбакый бине Салих Бәнүхисам**нар кабат агач мәчет салалар. Икенче мәчет тә 1882 елда янып әрәм була. Моннан соң 1301 (1884) елда Мөхәммәдбакый бине Салихкямал таш җәмигъ бина итеп, дин әмерендә вә гыйбадәт бабында булган тырышлык вә гайрәтен лаек мәртәбәсендә гамәлгә ашыра.

Беренче имам – **Мостафа бине Биктимер әд-Дәүләтярый**. Бу кеше яхшы, күркәм дәресләр укытты, дип риваять итәләр.1242 (1827) елда вафат.

Икенче имам – **Вәлид бине Мөхәммәдәмин бине Сөләйман бине Бикмөхәммәд бине Азай**. Ватаны – Тәтеш өязендәге Кайбыч исемле авыл. Гыйлем алуда остазы Мөхәммәд бине Гали әд-Дагстани булып, Фәезхан бине Хазирхан әл-Кяблидән тәрикать рөхсәте *(иҗазәт. – Ред.)* алган. Казан вилаятендәге мәшһүр Кизләү, Әлмәт, Пәрәү ишаннарының силсиләләре ошбу Вәлид ишанга тоташа. 1214 (1799) елда җәяү хаҗ сәфәренә чыгып китә. Мисыр әл-Каһирәгә барып җиткәндә, француз гаскәрен Мисыр вилаятеннән куу вә чыгару фикере илә Ак диңгездә каравыллап торган ин-

Оренбург Каргалысындагы 3 нче мәчет рәсеме. 1883 нче елда кирпечтән салынган. Бинасын Каргалының мәшһүр байларыннан Бакый Хисамов 1910 нчы елда, мәрхүм Вилдан Габделваһаповның васыяте буенча, кабат төзекләндерде.

[1] Текст хәзерге әдәби телгә якынайтылып бирелә. Җәя эчендәге ел хисабын үзебез билгеләдек. — *Ред.*

глиз гаскәренә очрап, күп мәшәкать күрә. Ошбу сәфәрендә 1217 (1802) елда Мәдинәи мөнәвәрәдә вафат була.

Өченче имам моның углы **Мөхәммәд бине Вәлид**тер. 1256 (1840) елда вафат.

Дүртенче имам – **Моталлиб бине ...**[2] . Бу 1258 (1842) елда вафат. Башка әхвәле мәгълүм түгел.

Бишенче имам – **Һибәтулла бине Сәедбаттал**. Бу кеше, күркәм шагыйрь булуыннан тыш, Дәүләтша бине Гаделша хәзрәтләреннән гыйлем эстәп, шәехлек алган. Әсәре басылган. 1282 (1865) елда вафат.

Алтынчы имам – **Химад бине Гайсә бине Габдекәй бине Иштугани**. Габдулла бине Яхъя әл-Мәчкәрәви хозурында белем ала. Юлык авылыннан китеп, ошбу мәчеттә имам була. 1265 (1849) елгы давылда вафат булды.

Җиденче имам – **Гомәр бине Баһадиршаһ**. Байморад бине Мөхәррәм вә Габдулла бине Яхъя әл-Мәчкәрәви шәкертләреннән дәрес алганы риваять ителә. 1272 (1856) елда вафат.

Сигезенче имам – **Әхмәдшаһ (Әхмәди) бине Нигъмәтула бине Габдерәхим**. Асылы – Пенза губернасындагы Аллагол исемле авыл. Атасы Нигъмәтулла бине Габдерәхим, Дәүләтша бине Гаделша хәзрәтләренең мәртәбәле шәкерте булып, аның Гайшә исемле кызын никах итеп, кияве булды. Әхмәдшаһ исә, Һәбибулла бине Сәедбаттал вафатыннан соң, ошбу мәчеттә имам булып, аз-маз вакыт соңында Тозтүбә[3] шәһәренә күчеп китте.

Тугызынчы имам – **Хәлилрәхман бине Максуд** 1274 (1858) елда имам булды.

Унынчы имам – **Габделгалләм бине Химад бине Гайсә**. Әхмәдша бине Нигъмәтулла киткәннән соң имам булып, Җаек елгасы буенда булган Яңа Каргалы исемле авылда аз-маз имам булды. 1290 (1873) елда күчеп китте.

Унберенче имам – **Габдерәхман бине Габделкәрим ахун**. Габделгалләм бине Химад күчеп киткәннән соң имам булып, 1311 (1894) елда вафат булды.

Уникенче имам – **Хәсән бине Габдерәкыйб**. Габдерәхман бине Габделкәрим вафат булганнан соң имам булды.

ДҮРТЕНЧЕ МӘЧЕТ

Каргалы тарафында булган мәчет. Бу мәчетне **Габдерәхман бине Әүләй** исемле кеше 1225 (1810) елда төзегән. Әмма 1858 елда бу мәчет янып һәлак булган. Соңрак бер казакъның матди ярдәме һәм **Гали бине Габбас** исемле кешенең иганәсе илә кабат төзелде. 1304 (1887) елда мәхәллә кешеләреннән **Габделлатыйф бине Габдессаттар** исемле иганәче моның алдагы тарафын зурайтып, түбәсен тимер илә яптырды.

Беренче имам – **Әбүбәшир бине Ишмөхәммәд**. 1245 (1829) елда вафат.

Икенче имам – **Габделгафур бине Габдерәхим**. Бу кеше 1273 (1857) елда вафат.

Өченче имам – **Сәйфулла бине Габдерәхим**. Бу кеше 1246 (1830) елда вафат.

Дүртенче имам – **Мөхәммәдшәфигъ бине Габделмәҗид бине Кәрим**. Кулчым исемле авылдагы имамлыгыннан 1255 (1839) елда ошбу мәчеткә имам булып күчте. Соңрак моннан җиденче мәчеткә имам итеп билгеләнде.

Бишенче имам – **Мөхәммәдвәли бине Мостафый**. Мөхәммәдшәфигъ бине Габделмәҗид киткәннән соң, 1273 (1857) елда Уфа мозафатында Казарма исемле авылдагы имамлыгыннан күчеп, имам вә ахун булды. Фәкать ике ел мәгыйшәт итеп, 1275 (1859) елда вафат булды.

Алтынчы имам **Габдерәхман бине Сәйфулла** 1299 (1882) елда вафат.

---

[2] Күп нокталар авторныкы. – *Ред.*

[3] Тозтүбә – тоз карьеры һәм тозлы күлләре белән мәшһүр Соль-Илецк. – *Ред.*

Оренбург губернасындагы Сәгыйдь бистәсенең 4 нче мәчете

Җиденче имам – **Мөхәммәдфатих бине Мөхәммәдвәли ахун**. 1306 (1889) елда вафат.

Сигезенче имам – **Мөхәммәдвәли бине Әхмәд**. Габдерәхман бине Сәйфулла вафаты соңында имам булды. Укуы – Исхак бине Мәхмүд хозурында.

Тугызынчы имам – **Максуд бине Хәлилрәхман бине Сөбхан**. Исхак бине Мәхмүд әс-Сәгыйди, Мөхлисулла бине Максуд әл-Мәчкәрәви шәкертләреннән.

БИШЕНЧЕ МӘЧЕТ

Каргалы елгасы буендагы агач мәчетне **Бикчәнтәй бине Мөхәммәдкол** исемле кеше 1174 (1764) елда төзеткән. Ошбу Бикчәнтәй бине Мөхәммәдкол, үзенең ике углы Искәндәр һәм Әбүбәкер илә, Емельян[4] исемле кеше фетнәсендә катнашып шәһид булганнары риваять ителә. Бу вакыйга 1187 (1773) елда булды. Ошбу агач мәчет утта янганнан соң, **Хөсәен бине Гобәйдулла** исемле кеше үз акчасына 1230 (1815) елда янә агач мәчет салды. Кайвакытта яңартылса да Хөсәен бине Гобәйдулланың асыл бинасы әле дә бакый.

Беренче имам – **Габделкәрим бине Балтай**. Малмыж өязендәге Адай исемле авылдан. Шәех Хәбибулла әл-Бохаридан укып кайтып, Сәгыйдьтә имам булды. Ханәкә бина итеп, мөридләр җыйды. Шәһре рамазанда игътикяфта[5] икән хәлендә 1171 (1758) елда вафат булды.

Икенче имам – моның углы **Исхак бине Габделкәрим**. Имамәт һәм дәресләр укыту илә мәшгуль булып, хозурында күп кешеләр камиллеккә иреште. 1216 (1801) елда вафат булды.

Өченче имам – **Габдерәшид бине Габделкәрим**. Дәмәшекъ шәһәрендә ун ел микъ-

---

[4] Бу кеше Пугачев була. Таштан төзеткән йорты Сәгыйдьтә әле дә сәламәт хәлдә.

[5] Игътикяф – озак вакыт, гадәттә ураза аеның соңгы ун көнендә мәчеттән чыкмыйча гыйбадәт кылу. – *Ред.*

дары укып кайтып, ошбу мәчеттә имам булды. Бу кешене гыйльме хәдистә сәләте илә мактап искә алалар. 1231 (1816) елда вафат.

Дүртенче имам – **Габденнасыйр бине Рәхманколый бине Габдерәхман**. Асылы Тәтеш мозафатындагы Бәбкә исемле авылдан. Ошбу мәчеттә имам булуыннан тыш, ахун да иде. Заһид[6] вә тәкъвә, хуш вә әсәрле аваз илә Коръән уку илә замандашлары арасында башкалардан өстен кеше. Ошбу мәчеттә берникадәр вакыт имам булып торганнан соң, Казанның Зәңгәр мәчет дип танылган дүртенче мәчетенә күчеп китте. 1251 (1835) елда вафат булып, Казан зиратында җирләнде.

Бишенче имам – **Надир бине Габделвәһаб бине Габделкәрим**. Габденнасыйр ахун соңында имам булса да аз вакыт торып, 1250 (1834) елда вафат.

Алтынчы имам – моның углы **Госман бине Надир бине Габделвәһаб**.

Җиденче имам – моның бертугмасы **Ибраһим бине Надир бине Габделвәһаб**.

Сигезенче имам – **Мәклүбай бине Локман**. Габденнасыйр ахун хозурында укып, ватан асылы булган Бөгелмә төбәгендәге Чагдай авылында имам вә мөдәррис булды. 1251 (1835) елда ошбу мәчет имамәтенә күчеп, 1269 (1853) елда вафат булды.

Тугызынчы имам – **Габделхәким бине Габдерәхим.** Асылы Чистай төбәгендәге Чиртуш авылында. Мәклүбай бине Локман вафатыннан соң имам булса да, аз вакыт торып, 1274 тә (1858) вафат булды.

Унынчы имам – **Габделгалим бине Химад бине Габбас**. Габдулла бине Яхъя әл-Чиртуши шәкертеннән. 1276 (1860) елда имам булып, дәрес илә дә мәшгуль булды. Мәдрәсәсеннән күп имам җитеште.

Унберенче имам – **Фәрхетдин бине Шәрәфетдин бине Мәклүбай**. Мәклүбай бине Локманның нәбирәсе (оныгы) буладыр. Чистайда Мөхәммәдзакир бине Габделвәһаб әс-Саснави хозурында укып, ошбу мәчеттә имам булды.

АЛТЫНЧЫ МӘЧЕТ

Каргалы елгасы буендагы таш мәчет. Бу мәчетне 1174 (1761) елда **Габделмөәмин бине Әпик** исемле кеше таштан салдырган. Аскы катында мәдрәсә булып, шәкертләре шунда укый, соңрак башмак бүлмәсе арттырыла. Башка төзелешләр булганы беленмәде.

Беренче имам – **Мәүлүд бине ...** . Бу кеше Мәүлүд ахун дип танылган. Оренбург мозафатындагы Яхшы Өммәт авылы башкортларыннан. Укуы Дагстанда булган.

Икенче имам – **Мөхәммәдәмин бине Габделбакый**. Бу кеше гыйлем вә укымышлылык бабында Габдерәхман бине Мөхәммәдшәриф Әл-Кирмәни дәрәҗәсендә саналыр. Асылы Казан мозафатындагы Наласа исемле авылдан. 1242 (1827) елда вафат булды.

Өченче имам – **Садретдин бине Мөхәммәдәмин бине Габделбакый**. Яхшы кеше, диндар вә тугры сүзле иде, диләр. 1286 (1869) елда вафат.

Дүртенче имам – **Мөхәммәд бине Әбүбәшир**. Алда искә алынган Садретдин бине Мөхәммәдәминнең кызын никах итеп, кияве булды. 1306 (1889) елда вафат.

Бишенче имам – **Госман бине Җәгъфәр**. Самара вилаятендәге Фәйзулла исемле авылдан. Исхак бине Мәхмүд әс-Сәгыйди хозурында укып, 1300 (1883) елда имам булды.

Алтынчы имам – **Әхмәдшәриф бине Мәхмүд бине Әбүбәшир**. Атасы Мәхмүд сәламәт вакытта вазыйфасын ошбу углы Әхмәдшәрифкә тапшырган. Укуы Исхак бине Мәхмүд әс-Сәгыйди, Мөхлисулла бине Максуд әл-Мәчкәрәвиләрдә булды. Бу кеше Мәчкәрәдә Габдерәхман бине Мөхлисулла исемле имам вә мөдәррис вафаты

---

[6] Заһид – дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнүче. – *Ред.*

Оренбург, Сәгыйдь бистәсендәге (Каргалы) 6 нчы мәчетнең рәсеме һәм агач мәдрәсә

соңында, 1310 (1893) елда аның урынына Мәчкәрә авылына күчеп, имам булды.

Җиденче имам – **Гатаулла бине Сәмигулла**. Әхмәдшәриф бине Мәхмүд соңында имам булды. Асылы – Богорыслан авылындагы Котлыгмөхәммәд исемле авыл. Остазы – Хәйрулла бине Зәйнулла әл-Арыслани.

ҖИДЕНЧЕ МӘЧЕТ

Каргалы суы буенда булган таш мәчет. Бу 1225 (1880) елда Габделҗәлил исемле сәүдәгәр акчасына төзелгән. Соңыннан төзекләндерелгән һәм ал тарафы бераз арттырылган.

Беренче имам – **Әбү Ильяс бине Әбелфәез бине Габессәлам ахун**.

Икенче имам – **Гомәр бине Габделваһаб**. Бу кеше – Надир ахун бине Габделваһабның тугмасы. 1271 (1855) елда вафат.

Өченче имам – **Моттаһир бине Мозаффар бине Габдессәлам ахун**.

Дүртенче имам – **Гыйсаметдин бине Моттаһир бине Мозаффар**. Укуы Тәмур бәк ахун бине Вилдан хозурында. 1275 (1859) елда вафат булды.

Бишенче имам – **Мөхәммәдшәфигъ бине Габделмәҗид бине Кәрим**. Дүртенче мәчет имамлыгыннан бу мәчеткә күчте. 1300 (1883) елда вафат.

Алтынчы имам – **Нуретдин бине Ногман**. Берничә ел имам булып, 1281 (1864) елда икенче мәчеткә күчте.

Җиденче имам – **Мөхәммәдгали бине Әбүбәкер**. Мөхлисулла бине Максуд әл-Мәчкәри шәкерте. Мәдрәсәсе дә булып, шәкерте күп.

Сигезенче имам – **Хәйрулла бине Зиннәтулла бине Галикәй**. Асылы – Уфа төбәгендәге Арыслан исемле авыл. 1304 (1887) елда имам булды. Дәресе дә бар.

Безнең мирас №2 февраль 2019

СИГЕЗЕНЧЕ МӘЧЕТ

Базар янында куш манаралы булган таш мәчет. 1220 (1805) елда **Мөхәммәдрәхим бине Мәһди** исемле кеше үз акчасына төзеткән. Кайвакыт төзекләндерелсә дә асыл бинасы иске хәленчә.

Беренче имам – **Солтанморад**.

Икенче имам – **Ногман бине Мәүлүд.** 1253 (1837) елда вафат.

Өченче имам – **Вәлетдин бине Хәсән**. Асылы Бәгъдадтан. Хаҗи Бәгъдади исеме илә мәшһүр, мокъри (кари, Коръәнне күңелдән укучы. – *Ред.*) булган ошбу кеше, мәхәлләсендә тынычсызлык булу сәбәпле, эшеннән азат ителде. 1247 (1831) елда вафат булды.

Дүртенче имам – **Бәдретдин бине Сәйфелмөлек бине Габделгазиз**. Танылган галим. 1300 (1883) елда вафат.

Бишенче имам моның углы **Габдерәхман бине Бәдретдин**. 1310 (1893) елда эшеннән читләштерелде.

Алтынчы имам – **Әхмәдшаһ бине Нигъмәтулла**. Тозтүбәдән ошбу мәчет имамәтенә күчте. 1307 (1890) елда вафат.

Җиденче имам – **Әбелмөхбин бине Гыйсмәтулла**. Казан мозафатындагы Мәңгәр исемле авылдан 1290 (1873) елда күчеп китте. Мәхкәмәи исламиядә бер нәүбәт әгъзалык хезмәтен дә башкарды. Исмәгыйль бине Муса әл-Кышкарый талибәсеннән.

Сигезенче имам – **Харрас бине Әхмәдшаһ бине Нигъмәтулла**. 1317 елда Габдерәхман бине Бәдретдин урынына имам булды. Хәйрулла бине Госман әл-Уфави талибәсеннән.

Каргалыдагы 8 нче мәчет. Аңа 1795 елда мәхәлләнең бае Мәһди Кыйсаров нигез корып, ул вафат булгач, углы Мөхәммәдрәхим тәмам кыйлган

Оренбург Каргалысының 9 нчы Яңа бистә мәчете

ТУГЫЗЫНЧЫ МӘЧЕТ

1882 елдагы гадәттән тыш вакыйдан соң, Каргалы суының икенече тарафына бер микъдар халык аерылып, бер мәхаллә оештырдылар. Бу мәхалләгә **Мостафа исемле кешенең угланнары Рәхмәтулла, Нигъмәтулла, Сибгәтулла** исемле сәүдәгәрләр бер агач мәчет бина итеп, янында мәдрәсә дә булдырдылар. Мәдрәсә кечерәк булганлыктан яңартырга вә төзекләндерергә мохтаҗлык сәбәпле, 1312 (1894) елда **Хөсәен балалары Әхмәд, Габделгани, Мәхмүд әфәнделәр** акчасына таш мәдрәсә бина иттеләр.

Беренче имам – **Әюп бине Ибраһим**. Бөгелмә төбәгендәге Зәй елгасы буенда урнашкан Тайсуган авылыннан. Остазы – Габденнасыйр бине Габдерәхим әт-Тайсугани. 1300 (1883) елда имам булды.

Икенче имам – **Габделкотдус бине Нуретдин бине Ногмани**.

***

Таркау хәтеребездә калган мәгълүматтан бу урында язарга ният иткән шәйләрем тәмам булды. Ният исә ошбу рисаләне язу түгел, фәкать киләчәкләргә бер ядкәр калдыру иде. Шуның өчен дә кимчелек вә хаталарым өчен гафу үтенүне кирәк дип тапмадым. Китап төзү вә җыю илә мәшгуль булган кешеләрнең, моның мәшәкатен яхшы белгәннәре өчен, хаталарны һәрвакытта гафу итәргә әзер булганнары мәгълүм. Бу эш белән мәшгуль булмаган кешеләрдән, язуларда булган кимчелекләрне санау вә мәҗлесләрдә аны озын итеп сөйләгәннәре өчен гафу сораудан да мәгънәсезрәк бер эш булмас. Болар хакында Акмулланың шигыре туры килә:

«Бер җиргә килештереп хат яза алмый,
Берәүне яманларга гаять оста».

Тәмам

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Мәчет фотолары ТР Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган «Юбилей ядкәре» (Казан, матб. «Кәримия», 1911 ел) исемле китаптан алынды.

БЕР АЙ ЧАСТЬТА

Гыйлемдар Баембәтов

Гыйлемдар Солтан улы Баембәтов (1886-1933) – сәясәтче, өч инкыйлабта катнашкан язучы, драматург, тәрҗемәче, журналист, «Хөррият», «Ирек», «Авыл халкы», «Көрәш», «Кызыл яу», «Хасабе сәхифәсе» («Хезмәт сәхифәсе») исемле газеталарның даими авторы, мөхәррире, Уфа губернасының халык комиссары (1917), сул эсерлар фиркасе (1905-1918) һәм РКП(б) әгъзасы (1918-1930), Милләт Мәҗлесе депутаты (1917-1918), «Тупракчылар» фракциясе әгъзасы, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе җитәкчесе. Казан, Самара, Санкт-Петербург, Мәскәү, Урта Азия, Яңавыл, Уфа тарафларында киң кырлы эшчәнлек алып барган әлеге мөхтәрәм зат берничә мәртәбә кулга алына. 1933 елны ТАССР ОГПУ коллегиясе тарафыннан «сул эсерларның «Крестьян иттифагы» фиркасен яклау»да гаепләнеп, атып үтерелә. 1989 елда аклана. Г.Баембәтовның тормыш юлы һәм сәяси эшчәнлеге белән beznenmiras.ru сайтында танышырга (смартфон ярдәмендә QR-код аша да керергә) мөмкин.

Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган социаль-психологик төсмерләр белән баетылган истәлектә Г.Баембәтов 1906 елда беренче төрмә чирканчыгы узуы турында тәфсилле бәян итә. Автор мәкаләне, 1909 елның августында 3 елга Вологдага сөрелеп, аннан качып кайтканнан соң, «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 20 һәм 25 гыйнвар (№635, 637) саннарында бастыра.

1906 елның 4 апрелендә Казанда идем. Балык базары урамында Морасов йортында бер табиб хатыны квартирында бүлмә алып тора идем. Хосусый мәшәкатьләрем булганлык белән бүген чыгып йөри төштем. Квартирыма сәгать 9ларда кич кенә кайтып кердем. Мин капкадан кергәндә кечек капка буендагы эскәмиядә бер адәм утыра иде. Тыштан карамакта, ул урыс иде.

Бу көн пасха бәйрәме булса да, ул өстенә шакшы киенгән. Бу көн урыслар өчен шундый әһәмиятле бер көндә бөтен урыс гаиләләре шатлыкта, кәеф-сафада, бае юк, ярлысы юк – барысы да дөньяны онытып бәйрәм итәләр. Ә бу адәм өшеп-катып сәгать 10ынчыларда кич капка төбен каравыллап утыра. Ишекне ачып кергәндә бу мәгъсуманә булып утырган адәмнең вөҗданы сафлыгында мин шик тоттым. Бу мәлгунь эшпиун булмаса ярар иде, дидем. Шулай булса да мин аны исемнән бик тиз чыгардым. Бүлмәмә кердем дә

Бу вакытта бер бәгыремне кискән нәрсә булса, бу хәлгә дучар булуым тиз заманда әткәм вә әнкәмә ишетелеп, анлар кебек бала хәсрәте күрергә өйрәнмәгән кешеләрне зур хәсрәткә калдыру, әллә никадәр гөнаһсыз яшьләр, сабый туганнарымның яшьләре түгелү иде. Бу шулай буласы миңа көннәр кебек ачык иде.

лампага ут кабыздым. Чишендем, юындым, караватка яттым. Кулыма алган китапны укый башладым. Сәгать 11дә бер зат киләчәк иде. Аны көтәм. Квартирда бер урыстан башка беркем дә калмаган. Хуҗа хатын да, балаларын алып, кунакка киткән. Мин кухняга кердем дә киләсе кунагым өчен дә, үзем өчен дә самовар куйдым.

Тагын укыймын. Бүлмә эче тып-тын. Колак салып тыңлап торсаң, самовар гөжләгәне генә ишетелә. Бераздан соң «тыр... тыр... тыр... тыр...» ишек кыңгыравын тарталар. Мин, тиз генә сикереп торам да, кулымдагы китабымны куеп, ишек ачарга ашыгам. Кунагымдыр инде бу, димен дә ишек төбенә кулыма лампа тотып киләм.

Г.Баембәтовның төрмәдә төшерелгән фотосы

Ишегалдында итек ышпурлары чылтыраганы ишетелә. Анда таптаналар, төкеренәләр дә чыш-пыш сөйләшеп тә алгалыйлар. Мин: «Юк. Бу миңа килүче түгелдер. Хуҗа хатын, әфитсәр кардәшем бар, дип әйткән иде. Ул шуның белән кайткандыр», – димен. Ишекнең элгечен күтәреп җибәрдем. Ни күзем белән карыйм... Полиция!

Бер пристав, алдан кереп, мине җиңемнән тотып ала. Аннан ары икенче пристав, тагын берничә городовой кереп тоталар. Барысы да кәефлеләр.

Бер пристав, миңа карап:

– Сез Солтановмы? – дип сорый.

Мин:

– Юк, мин Солтанов түгел! Яңашасыз! – дим.

Бер пристав:

– Ник Сез Солтанов булмыйсыз? Сез дарелмөгаллимин[1] шәкертләреннәнме? – ди.

Мин:

– Әйе! – дип җавап бирәм.

Пристав:

– Алай булгач, безгә кирәк кеше Сез инде. Мин Сездә тентү ясыйм! Жандармский полковниктан әмер бар! – ди.

Мин:

– Мин Солтанов булмагач, миндә тентү ясарга нинди хакыгыз бар? Кая әле әмер кәгазе? – дип сорыйм.

Пристав, дәшми-тынмый, сумкасыннан бер язу чыгарып бирә. Язуда минем исем дә бар.

Пристав:

– Ышандыгызмы инде... Бүлмәгез кайда? Мин тентү башлыйм! – ди.

Мин торган бүлмәмне күрсәттем. Мине пристав тентеде дә бүлмәмә кертеп утырт-

[1] Укытучылар әзерли торган уку йорты.

тылар. Ул ике пүнәтәй вә ике городовойны бүлмәгә кертте. Менә тентү башланды. Җыйнак итеп өеп куйган китапларны, өстәлдәге кәгазьләрне, дәфтәрләрне өстенаска әйләндереп туздыра башладылар. Бер сәгать чамасы тентегәч, бүлмә ат азбары кебек булды. Тузан. Городовойлар тынчыйлар. Приставлар өзлексез тәмәке тарталар. «Чыгып тартыгыз!» – дигәнне илтфатка да алмыйча, гафу үтенгән булалар.

Бүлмәдә һава тәмам бозылды, чыдар хәл калмый башлады. Тентү дәвам итә, мин утырам һәм уйлыйм... Бая ишек барып ачканда ук минем бу төнне частьта булачагымда һич шөбһә калмаган иде инде...

Бу вакытта бер бәгыремне кискән нәрсә булса, бу хәлгә дучар булуым тиз заманда әткәм вә әнкәмә ишетелеп, анлар кебек бала хәсрәте күрергә өйрәнмәгән кешеләрне зур хәсрәткә калдыру, әллә никадәр гөнаһсыз яшьләр, сабый туганнарымның яшьләре түгелү иде. Бу шулай буласы миңа көннәр кебек ачык иде. Утырган урынымда шул хәлне уйлап, боега идем. Утыра торгач, ялкып киттем. Ул арада самовар куйганым исемә килеп төште. «Чәй эчәргә мөмкинме?» – дип, приставтан сорадым. Мин бит инде мәхбүс кеше! Пристав бер городовойны чәй ясап китерергә җибәрде. Тиз чәй килде. Ике стакан чәй эчеп алдым. Бу арада бүлмәдә тентү бетте. Бүлмәдән чыгып, бүтән урыннарны актарып йөри башладылар. Бу урыс полициясенең иң истигъмали бер ысулы – ул да бер кешене тентү ясарга әмер алып килсә, өй эчендәге бөтен торучыларын һәм анлар урыннарын тентеп чыга. Күп урыннарда шушы вакыйга тәкърар булып тора. Алар өйне бутап йөргәндә хуҗа хатын да кайтып керде. Аның сандыкларын ачып тентеделәр. Йорт хуҗасы булган хатыннан ачкычлар алып, кар базларын барып тентеп йөргәннәр. Ишегалдын, хаҗәтханәсен тентегәннәр. Бернәрсә дә таба алмый керделәр. Мин кар базы бары-югын да белми идем. Анда корал юк микән, дип эзләп йөриләр икән! Бер пристав протокол язарга утырды. Табылган нәрсә байтак күренә. Прокламацияләр күп. Берничә җилем матбагасы да бар. Анама язган бер хатымны алдылар. Аннан килгән хатларның барысын да алдылар. Белеш-танышларымнан алган мәктүбләрем, берничә визитный карточкаларым бар иде. Барысы да китте. Урыс телендә дә берничәсе табылды. Бу язулар, хатлар шулкадәр мәгъсумәнә язылган ки, һичкемнең күңеленә шик китерерлек түгелләр иде. Пристав протоколны яза, прокламацияләрне саныйлар. Тентү дәвам иткәндә бер татар пүнәтәй өстәл астында торган корзинаны сөйрәп чыгарып тентәргә керешсә дә, анда кара керләрдән башка берни дә күзгә күренмәгәнгә, приставның ташла, дип боерып әйткән сүзен ишетеп, ул аны тагын өстәл астына илтеп куйган иде. Татар пүнәтәйнең корзинкадагы кара керләрне тентеп бетермәгәнгә, корзинканы аударып карамаганга тентү сузылганчы эче пошкан булса кирәк. Урыслар тентеп арыгач, протоколның яртысы язылып беткәч, түзмичә, корзинаны урыныннан сөйрәп чыгарып, ул тагын тенти башлады. Ул корзинаны аударды да ут алып килеп карый. Корзина төбендә бер каты кәгазь бар икән. Аны алып ташлап, төптән берничә хат, 1905 елда көз Казан татар яшьләре арасында чыга башлаган «Хөррият» атлы гәзитәнең ике номерын сөйрәп чыгарды. Мин бу нәрсәләрне үзем дә озак таба алмас идем. Ул, аларны тапкач, берәр тәмле нәрсә биргәндәге сабыйлар сөенече кебек сөенеч белән: «Менә, Ваше благородия!» – дип кычкырып җибәрде. Язып утырган пристав, исе китмичә генә нәрсәләрне алып, протоколга беркетә башлады. Ул – пүнәтәй. Тентергә аның хакы-фәләне юк! Ә ул тырышлык-иҗтиһад өчен кулыннан килгән бөтен һимматен сарыф кыла! Шулай булса да пристав аңа гади генә бер рәхмәтне дә әйтмәде. Протокол язылып бетте. Имзалар да куйдылар. Пристав урыныннан торды. Ул, миңа карап: «Әйдәгез, күнегез!» – диде. Мин кая барасымны сорап та тормадым. Киендем, бер янчыкка шикәр, чәй, бераз лимон кисәге салдым да, аны бавыннан кулыма киеп, ишек төбенә китә башла-

дым. Бүтән нәрсәләремне барысын да бүлмәдә калдырдым. Мин ялгышканмын! Бу да тәҗрибәсезлек җимеше! Бөтен нрәсәләремне барган урыныма алып китәргә кирәк иде... Ә мин хәтта бит сөртергә сөлге дә алмадым! Алып керердәйләрен үзем белән алып керер идем. Алып керү мөмкин булмаган нәрсәләремне расписка белән часть идарәсендә калдырыр идем... Ишектән чыга башладык. Мине арттан да, алдан да тотып алып чыгалар. Ишегалдына чыгасымны күзләрем белән карыйм: полиция бөтен йортны урап алган икән! Берничәсе – атлы городовой.

Пристав, мине өч городовойга биреп, 1 нче часть идарәсенә җибәрде. Городовойларның берсе юлда сөйләнә башлады. Мин дәшмәдем. Часть идарәсенә килеп җиттек. Мине алдан кертеп җибәрделәр. Монда тагын бер манзара. Часть идарәсе тулы городовой. Минем исемне, фамилиямне бер кизү булганы язып алды да городовойга әйтте:

– Бар, алып кит төрекне!

Городовой мине часть казармасына бикләргә алып китте. Бу шактый зур бер бина ат амбарына охшашлы. Аны ачтырып кердек. Ишектән кергәндә әллә нинди авыр исләр, полиция казармасына гына махсус булган ис танауны яра иде. Бер исерек полицейский ачкыччы мине өстәл өстенә дәшеп китерде дә, мышный-мышный исем һәм фамилиямне язып куйды. Ул бүрәнәдәге кара тактага нәхүсез-нисез, үзе белгәнчә, «политический» дип язып куйды. Аннан соң ул мине тентеп, бер камерага китереп япты. Кергәч, ни күзләрем белән карыйм: камераның идәне, сәкесе туп-тулы исерек халык. Босяклар да бар. Аларның кайсылары гырылдашып йоклый, кайсылары акырына, сүгенә. Җырламакчы булып та карыйлар да булдыра алмыйлар. Берсе, ишек төбендәге тышка чыга торган парашага килеп егылган да, шунда косып ята. Берәү, әллә ничә айлардан бирле алмаштырмаган күлмәген салган да, электриктан төшкән яктыга килеп, җанварлар аулый. Мин, идән уртасына килеп туктаганмын да, башымнан әллә нинди уйлар кичереп, шаккатып карап тик торам. Бераз кузгалып, камераның бүтән урыннарына күз салдым. Камера шактый зур, биек. Бер тарафта зур гына бер тәрәзә. Ул бик юан решиткәле. Бу күңелгә бик авыр тоелды. Әллә частьта булганга... Шулай булса да моннан беркая да чыгып китә алмыйм. Өстеңнән бик нык бикләп куйганнар...

Кич сәгать 7-8ләрдә монда шәһәрнең бөтен бәхетсезе җыела башлый икән. Басып торган урынымда мин шыбыр суга төшеп тирләп киттем. Камерада һава бик начар, бозык, бик җылы. Теге кабахәт чиләктән нәҗәсәт исләре чыгып, бөтен камерага җәелгән. Аннан башка исерекләрдән аңкылган ис тә, босяклар исе дә күңелне болгата иде. Берәү, урыныннан торып, минем янга килде: «Якташ, тәмәке юкмы? Карап торам да синең монда әүвәлге мәртәбә килеп керүең бугай. Шулаймы?» – дип сорады. Мин: «Әйе», – дим. Ул миңа бер тарафтан урын күрсәтте.

Мин, тора-тора арыгач, өстемнән пәлтәмне генә салып аска җәйдем дә баш очыма бүркемне салып яттым. Бик озак йоклый алмадым. Кандалалар, бүтән җанварлар, минем ятканны гына көтеп торган кебек, хәзер килеп сырып алдылар. Шулай әле бит тарафыннан, әле бер якта яткан сасы беләктән йөгерешеп килгән хайваннарның һөҗүменнән бимазаланып ята идем, коридорда бик ачы бер тавыш чыкты. Хатын тавышы... Аны ике городовой караңгы камерага алып баралар икән. Мин бу хәлнең асылын бу тавышка ишек төбенә барып, карап торып сөйләгән бер яшь урыстан белдем. Бер гади генә бер яшь урыс, ишек төбеннән китмичә, әллә нинди кабахәт сүзләр кушып сүгенә иде. Городовой килеп: «Йокла!» – дип кычкырды. Ул, городовойның бу сүзләренә каршы әллә нинди сүзләр әйтеп, төкеренә-төкеренә урынына барып ятты. Ул арада безгә янәшә камерада тавышлана башладылар: әллә сугышалар, әллә

ни кыланалар. Городовой килеп: «Йоклагыз, фәләннәр...» – дип кычкыра. Тавыш тиз басылды.

Бераздан соң казарма тып-тын булды. Ахрысы барысы да йоклап беттеләр бугай. Мин дә азрак оеп алдым. Кулыма бер салкын нәрсә тигәнлектән уянып китәм. Ул арада минем яннан берәү икенче урынга үрмәләп бара. Ул, мин баш күтәреп карагач ук, туктап ятты да йокысына китеп йоклаганга салышты. «Ни бар?» – мин әйтәм күңелемнән. Соңра гына бу вакыйга исемә килеп төште. Ул мин кулыма бавыннан киеп яткан чәй-шикәр капчыгын алырга маташкан икән. Тышкы кесәләремә дә кереп чыккандырмы, анысын белмим. Әлхасыйль, ул, минем нием туры килсә – шуны угрыларга килгән инде. Бу уйкануымнан тиз йоклый алмадым. Тәрәзәгә таң нуры төшкән. Тиз яктырып көн буласын белдерә иде. Мин теге хатынны алып барганда башыма килеп төшкән уйларны рәткә кертә алмаган идем. Хәзер бераз таныдым, уйлый башладым. Инде шуннан соң тагын йоклап киткәнмен. Иртән тик каты ишек тибүгә генә уянып киттем. Кояш чыккан, тәрәзәнең бер кырыеннан гына төшеп, камераның бер тарафындагы стеналарга нурын салып тора. Кунучылар барысы да дип әйтерлек урыннарыннан кубып беткәннәр. Алар болганышалар, чайпалалар. Кайсылары кичә эчкән бутылкаларын санайлар, йөргән җирләрен искә төшерәләр, кичә кылган гамәлләрен сөйләп-сөйләп куялар. Бәгъзеләр озын-озын тирги торалар. Ишек төбендә җыелышып торган кешеләр тагын җан ачуы белән ишеккә тибә башладылар. Алар: «Ач ишекне!» – диләр. Ачкыччы бүтән тарафта мәшгуль. Тагын ишек тибәләр. Тагын: «Ач ишекне!» – дигән газап килеп әйткән тавыш яңгырап китә. Ачкыччының ачуы бик килгән. Ул кызарган, бүртенгән. Маңлаеннан тирен сыпырып коридорның әле бер башына, әле икенче башына чаба. Аны да кызганырлык. Монда кем гаепле? Городовой сүгенә: «Көтегез азрак, шайтаннар!» – ди. Ул бертуктамыйча кабахәт сүзләр әйтә. Болар тагын: «Ач, чиләк чыгарырга кирәк!» – дип торганда, ул килеп ишеккә ачкычын шелдерәтеп тыга. Барысы да берсен-берсе мал кебек этеп, йөгереп чыгып китәләр. Бәдбәхет параша урынында утырып кала. Мин дә чыктым. Бик озын коридор идәне. Янган кирпечтән өйгән коридорның ике башында ике тәрәзә. Коридор уртасына түгел, башларына да алардан якты аз төшә. Аларны әллә ничә еллардан бирле, бәлки казарманы салганнан бирле юмаган. Коридорда җуына торган кран-фәлән юк. Чәйнек бар. Кеше суны шуңар алып юына. Яртысы парашаларга юына. Кайсы туптуры кирпеч идәнгә юына. Шунлыктан, коридор бик дымлы, юеш. Сәгать тугызларда барысы да дип әйтерлек чыгып беттеләр. Мин калдым, тагын ике карак калды. Бераз заманнан соң городовой кереп әйтә: «Бишәр тиенгә ни алдыртасыз?» Мин: «Ул нинди бишәр тиен?» – дип сорыйм. Караклар: «Монда тәүлеккә кеше башына бишәр тиен тәгаен кылынган. Шул акчага кибеттән икмәкме, чәйме, анда ни кирәк булса, шуны алдырып була», – диләр. Ул бишәр тиенгә мин дә, тегеләр дә кирәк нәрсәне китерттек. Бүтән акчам да бераз бар иде. Ашарга-эчәргә бер-ике тәүлеккә җитәрлек китерттем. Билгеле ки, иң кирәк булган нәрсә икмәк иде. Караклар мондагы гореф-гадәтләрне бик яхшы беләләр. Аларның бу бәдбәхетханәдә әүвәл мәртәбә утырулары түгел. Аларның комганнары, чашка-фәләннәре бар. Кайнаган су алып килделәр. Чәй эчтек. Караклар, бу көн төрмәгә барабыз, дип хәзерләнәләр иде.

Тентү вакытында хәлем ничек икәне, кайда булачагым бераз мәгълүм булса да, минем хәлем хәзер билгеле түгел иде. Монда калдыраларымы? Җавапка жандарм идарәсенә чакыраларымы? Төрмәгә илтәләрме? Хәлемне аермачык белмичә, бернәрсә булырын көтә идем. Көткән кешегә вакыт бик озак үткән кебек тоела бит ул. Сәгать 12ләр. Мине беркая да чакырмыйлар. Ачкыччыдан минем канторга чакыруларымны таләп иткәнемне барып белгертүен сорадым. Ул, ярар, дип китте. Көтәм – юк.

Көтәм – юк... Городовойны тагын кычкырып алып, минем янга полицмейстер яки аның иптәше килүне требовать итәм. Городовой: «Ыстаршый өйдә юк! Ул кайткач, даложить итәрмен аңа», – ди. Сәгать икенче... Ыстаршый да юк, городовой да ишек төбенә килми. Ул килү белән генә эш тә чыкмый, аның ыстаршасы булмагач. Ул аннан узып беркая бара алмый инде. Сәгать өч... Ыстаршый килеп: «Сезне бу көн беркая да дәшмәсләр», – ди. Мин: «Нигә алай?» – дим. Ул: «Менә шулай. Канторда начальство юк. Таралдылар. Ә жандармскийга сәгать өчкә кадәре генә әйтеләдер. Сезне анда бу көн требовать итмәделәр дә әле», – ди. Мине икенче көнне дә, өченче көнне дә беркая да чакырмадылар. Хәлемнең ничек булуын белмичә (хәлем моңардан начар булмас иде инде), эшем кем кулындалыгын да белмичә, часть казармасында бер ай тордым. Шулай озак утыручылар булгалаган. Мәгәр аларны берәр урынга җавапканигә чакырганнар яки ничек... Кайсыларының исключительный бер хәл булган. Бу гаҗәп түгел. Ә минем хәл гади генә булса кирәк иде. Эш бик кечкенә бит... Ул заманда бик гади эш. Бары миндә тентү булды. Канунга хилаф булган әдәбият таптылар. Тагын мин үзем барын-югын да исемә төшермәгән берничә кәгазьләр таптылар. Гакылы сәламәт булган әллә нинди генә кешенең ноктаи нәзареннән караганда да анлар һич зыянсыз кәгазьләр. Полиция шуларны пичәтләп, бер эш итеп алып китте. Үземне китереп таш капчыкка тыгып куйдылар. Иртәгесен мине җавапка чакыру кирәк иде инде... Аларча, иртән чакырырга чират булмаса, минем кебек гаепле кешеләр күп булса, бер көн аша, ике көн аша чакыралар. Алар, нәрсә өчендер белмим, частьта бер ай яткыралар да аннан соң төрмәгә тотып җибәрәләр.

Караклар белән бер камерада ике тәүлек утырдым. Аннан соң алар решиткә кисеп качарга тотындылар. Аларны шул төннең иртәгесен үк төрмәгә озаттылар. Караклар белән кай заман шашка уйный идек. Алар белән сөйләшә башладым. Казарма эчендә без өйдәш булдык! Караклар бер вакытны миннән: «Яңа законнар буенча төрмә булачакмы? Караклар өчен нинди законнар чыгачак?» – дип сорадылар. Мин: «Тентү, частька алу тугрысында булган хәзерге правалар һич шөбһәсез ислях ителер, төрмә бетмәс, мәгәр төрмәләрдә тәртип бүтәнчә куелып, анда эләккән кешене бер-бер эшсез тотмаслар, берәр төрле һөнәргә өйрәнү аның өчен мәҗбүри булыр», – дидем. Бер карак, минем сүзне тәмам аңлап җиткерә алмыйчадыр, сорый: «Берәү бары бер генә айга яки аннан да азга гына керер. Ул арада ул ничек итеп һөнәргә өйрәнеп җитсен?» Мин: «Бер ай гына түгел, бер дә кермәсә дә бик яхшы. Мәгәр керсә, бер генә көнгә керсә дә, аңар эш табылыр», – дидем. Минем сүзләрем каракларга ошады. Алар угрылаудан бер дә туктар кебек түгелләр иде...

Актык төнне караклар озак йокламыйча кич утырдылар. Гавам җырларын җырлыйлар иде... Мин югарыга иртә яттым вә тиз йокыга киттем. Бик арыганмын. Хәлем билгесезлеге мине йөдәткән. Алҗып беткәнмен...

Йолдыз. – 1911. – 20 гыйнвар. – №635; 25 гыйнвар. – №637.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм*
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2019

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

ТАТАРСТАННЫҢ БИШЬЕЛЛЫК БӘЙРӘМЕ КӨНЕНДӘ

Татарстан дәүләтчелеге тарихындагы мөһим даталарны бәйрәм итү яки билгеләп үтүнең төрле елларда үз традициясе бар. Аның иң әүвәлгесе һәм масштаблысы ТАССРның бишьеллыгын бәйрәм итү булгандыр, мөгаен. Анда 1925 елда башкарылган эшләргә нәтиҗә ясала, махсус китап-җыентык дөнья күрә, вакытлы матбугат битләрендә һәр тармактагы үсеш-үзгәреш турында мәкаләләр басылып чыга. Хәзер тәкъдим ителә торган язма һәм фотоларны (чыганак – «Безнең юл». – 1925. – №7-8. – Б.273-274) республикабызның беренче зур бәйрәме рухын саклаучы ядкәр буларак кабул итәрсез, дип өметләнәбез.

Редакциядән

Татарстан Җөмһүриятенең бишьеллык бәйрәме. Парадта – эшче оешмалары, спортчылар һәм яшь ленинчылар.

Парадта Кызыл Армиянең атлы гаскәре

Татарстанның бишьеллык бәйрәме көнен җөмһүриятебезнең үзәге булган Казан чыннан да зур бер тантана белән үткәрде. Бу көнне бәйрәмнең үзәк пункты «Ирек» мәйданы бәйрәм итүчеләрне каршы алырга алдан ук хәзерләнгән иде. Завод-фабрикадан хезмәт ияләре, музыка һәм кызыл байраклар белән, төркем-төркем булып, мәйданга агыла. Сәгать унынчы яртылар алдыннан Кызыл Армия полклары саф-саф булып, мәйданга килә башладылар.

Әнә, берләшкән татар-башкорт хәрби мәктәбе курсантлары. Алар арасында атлы гаскәр үзенең төзлеге һәм очар коштай матурлыгы белән халыкның дикъкатен аеруча үзенә тарта. Әнә, дөнья җимереп, тупчы гаскәрләр киләләр. Менә инде бөтен гаскәрләр үзләре өчен алдан билгеләнгән урыннарга төз рәтләр белән барып урнаштылар.

Эшчеләр һәм гомумән хезмәт массасыннан гыйбарәт булган халык төркеме көрәш мәйданнарында үзләренең нык арка таянычлары булган шанлы Кызыл Армия сафларына һәм сокланып, һәм мактап карыйлар. Бит бу төз сафлар аларның үз көчләре белән үз улларыннан, үз туганнарыннан төзелгән!

Каяндыр барабан тавышы ишетелә. Бу – карт буынга алмашка әзерләнүче пионерлар. Алар, барабанның төз ритмлы өзек-өзек тавышлары астында, аерым бер яшьлек шаукымы белән дәртләнеп-дәртләнеп тигез генә атлап баралар. «Парад, смирно! Равнение на-право!..» – дигән тантаналы команда тавышы яңгырый.

Татарстан Җөмһүрияте хөкүмәте, партиянең өлкә комитеты һәм эшче оешма-

Парадның гомуми күренеше

Парадның рәисе иптәш Антипов кызыл гаскәрләр белән исәнләшә

лары вәкилләре һәм кантоннардан тантананы карарга килгән крәстиәннәр кызыл гаскәрләрнең сафлары буенча карап йөриләр.

Һәрбер Кызыл Армия бүлеге һәм һәрбер эшчеләр оешмасы төркемен парадны кабул итүче аерым-аерым сәламли. Аның һәрбер сәламләве көчле. «Ура!» тавышларына катнашып, бөтен мәйданны яңгырата. Кинәттән сугылган барабан тавышлары инде митинг башланганны белдерәләр.

Ике-өч җирдә ораторлар сөйли башлыйлар. Аларның речьләре озын түгел. Кыска җөмләләргә, кыска сүз калыпларына алар көчле мәгънә салганнар.

Митингны рәсми рәвештә ачкан Габидуллин[1] иптәш үзенең речен:

– Бөтен хезмәт ияләрен, үзебезнең көчле Кызыл Армиябезне, яшь пионерларны тәбрик итәм! – дигән сүзләр белән тәмамлый.

Өлкә партия комитеты секретаре Морозов[2] иптәш реченең ахырында:

– Яшәсен милләтләрнең үзара берлеге! Яшәсен Көнчыгыштагы җиңү! – ди.

Бөтен бәйрәм тантанасы, сөйләнгән барлык речьләр менә шушы Көнчыгыштагы кузгалган халыкларның җиңүен[3] теләү лозунгысы астында үтә.

Бөтенрусия үзәк башкарма комитеты президиумы әгъзасы Әсфәндияров үзенең тәбрикләп сөйләгән речендә хезмәт ияләрен тагы да ныграк берләшергә өнди.

Авыллардан җөмһүрият бәйрәменә катнашу өчен махсус сайланып җибәрелгән крәстиәннәр митингка катнашучыларны тәбрик итәләр. Аларның сүзләре искиткеч бер кул чабулар белән каршы алына. Речьләр тәмам булганнан соң, кызыл гаскәрләр церемония маршы белән узалар. ■

[1] Габидуллин Хаҗи Заһидулла улы (1896-1937) – 1924-1927 елларда ТАССР Халык комиссарлары советы рәисе.

[2] Морозов Иван Титович (1889-1957) – 1924-1925 елларда Татарстан өлкә комитетының җаваплы (беренче) сәркатибе.

[3] 1920 нче елларда Төркия, Һиндстан, Монголия, Мисыр һәм Африканың кайбер дәүләтләрендә азатлык сугышлары, 1925-1927 елларда Кытайда милли азатлык революциясе була. Аларның күбесе, аеруча Кытайдагысы СССР катнашында уза.

Ризаэддин Фәхреддин *гыйбарәләре*

• Ирләр һәрвакытта хатыннары теләгәнчә булырлар.

• Милләт мәшһүр адәмнәре белән мәртәбәле.

• Вәгазьләрне күңелләргә салыр өчен, үзең саф һәм әзер булу гына җитми, бәлки вәгазь сөйләүченең әүвәл үзе шундый булуы кирәктер.

• Үзенә хуҗа булып, хисләрен кулында тота алса, нәфестән дә юаш һәм итагатьле нәрсә дөньяда булмас иде.

• Сәламәтлек – бер хезмәттер ки: һич тә хакы түләнмәс.

• Адәм баласының иң зур байлыгы – тәне һәм җаны сәламәт булу.

• Акчаның үзен сөю – иң каты фәкыйрьлектер.

• Акчасы вә дәүләте күп кеше бай түгел, бәлки икътисады булган кеше байдыр.

• Милләтләр югары күтәреләләр, түбән төшәләр, алга китәләр вә артта калалар, хуҗалык итәләр, хезмәтче булып йөриләр; шушы эшләрнең һәрберсендә асыл көч, төп сәбәп – яшьләрдәдер.

• Дөньяда яшәргә һәм башкалар рәтендә гомер сөрергә теләгән милләт үзенең үткән көннәрен белсен һәм үз тарихы белән дус булсын.

• Һичнәрсәсе булмаган кеше фәкыйрь түгел, бәлки һөнәре вә тырышлыгы булмаган кеше фәкыйрьдер.

• Дусларны камил вә яхшы адәмнәр арасыннан сайлагыз. Дине бөтен, гакылы камил, нәсел-нәсәбе асыл, фикере тугры, әдәбе җирендә булган кешеләрне табыгыз!

• Ислам диненең әһәмиятле нигезе – ихласлык.

• Төшүе авыр булган югары урынга кызыкма.

• Тугрылык – максатка бара торган юлларның һәм кыскасы, һәм яхшысы.

• Дошманны җиңү өчен көчле корал – аңа изгелек итү.

• Озын сүзләрдә кыска гына бер максат була...

• Киң далада адашып йөрүче сарык көненә төшмәс өчен, гыйлем үгрәнү лязим!

• Инсаннар тормыш юлында туктап торыр өчен килмәгәннәр, әмма һәмишә алга барырга, югарыга омтылырга килгәннәр.

• Күрү өчен йөрүче хатыннарга караганда, күрелү өчен йөрүче хатыннар күбрәк була.

• Философлардан берсе, исерткеч эчеп утырган берәүне күргәч: «Бичара адәм! Үзенең сәламәтлеген, хатынының күз яшьләрен, балаларының ризыкларын эчә», – дип әйткән.

• Ата вә анагызны, якын кардәшегезне ничек сөйсәгез – милләтегезне шулай сөегез, милләтегез өчен хезмәт итүне җаныгызга зур табыш дип санагыз.

Журналга ***Диләрә Гыймранова*** *әзерләде* ■

САРАЛЫ МЕҢ ЫРУЫ ТАТАРЛАРЫ

Раиф Мәрданов

2. Рус патшасы Иван Васильевич исеменнән 1562 елның 22 июлендә дүрт кешегә – Чөкрәй Аккуҗак улына, Бәхтияр Дәүләтьяр улына, Салтамыш Миркамал улына һәм Яуш Аккуҗак улына Казанда бирелгән документта Чулман һәм Ык елгалары буендагы җирләрен элекке әтиләре заманындагы, ягъни Казан ханлыгы чорындагы кебек биләү хокукы бирелгән («...и им теми вотчинами владеть по тому ж, как владели отцы их»). Шунда ук аларның Иж буендагы Тирсә волосте биләмәләренә дә хуҗа булганлыклары һәм үзләре Чулманның Агыйдел елгасына каршы тарафында, Тойма елгасы тамагында яшәгәнлеге әйтелгән. Архив документында ясаклы татар (чувашенин) дип теркәлгән Чөкрәй (документта: Чигирей), ихтимал, хәзерге Менделеев шәһәре урынында Тойма елгасы буенда яшәгәндер. Чөнки анда борынгы заманда Чөкрәй исемле татар яшәгәнлеге мәгълүм. Ә исемнәре аталган башка кешеләрнең Тойманың Чулманга койган тамагында – Алабуга янындагы Саралы авылында гомер итүләре күздә тотылган. Архив чыганагында «Салтамыш Милкованов» дип бозылып язылган исемнең дөресе Миркамалов булырга тиеш, чөнки Саралыда Миркамал исемле кеше яшәгән һәм аның улларының исемнәре архив документларында һәм шәҗәрә язмаларында да бар.

1562 елгы документта язылган кешеләр 1582 елда Иж елгасы буен-



Көчек авылы татарларының Иж елгасы буендагы биләмә бәхәсенә багышланган архив эше. 1672 ел

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 1 нче санында.

дагы биләмәләреннән (шул исәптән, Тирсә волостеннан) мәхрүм ителгәннәр. 1582 елда Тирсә волосте патша Иван Грозный фәрманы белән, Багыш морза Яушевка милек итеп бирелгән. Әмма Иж елгасының түбәнрәк өлешенең уң ягы элекке хуҗаларында, ә сул тарафы Салагыш татарлары карамагында калган.

Чуашай Турай улы Ык елгасы буендагы биләмә хокукларын даулаган эшне Мөшеге авылы татарлары дәвам иткән, дип әйткән идек. Алар Ык елгасы буе биләмәләрен ата-бабаларыныкы дип һәм Казан яулап алынгач, Казандагы ясак кенәгәләренә дә аларныкы итеп теркәлгәнен белдергәннәр («...та де вотчина... написана в прежних ясашных книгах после Казанского взятия в первых летех») һәм аңарчы үзләрендә Казан ханы биргән тарханлык ярлыгы саклануын искәрткәннәр. Ык буе биләмәләре Казан алынгач ясак кенәгәләренә язылганлыгы турындагы сүзләрдән нәкъ менә Саралыда яшәгән татарлар исеменә теркәлгән 1562 елгы документ күздә тотылган, дип уйлыйбыз. Чөнки 1562 елларда Минзәлә ягының Мөшеге авылы урнашкан тирәләре руслар хакимлегенә кермәгән һәм андагы ырудашлар исеме белән теркәлә алмаган. XVII гасырдагы тикшерү эшендә Мөшеге кешеләре үзләре дә XVI гасырдагы бабалары Тойма һәм Чөмән елгалары буенда яшәгәнен белдергәннәр бит[1].

3. Биләмә низаглары чыккан вакытларда Турай авылы кешеләре 1567 елдагы грамотаны да дәлил итеп күрсәткәннәр («В 7075 [1567] году по указу Царя... Иоанна Васильевича даны вотчины по Каме реке, по Ику...»). Мөшеге авылы кешеләре дә, тарханлык ярлыгы белән бергә, шул ук 1567 елгы грамотаны кулланганнар: «Деревни Мушуги Акешке Доскееву с товарыщи тою спорною вотчиною по Ику реке, которою владели отцы их и они по крепостям 929 [1523] и 7075 [1567] годов владеть по-прежнему да и по тому им тою вотчиною владеть». Архив эшләрендә 1574 һәм 1577 елгы хокук документлары да искә алынган.

4. Патша Иван Грозный исеменнән 1580 елның 15 сентябрендә «Шихдербеш Миткоманов, Тевкел Токтамышев, Бахтемир Еналеев» исемнәренә Чулман һәм Ык елгалары буендагы биләмә хокукы расланган. Алар документта ясаклы татарлар (чуваше) дип язылганнар һәм күпмедер вакыт башка кеше ия булып торган биләмәләре үзләренә – төп хуҗаларына кайтарылу сәбәбе әйтелгән («...потому что та вотчина старинная их»). Аларның төгәл кайда яшәгәнлеге күрсәтелмәгән. Менә монда исеме аталган Шәехдирбеш Миткоманов дигәне – башка грамоталар һәм шәҗәрәләрдән күренүенчә, Шәехдирбеш Миркамал улы һәм ул 1562 елгы документта исеме язылган Салтамыш Милковановның бертуган кардәше булган.

Бу грамотада әйтелгән «элекке биләмәләре» дигән сүзләр моннан алдагы 1523 һәм 1562 еллардагы документларга бәйле фикеребезне куәтли.

5. Саралы авылының Туктамыш Шәехдирбеш улы һәм иптәшләренә 1595 елның 27 февралендә бирелгән грамотада Чулман елгасы һәм Ык буендагы биләмәләре төгәлрәк итеп язылган һәм алар хәзерге Татарстанның Алабуга, Менделеев, Әгерҗе, Тукай, Минзәлә, Сарман районнарындагы һәм Удмуртиянең Алнаш районындагы территорияләрнең күбрәк яки азрак өлешләрен үз эченә алган.

---

[1] Чулман буенда торган Мең ыруы татарларының рус хакимлеге дәверендә Ык буенда авыллар нигезләп яши башлауларының беренче дулкыны 1640-1650 нче елларга туры киләдер. Риваятьләрдә дә Ык елгасы буендагы, бигрәк тә Минзәлә төбәгендәге авылларның XVII гасырда нигезләнгәнлеге әйтелә. Татарлар анда Чулман елгасының уң һәм сул якларындагы авыллардан күчеп урнашканнар һәм аңарчы электән килгән биләмә чикләрен төгәлрәк итеп билгеләп, рәсми документлар (грамоталар) яздырып алганнар. Мең ыруы вәкилләренең Чулманның ике тарафындагы авыллардан Ык буе биләмәләренә күчүенең икенче дулкыны XVIII гасырның беренче яртысында булган. Ул чорда, гомумән, Казан өязендәге меңнәрчә авылларда яшәгән бик күп халык туган җирләрен ташлап качарга мәҗбүр ителгән.

Бу грамотада әйтелгән Саралы авылы 1562 елгы документтагы Тойма елгасы тамагында яшиләр дигән сүзләргә туры килә. Шул ук документтан, аларның үз биләмәләренә Казан ханлыгы чорыннан хуҗа булганлыгы аңлашыла.

Әлеге ыру татарларының Саралы авылында яшәгәнлекләре соңгырак (1625 елгы һ.б.) грамоталар һәм Н.И.Шишкинның Алабуга тарихына багышланган китабында китерелгән архив чыганагы белән дә раслана. Шишкин китабында 1619 елда Алабуга янындагы Танайка авылы татарларының биләмә чикләрен тикшергәндә Саралы авылы аксакаллары шаһит булып катнашканлыгы тасвирланган («Саралинские деревни старожильцы татаровя... Бисяр Кагтов, Ширзаман Умеленев, Акиней Шедейбышев, Акзат Янзитов, Байгодя Беренгузов»)[2]. Алар Танайка татарлары дәгъва кылган бер өлеш җирне Казан ханлыгы алынганнан бирле буш ята («лежит впусте от Казансково взятья») дип раслаганнар. Шуның белән бергә, Саралы татарларының Казан ханлыгы алынган вакытка хәтле бу тирәдә электән яшәгән «старожильцы» икәнлеге дә раслана. Кеше исемнәре бозыбрак язылган булса да, Шедейбышев дигәне Шәехдирбешевтән үзгәргәнен, Байгодя Беренгузов – Байхуҗа Бәйрәмхуҗа улы икәнлеген чамалау кыен түгел.

6. Тойма елгасы буендагы Татар Чаллысы авылында яшәгән ясаклы татарлар (документта: чуваша) Җанкилде белән Туйкилде Кунакхуҗа уллары һәм иптәшләре исеменә 1623 елның 15 апрелендә биләмә грамотасы алганнар. Шунда ук Җанбәк Кәбәк улының да исеме телгә алынган. Андагы татарларның бер өлеше Тойма елгасы буйлап бераз югарырак – Тогыҗа авылына урнашкан һәм кайберләре Тойма елгасының башына күчеп, Татар Туембашы авылын нигезләгән.

Чаллы авылында яшәгән 41 хуҗалыктагы татарлар 1712 елда бөтенесе дә күчеп киткәннәр һәм авыл бушап калган. 1720 нче елларда ул урынга Саралыдан руслар килеп утырган һәм 1623 елгы грамота алар кулына кергән. Шул заманнан алып руслар яшәсә дә, ул авыл хәзергәчә Татар Чаллысы дип атала.

1712 елда Тогыҗадагы татарлар да Чулман аръягына күчеп киткәннәр. Бер мәхкәмә эшендә чынлыкта да Чулман аръягында, Тогыҗа кешеләре белән бергә, Чаллы авылының 1623 елда исеме теркәлгән Җанкилде Кунакхуҗа улының нәсел дәвамчылары яшәве әйтелгән. Алар, Чулман аръягындагы Игәнә елгасы буенда урнашып, ул төбәкне үзләренең борынгы бабаларыннан килгән үз биләмәләре дип, элекке грамоталарга ишарәләп, патша исеменә үтенеч язганнар һәм шул урында яшәргә рөхсәт алганнар.

Татар Туембашында яшәгән татарлардан Госман Биккенә улы 1764 елда үзенең Саралы волостена бәйле икәнлеген белдергән архив документы бар. Шулай ук аның уллары 1795 елда, Тогыҗа авылындагы нәселдәшләре һәм Сарсаз Тәкермән авылындагы ырудашлары белән бергә, борынгы бабалары Канзафар Муса улы дәвамчылары икәнлеген белдергәннәр һәм бу фактны кардәшләре дә раслаган, чит кешеләр дә таныган.

7. Саралы авылы татарлары, үзләренең Чулман елгасының ике ягындагы төп биләмәләрен раслатып, 1625 елда грамота алганнар. Анда Саралы авылының Туктамыш Шәехдирбеш улы, Тукай Котый улы, Җанбакты Җансәет улы, Сарбаш һәм Бигәш Туймыш улларының исемнәре язылган. Әлеге грамота, 1641 елда янгында харап булганнан соң, 1643 елның 27 февралендә шул ук кешеләр исеменә яңартылган[3]. Документта Саралы кешеләренең җирбиләүче хуҗалар булганлыгын белдерә тор-

---

[2] Шишкин Н.И. История города Елабуги с древнейших времён. – Елабуга, 1901. – С.35-36.

[3] Чулман аръягындагы төбәкләр тарихын өйрәнүчеләр менә шушы – 1643 елның 27 февралендәге грамотада әйтелгән Саралы авылын хәзерге Сарман районындагы Сарайлы (элекке исеме: Сарайлы Бикмәт, архив документларында «Сарали Бикметево») авылы, дип язып ялгышалар.

Саралы авылы кешеләренә 1625 һәм 1643 елда бирелгән биләмә хокукы документын тасвирлаган архив эше. XIX гасыр башы



таковымъ же копии въ коихъ зна-
чатся одни только бортныя угодья
сѣнные покосы звѣриные и рыбныя
ловли большею частию по ихъ [illegible]
отдаточные имъ изъ платежа ясаку
и на помѣстную землю никакихъ
грамотъ и выписей не представлено
кромѣ копии съ грамоты данной
якобы въ 7151 году февраля въ 27
день башкирцамъ деревни Саралы Так-
тамышку Имбердибееву Токат-
ку Кутлееву Янбахтейку Янтемиро-
ву Сарбашку да Бигишку Томана-
евымъ съ товарищи вмѣсто данной
сгорѣвшей во 133 году въ возной грамо-
ты которая отъ бывшаго во 149
году пожара сгорѣла но сия копия
ни кѣмъ не засвидѣтельствована а
потому во уважение оной принять
безъ удостовѣрения справедливости

ган «башкирцы» дигән сословие термины кулланылган. Исемнәре аталган кешеләр 1643 елга хәтле үк Саралыдан күчеп киткәннәр һәм ул тирәдәге биләмәләрен югалтканнар. Туктамыш, Тукай һәм Җанбакты тармаклары – Турай, Әтәс һәм Песәй авылларына, ә Сарбаш белән Бигәш дәвамчылары Бәзәкә авылына урнашкан.

1625 елгы грамотада исемнәре язылган шәхесләрнең ата-бабалары элекке документларда Саралы авылының ясаклы татарлары буларак теркәлгән. Ә 1625 елгы документ нигезендә алар, үз җирләренең төп хуҗалары буларак, «башкорт» катлавына язылганнар[4].

---

[4] Заманына күрә, башкорт булып язылу – электән килгән җир биләмәләрен саклап калу өчен бер чара булган, шулай ук башка төр өстенлекләр дә биргән. Патша хөкүмәте баштарак «башкорт» катлавындагыларны чукындырмаган. Менә бу сәбәп тә көчләп чукындыру сәясәтеннән җәфа күргән халыкларның башкорт дип язылуына этәргеч булган. Шулай ук башкортлардан көчләп рекрут-солдат алынмаган. Архив документларында «из татар башкирцы», «башкирец татарского племени», «тептяри из черемис» кебек язмалар да күп. Хәтта бер үк кешеләр төрле документларда татар дип тә, башкорт дип тә язылган очраклар бар һәм алар милләткә нисбәтне белдерми. Тарихта киң билгеле булган Кара бәк нәселенең дә

8. 1635 елда Тойма елгасы буендагы элекке Шәехдирбеш исеме белән бәйле авыл урынына («Шердербышевская пустошь»ка) Чулман елгасының аргы ягында яшәгән һәм калмык яуларыннан җәфа чиккән ясаклы татарлар Дәүләкәй Акхуҗа улы һәм Айтуган Байкилде улы күчеп урнашкан. Әлеге авыл тора-бара Тойма (Карамалы Тойма) дип атала башлаган. Күчеп кайтучылар Чулман елгасы аръягына элегрәк китеп урнашкан Мең кабиләсе кешеләре булганлыгында шик юк. Чөнки алар Чулман аръягында да шул ыру биләмәсендәге җирдә һәм Тойма елгасы буена кайткач та 1580 елда Саралы кешеләреннән Шәехдирбеш Миркамал улы һәм башка кардәшләренең грамоталар белән расланган биләмәсендә төпләнгәннәр.

9. Казан өязе Җөри даругасындагы Балтач авылының ясаклы татарларына (чувашам) 1637 елның 3 февралендә бирелгән документта Чөмән (документта: Учюмень) елгасы буендагы биләмәләре расланган. Аларның Чулман елгасы аръягында һәм Ык буенда да биләмәләре булуы искәртелгән. Документта исемнәре күрсәтелгән кешеләрнең («Алакайка Тявкеев, Тявгидейка Тявкеев, Карманка Шихдербышев, Балтачка Сапарюзев, Ахпайка Басубин, Ядчек Тараев»), архив документлары һәм шәҗәрә язмалары белән, Саралы авылында яшәгән Мең кабиләсе вәкилләре булганлыгы раслана. Бу документта аталган Балтач дигән авыл хәзерге Менделеев районындагы Песәй авылы, ягъни аның элекке исеме[5].

10. Бәзәкә авылында электән яшәгән татарлар Чулман аръягындагы Байлар авылына күчеп киткәч, 1639 елда Исәнгол һәм Ырыс Сарыбай уллары, Таңай Бигәш улы, Акбулат Актый улы – Мең ыруына караган барлыгы дүрт гаилә шунда килеп урнашканнар. Алар 1642 елда үзләренең Бәзәкә авылы тирәсендәге биләмәләренә рус патшасы исеменнән рәсми документ («оберегательная память») алганнар һәм 1643 елда балык тоту урыннарына хуҗа булу турындагы хокукларын раслатканнар. Исәнгол белән Ырысның этиләре – Саралы авылы кешеләренә 1625 елда бирелгән һәм 1643 елда яңартылган грамотада теркәлгән Сарбаш Туймыш улы дигән кеше. Таңайның этисе Бигәш тә шул ук Туймышның икенче улы.

Исәнгол Сарыбай улы үзе яки дәвамчылары Ык елгасы буендагы биләмәләренә

бер тармагы башкортларның Җәнәй ыруы буларак билгеле. XVII гасырда ук менә шул Җәнәй ыруының хәзерге Әгерҗе районы территориясендәге авылларда яшәгән кайбер вәкилләре – «башкорт» дип, ә икенче бер кардәшләре «татар» дип язып йөртелгән.

Хәзерге башкорт галимнәре һәм милләтчеләренең ялгыш карашынча, патша заманнарындагы рус документларында «башкорт» дип язылган бөтенесен чып-чын башкорт халкы дип тәңгәлләштерү, шул ук чор документларында «татар» дип язылган барлык халыкларның да асылда татар булуын дәгъва итүгә охшаш булыр иде. Әмма безнең галимнәр дә, милләтчеләребез дә, шөкер, Кавказдагы, Урта Азия һәм Себер-Алтай киңлекләрендәге элек «татар» дип аталган, рәсми кәгазьләргә дә шулай язылган күп халыкларны һәм төрле кавемнәрне хәзерге татарлар дип тәңгәлләштерергә маташып хаталанмыйлар.

[5] Турай Шәехдирбеш улының исеме теркәлгән нәсел шәҗәрәләре Башкортстанда татарлар яшәгән төбәкләргә һәм Татарстанның Баулы якларына да бәйле. Төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең мәгълүматларына нигезләнеп, М.Әхмәтҗанов Шәехдирбеш бабайның Баулы ягындагы дәвамчылары XVII гасырда Казан өязенең Җөри юлындагы Балтач авылыннан килгән ясаклы татарлар дип язды (Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре: I том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012. – Б.266). Ләкин аның Балтач авылын хәзерге Татарстандагы район үзәге яки Әгерҗе районындагы Балтач авылы белән бәйләргә омтылышы дөрес түгел. Чөнки, беренчедән, Әхмәтҗанов фаразлаган ике Балтач та административ бүленеш буенча беркайчан да Җөри юлына (даругасына) кермәгәннәр. Ә иң мөһиме – Турай нәселенә бәйле, Балтач исеме белән аталган авыл хәзерге Менделеев районындагы Песәй авылы булган. Ягъни Турай бабайның кардәшләре яшәгән Песәй авылы башта Балтач дип аталган. Моны архив документы ачык раслый: «...владеют по грамоте 7145 [1637] года февраля 3 дня, данной деревне Балтасевой, что ныне Псеева чувашем» (Россия дәүләт борынгы актлар архивы, 1324 фонд, 1 тасвир, 1202 саклану берәмлеге, 2, 142 кәгазьләр).

Галим Д.Исхаков та Байлар волостенда яшәгән кешеләрнең бер өлеше Җөри даругасының Балтач авылы ясаклы татарлары булып, аннан соң 1680 нче елларда Турай авылында пәйда булулары турында язды. Ләкин ул нинди һәм кайдагы Балтач авылы күздә тотылганын тәгаенләмәгән (История татар с древнейших времён. В семи томах. Том V. – Казань, 2014. – С.308). Кайбер тикшеренүчеләрнең хәзерге Балык Бистәсе районындагы Балтач (Юлсубино) булмадымы икән дигән фаразлары да нигезле түгел.

күчеп урнашканнар булса кирәк, Бәзәкә авылында аларның дәвамчылары билгеле түгел. Ә хәзерге Азнакай районындагы Чалпы һәм башка авылларда яшәгән татарларның нәсел шәҗәрәләрендә борынгы бабалары Исәнгол Сарыбай улының исеме әйтелгән. Алар шулай ук әүвәлге грамота алган бабаларыбыз дип 1625 һәм 1643 еллардагы Саралы авылы татарларына бирелгән грамотадагы кеше исемнәрен теркәп йөрткәннәр.

XVIII гасыр ахыры һәм XIX гасыр башында Бәзәкә авылында Чалпы кешеләре озак еллар дәвамында имам булып торуы да очраклы дип кенә карарга кирәкми. Шуның кебек үк, Песәй һәм Татар Сарсазы авылларында Тәкермән кешеләре, Татар Туембашында Чулман аръягында туып-үскән укымышлылар XIX гасырда имам булганнар. Менә бу фактлар да әүвәлге кардәшлекне күрсәтә.

Ык елгасы буенда XVII гасыр ахыры-XVIII гасыр башларында Бәзәкә авылының ясаклы татарлары да оброкка биләмә алып торганлыгы билгеле.

11. Элегрәк Саралы авылының ясаклы татарлары (документта «чювашенин») Аксәет Сүтәев белән Бәйрәмхуҗа Балтач улы исемнәренә язылган биләмә грамотасы, алар үлгәннән соң 1641 елда балаларына: Бәйрәмхуҗаның улы Тугыҗак һәм кардәшләре исеменә яңартылган. Анда биләмәнең чикләре тәфсилләп күрсәтелгән. Документта ул биләмәләрнең элек ясаклы татар Шәехдирбеш исеменә теркәлгән булуы әйтелгән.

Архив документында теркәлгән Тугыҗак Тойма елгасы буендагы Тогыҗа авылында яшәп, аның исеме авылга да атама булып калган.

Элекке грамоталарда исемнәре теркәлгән Аксәет Сүтәй улы һәм Тугыҗак токымнары 1712 елда Чулман аръягындагы элекке биләмә җирләренә күчеп урнашканнар. Архив документларыннан күренгәнчә, анда күчүчеләрдән төп кешеләрнең берсе Бикмәт Урсай улы Аксәет Сүтәевне үзенең борынгы бабасы дип белдергән. Хәзерге Сарман районындагы Сарайлы исемле авылның Сарайлы-Бикмәт дигән иске атамасы, ихтимал, шушы Бикмәт Урсай улына бәйле булгандыр.

12. Сарман яклары тарихын тәфсилләп өйрәнгән Дамир Гарифуллин «XVIII гасыр ахырында да әле Саклаубаш, Өчөйле Саклау, Иман (хәзерге Иске Имән), Сарсаз Тәкермән, Чураш, Сарайлы-Бикмәт, Сөлек, Абдул, Сәет, Сәмәкәй, Күгәш, Каташ Каран, Теләнче Тамак, Сарман, Рангазар авылы кешеләре үзләрен әнә шул Туктамыш [Туктамыш Шәехдирбеш улы] һәм аның иптәшләренең дәвамы дип исәпләгәннәр», дип яза[6]. Ул шулай ук «Сарсаз Тәкермән, Дими Тарлау авылларында Туктамыш нәселен дәвам итүчеләр бүген дә яшиләр», дип, шул нәселгә нисбәтле кешеләрнең XX гасырдагы фоторәсемнәрен дә бастырды[7].

Алабуга янындагы Саралы авылына карата Д.Гарифуллин, XVIII гасыр турында хикәяләп, «мондагы татарлар чукынырга теләмичә төрле урыннарга күченеп утыралар. Хәзерге Тукай районы җирендәге Яңа Сарайлы, Сарман районындагы Сарайлы (Сарайлы-Бикмәт) авыллары әнә шулвакытта барлыкка килгәннәр», дип яза[8].

Ахыры бар ■

[6] Гарифуллин Д. Сарман районы энциклопедиясе: 2 китап. – Чаллы, 2006. – Б.30-31.
[7] Шунда ук. – Б.56-57.
[8] Шунда ук. – Б.100-101.

Мәрҗани ул – Тимерказык!

Узган елның азагында Г.Тукай исемендәге Арча педагогика колледжы – Милли кадрлар әзерләү үзәгендә Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңаеннан республика фәнни-гамәли конференциясе узды. Педагогик юнәлештәге урта махсус белем бирә торган уку йортлары студентлары белән бергә, булачак авыл хуҗалыгы белгечләре, нефтьчеләр, бухгалтер, сәүдә-таможня хезмәткәрләре һәм тимер юлчыларның да олуг мәгърифәтче турында фикер әйтүләре, аның тормыш юлы, иҗаты белән кызыксынулары һәм чыгыш ясаулары – тарихи бер вакыйга. «Ташка басылып калсын», – дип, конференциядән кайбер докладларны сезнең хозурга да тәкъдим итәбез.

Шәйхәйдәрова И., М.Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы студенты; Гыймадиева А., җәмгыять белеме фәне һәм тарих укытучысы

МИНЗӘЛӘ ӨЯЗЕНДӘ Ш.МӘРҖАНИ ШӘКЕРТЛӘРЕ

Ш.Мәрҗәни Ташкичү авылында, Бохара һәм Сәмаркандта, соңрак Казанга кайтып, анда кырык ел имам булып торганда укыту белән мәшгуль булган, 16 яшеннән башлап 74 яшенә кадәр аның дәресләре бик күпләрнең дөньяга күзен ачкан. Галимнең шәкертләре Пенза, Саратов, Самара, Сембер, Казан, Вятка, Уфа, Оренбург, Тубыл,

Томск, Санкт-Петербург, Рязань, Кострома һәм Тамбов төбәкләрендә остазларның традицияләрен дәвам итеп, аның педагогик мирасын гамәлдә кулланган.

XX гасыр башында Минзәлә төбәге хәзерге берничә районның территориясен берләштергән зур өязне тәшкил иткән. Биредә без анда туган, яшәгән, халыкка фидакарь хезмәт иткән, Ш.Мәрҗанидән белем алып, аның белән аралашу нәтиҗәсендә гыйльми хезмәт калдырган яки башка бер әһәмиятле эше белән танылган шәхесләрне искә алабыз.

1. **Минһаҗетдин бине Әбелмөгаллим** – Вәрәш (хәзерге Мөслим районы) авылыннан. Ул Мәрҗани мәдрәсәсендә озак вакытлар белем эстәгән. Мәдрәсәдән чыккач, яхшы гына дәрес укыткан, төбәкнең алдынгы имам-мөдәррисе һәм ахуны булган, иң яхшы мөгаллим, туры фикерле шәхес булып танылган.

2. **Хөснетдин бине Сираҗетдин**. Бу мәшһүр зат Мәрҗани мәдрәсәсендә укып, озак вакытлар мәдрәсәдә хәлфә булып торган. Аннан сон, Тәкермән авылына имам булып, зур тырышлык белән дәрес укыткан. Хөснетдин хәзрәт – тирә-юньдә яхшы хезмәт итүче шәкертләре байтак булуы белән билгеле шәхес.

3. **Миргаләветдин бине Әбелмөгаллим.** Ул Вәрәш авылыннан булып, алда язылган Минһаҗетдин хәзрәтнең туганы. Мәрҗани мәдрәсәсендә укып, озак вакытлар хәлфә булып торган. Дөньяви белемнәрдән яхшы мәгълүматлы, укырга ихласлыгы булганга, анын дәресләреннән күп шәкерт файда алган. Мәдрәсәдә «Миргали хәлфә» дип танылган. Аннан соң Мәллә Тамак авылында (хәзерге Мөслим районы) имам була, күп китап яза. Миргаләветдин хәзрәт үз мәдрәсәсендә укытуны заманча итеп, тиешле дәрәҗәгә җиткереп башкарырга тырыша.

4. **Хафиз бине Шаһиморат.** Бу шәхес Мәрҗани мәдрәсәсенең алдынгы шәкертләреннән саналып, төрек матбугаты белән кызыксынган, мәдрәсәдә математика дәресләре алып барган. Соңрак Кормаш (хәзерге Актаныш районы) авылында имам булып, тырышып укытырга керешкән. Хафиз хәзрәт үз шәкертләренә авыл халкы өчен әһәмиятле булган һөнәрләрне дә өйрәтеп калдырган. Аның мәдрәсә тәртипләрен саклауга зур игътибар биргәнлеге мәгълүм.

5. **Кәшшафетдин бине Шаһимәрдан** – Сөлек (хәзерге Сарман районы) авылыннан. 1883-1892 елларда Мәрҗани мәдрәсәсендә белем ала. Мәрҗанинең аңа «Хизамәтел-хәуаши» исемле күләмле әсәрен төзәтеп бастырырга васыять иткәнлеге билгеле. Кәшшафетдин хәзрәт бу эшне җиренә җиткереп башкара. Башта туган ягында, ә аннары Каркаралы (хәзер Казакъстанның Караганда өлкәсе) шәһәренә барып, Кунанбай хаҗи мәчетендә мөгаллим һәм имам була, күренекле казакъ акыны булып танала. Аның казакъ телендә язган 100дән артык әсәре бар. Иҗади мирасы төрле әдәби кыйсса, тарихи поэма, дәреслек һәм тәрҗемә әсәрләрне тәшкил итә. Күренекле якташыбыз 1898 елда шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнинең шигырьләрен туплап, Казандагы Кәримовлар матбагасында «Китабы мөһиммәт әз-заман» дигән җыентык та чыгара.

6. **Шәйхелислам бине Хәмидулла эт-Тәкәви.** 1869 елның 20 сентябрендә хәзерге Чүпрәле районына караган Татар Төкесе авылында морзалар гаиләсендә туа. Дөрес, бу олуг затка Ш.Мәрҗанинең үзен күререргә насыйп булмый. Аның каравы, ул Мәрҗани мәдрәсәсендә биш ел укып (1904 нче елда тәмамлый), «Мәдрәсәи Госмания»дә мөгаллим була. Соңрак Минзәлә өязендәге Яхшыбай (хәзерге Сарман районы) авылында имам һәм мөдәррис булып, тырышып хезмәт итә. 1911 елда вафат була. Аның турында зирәк, кыю фикерле кеше иде, дип искә алалар. Галимнең «Иткан фи тәфсирел-Коръән» исемле китабы күпләргә мәгълүм. «Мохтәсарел-Кодури» исемле китапны тәрҗемә итүе дә билгеле.

Сәфәрова О., Казан сәүдә-икътисад техникумы студенты; Приходько О., методист

Ш.МӘРҖАНИ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ АЛТЫН УРДА ТАРИХЫНА БӘЙЛЕ ЧЫГАНАКЛАР

Ш.Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар...»нең беренче томында бүгенге татар халкының тамырлары итеп кыпчак, болгар һәм татарны китерә. Чыңгыз хан һәм аның уллары турында язганда, аларның «төп нәселләре татар түгел, магул», дип ассызыклап үтә, Алтын Урданың бөек дәүләт икәнлеге, бик күп җирләрне, шул исәптән урыс кенәзләрен дә буйсындырып торганлыгы турында яза. Алтын Урдадагы бөек галимнәрне, ханнарны һәм башка мәшһүр шәхесләрне дә онытмый.

Мәрҗанинең тарихи карашлары, фикерләве һәм кулланган тарихи ысуллары нинди булган соң? Галим чыганаклардан өзекләр генә китереп калмый, ә аларны чагыштыра, анализлый да. Язма чыганаклар белән бергә, ул иске татар акчаларын, кабер ташларындагы язуларны, гади халыкта таралган тарихи риваятьләрне дә өйрәнә. Әсәреннән күренгәнчә, Ш.Мәрҗани урыс чыганакларыннан да хәбәрдар булган. Мәсәлән, Куликово кыры, Угра елгасы буе һәм татар-рус мөнәсәбәтләренә кагылышлы башка вакыйгаларны тасвирлаганда рус тарихчыларының хезмәтләрен файдаланган.

Галимнең борынгы татар чыганакларын өйрәнүе аеруча әһәмияткә ия. Мәсәлән, ул Алтын Урдадан калган ике документны үз язмасында тулысы белән китерә. Болар – Тухтамыш ханның Польша-Литва короле Ягайлага язган хаты һәм Тимер Котлык ярлыгы.

Ш.Мәрҗани халык арасында таралган фикер һәм мәкальләрне дә китереп, вакыйгаларны җанлы итеп сурәтли. Мәсәлән: «Нугай халкында дин Үзбәктән таралды», дигән сүз танылган», – дип әйтә яки «Идел туңса, кем кичмәс, Идегәй булса, кем китмәс», дигән әйтемне искә алып, Идегәй фетнәсе турында шактый объектив яза.

«Мөстәфадел-әхбар...»нең Алтын Урда тарихы буенча язылган өлешендә иң күп кулланылган чыганакларның авторлары: Ибне әл-Вәрди, Нәбакти, Әбелгали хан, Ибне Гарәбшаһ, Рәшид әд-дин, Ибне Халдун, Ибне Баттута, Мәхәммәд Риза әфәнде һәм башкалар. Билгеле булганча, әлеге чыганаклар бүген дә иң әһәмиятлеләрдән санала.

Ш.Мәрҗани ханнар исеменә бәйле нумизматика материалларын да киң куллана: Сарай, Болгар, Кырым, Урда, Гөлестан, Хаҗитархан, Азак, Маҗар, Хәрәзем шәһәрләрендә сугылган акчалар турында әйтеп үтә. 23 ханның үз исеме белән суккан акчасы барлыгы турында яза, «тәңкәләре күп табыла», дип белдерә.

Галим Алтын Урданың җимерелүендә Аксак Тимернең өлеше гаять зур икәнен әйтә. Мәрҗанинең Тимергә карашы бик тискәре, аның явы турында язганда ул фикерен шулай тәмамлый: «Тимер, бу мәмләкәтне талап, үтереп, әсирләр алып, утта яндырып, бөтенләй харап итеп, татар дәүләтен бөтенләй көчсезләндереп, зур тәфрика (бүлү, таркату) вә ихтилаф (каршылыклар) булды».

Әлбәттә, Ш.Мәрҗани, чын тарихчы буларак, Болгарны да, Алтын Урданы да, башка дәүләтләрне һәм чорларны да идеаллаштырмаган. Ул илнең бөлгенлеккә төшүенә мәгърифәтнең түбәнәюе, үзара җәнҗал, ызгыш-талашларның һәм тышкы дошман яуларының сәбәпче икәнен күрсәтә. Гомумән әйткәндә, «Мөстәфадел-әхбар...»дәге тарихи концепция бүгенге татар урта гасыр тарихы белән шөгыльләнгән профессиональ тарихчыларның карашлары белән тәңгәл килә.

Григорьева И., Н.В.Лемаев исемендәге Түбән Кама нефтехимия һәм нефть эшкәртү көллияте студенты, Шәрифуллина Э., татар теле һәм әдәбият укытучысы

МӘРҖАНИ ҺӘМ АНЫҢ ДАИРӘСЕ

Ризаэддин Фәхреддин, Җамал Вәлиди, Зәки Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, аңа бәя биреп: «Ул – тарихыбызның таң йолдызы, тарихыбызның атасы», «Төн никадәр караңгы булса, йолдыз шулкадәр яктырак яна», «Ул караңгы дошман лагеренда батыр көрәшче булды», – дип язалар. Мәрҗанигә багышлап 25 әдип, шулар рәтеннән бөек Тукай да шигырьләр, мәдхияләр, мәрсияләр язган. Бу бәяләр галимнең фәнни хезмәтләре өчен генә бирелмәгән. Аның иҗтимагый эшчәнлеге, вәгазьләре һәм төрле бәхәсләрдә җиңеп чыгуы, шәкертләре белән эшләве – боларның һәрберсе җәмгыятькә зур йогынты ясаган.

Мәрҗани аралашкан беренче даирә – шәкертләре һәм хәлфәләре. Мәдрәсә тормышы мәхәллә көнкүрешеннән үзенә хас үзенчәлекләре белән аерылып торган. Шәкертләрнең күбесе мәдрәсәдә торып, күмәк тормыш алып барган. Алар, Казанның үзеннән яки губернасыннан гына булмыйча, татар халкы яшәгән төрле төбәкләрдән (Шәһер Шәрәфнең санавынча, 16 төбәктән) җыелган. Мәрҗани эшли башлаган вакытта аның мәдрәсәсендә 65 шәкерт исәпләнә. Алар, белем дәрәҗәләре төрлечә булып, төркемнәргә бүленгән. Укытуны аерым китаплар буенча хәлфәләр алып барган, мөдәррис, төп юнәлеш бирүче буларак, шәкертләр һәм хәлфәләргә лекция укыган. Шәкертләр, бигрәк тә ярлылары, башка мәдрәсәләрдәге кебек үк, садака җыярга, үлем-җеназа биремнәре алырга, ясин укып, мәҗлесләргә йөреп акча эшләргә тырышкан. Билгеле булганча, ул вакыттагы мәдрәсәләрдә шәкертләрнең моназарәләре (бәхәсләре) еш оештырылган. Әмма Мәрҗани шәкертләрен тел чарлау өчен түгел, ә акыл куәтен үстерү өчен укытырга омтылган. Шулай да олуг галим үз шәкертләреннән риза булмаган, ягъни зур белемле, атаклы шәхесләр әзерләп чыгара алмадым, дип, үзе үк әйткән. Дөрестән дә, Мәрҗанинең шәкерте булган мулла-мөдәррисләр күп булса да, үзе кебек галим шәхесләр Х.Фәезхановтан башка күренми. Ләкин, гомумән алганда, ул яңа буын укымышлыларын булдыруга зур хезмәт куйган.

Мәдрәсәнең укымышлы хәлфәсе Сафиулла хәзрәт, мөдәрриснең олы кызы Галиябанатка өйләнеп, аның кияве һәм ярдәмчесе булып киткән. Икенче кызы – Казан имамы Габдулла Апанаевның җәмәгате. Ул әзерләгән имамнар арасыннан Фәсахетдин Мөхетдин углы, Шакирҗан Таһири, Габбас Әшраф углы Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган, Габдрахман Исмәгыйль углы Гомәров Әстерханда «Идел» газетасын чыгарган.

Мәрҗанинең фәнни җәмәгатьчелек белән аралашуы да игътибарга лаек. Галимнең Татар укытучылар мәктәбен ачканда чыгыш ясавы, «Тарих, археология һәм этнография» җәмгыятенең IV съездында докладлар белән катнашуы, Радлов, Катанов, Готвальд, Казыймбәк (Казимбек) һәм Х.Фәезханов аркылы Вельяминов-Зернов кебек зур галимнәр белән хезмәттәшлеге күпләргә мәгълүм. Шиһаб хәзрәтнең өязкалалардагы алдынгы имам-мөдәррисләр белән гыйльми мәсьәләләр буенча фикер алышуы, хатлар язып, тарихи-фәнни хәбәрләр соравы, шәҗәрәләр җыюы да игътибарга лаек. Ә инде чит илләрдә исеменең һәм хезмәтләренең танылуы, безгә калса, әлегә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, ул ачык мәсьәлә булып кала. ■

«Милләтне без тергезик!»

Гүзәл Төхфәтова

Габделгазиз Габдерахман улы Монасыйпов (1888-1922) – тарих сукмакларында югалып калган прозаик, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе. Совет хакимиятенең дошманы саналган бу шәхеснең тормыш юлы, сәясәт, мәдәният, әдәбият һәм матбугат өлкәсендәге күпкырлы эшчәнлеге соңгы дәвергәчә өйрәнелмәде, бары тик 90 нчы елларда гына Т.Әйди, З.Рәмиев тарафыннан биографиясенә, әдәби иҗатына кагылышлы мәгълүматлар тупланып, аерым мәкаләләр булып басылып чыкты. Г.Халит, Н.Гыйззәтуллин, Р.Ганиева, Ф.Бәширов, Д.Заһидуллина, Ф.Галимуллин, Г.Төхфәтова хезмәтләрендә әдипнең «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» (1918) романы турында кайбер фикерләр әйтелде.

ТУУЫ, НӘСЕЛ-НӘСӘБЕ

Г.Монасыйпов 1888 елның 21 ноябрендә (яңа стиль белән 3 декабрь) Татарстан Республикасының хәзерге Арча районына кергән Яңа Тазлар (хәзерге Байкал) авылында мәзин Габдерахман Галәветдин улы гаиләсендә дөньяга килә. Тугыз бабасының исеме билгеле: **Илкәй – Буҗак – Өрмәк – Котла – Имәнәти – Имәнкол – мелла Муса – Монасыйп – Галәветдин – этисе Габдерахман – улы Габделгазиз**.

Анасы яшьли үлеп, Габделгазиз үги ана кулында тәрбияләнә. 1902 елда язмыш аны Көнчыгыш Төркестанга, таранчылар (уйгырлар) арасына китереп чыгара. Г.Монасыйпов 1908 елга кадәр Голҗа шәһәрендә яши. И.Рәми аның биредә укытучы булып эшләвен хәбәр итә[1]. Туган ягыннан аерылган егет аннан соң өч елга якын Ташкентта гомер итеп, 1911 елда Казанга кайта. Янә өч елдан ул хәрби хезмәткә алына һәм анда гаскәри мулла вазыйфасын башкара.

Г.Монасыйповның шәхси тормышы хакында мәгълүмат бик аз. Аның хатыны мәшһүр драматург Галиәсгар Камалның сеңлесе, ТАССРның атказанган артисты Зәйнәп Камалова (1899-1977) булуы билгеле.

Әдипнең туганнары төзегән нәсел шәҗәрәсен һәм Арча районының Байкал авылы зиратында Монасыйповларга мөнәсәбәтле кабер ташларының фотосын **beznenmiras.ru** сайтында (QR код буенча да таныша аласыз) урнаштырабыз.

ИҖАТЫ

Г.Монасыйпов исеме матбугатта беренче тапкыр 1906-1907 елларда «Фикер» газетасы битләрендә урын ала. Балаларны белем алырга өндәгән шигырен, байлар тарафыннан рәнҗетелгән приказчикларга багышланган мәкаләсен, Голҗа байларының карта уйнарга һәвәсләнүен, мәктәпләргә булышмауларын фаш иткән язмаларын ул Голҗа шәһәреннән ватанына җибәреп тора.

1910-1912 еллар дәвамында Габделгазиз шагыйрь буларак ачыла. Аның «Шура» журналында һәм «Бәянелхак» газетасында унлап шигыре басыла. Шигъриятендә милләт өчен янып яшәү, халык язмышын йөрәк хисе аша үткәрү, бәхетле киләчәккә тирән ышаныч чагыла. **«Шагыйрьгә...»** (1910) шигырен татар халкының киләчәген,

[1] Рәми И.Г. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияты буенча кыскача белешмәлек) / Рәми И.Г., Даутов Р.Н. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – Б.178.

Габделгазиз Монасыйпов һәм хатыны Зәйнәп Камалова. 1918 ел

ил язмышын кайгыртып язылган әсәр дип атарга була. Биредә автор шагыйрьләргә мөрәҗәгать итә, сүзнең һәм телнең көч-куәт, милләтне тергезүдә корал икәнен дәлилли:

«Сүз белән дөньяга шау-шу бер салыйк,
Уңга-сулга бакмыйча алга барыйк.
Гомре аз калды дигән милләтне без
Тергезик – дөньяда калсын исмемез.
Йир йөзе белсен татарларның барлыгын,
Бу заманда аңа дәүләт ярлыгын».

Г.Монасыйповның мәхәббәт турында **«Берәү»**, хезмәт темасын яктырткан **«Икмәк»**, кешенең хис-кичерешләрен сурәтләүгә багышланган **«Кайгы»** (1911), иптәшлек һәм дуслык хакындагы **«Иптәш»** (1912), тәвәккәллек өчен мөһим булган

сыйфатларга дан җырлаган **«Чыдамлык һәм теләк»** (1910) һ.б. шигырьләре дә бар.

Г.Монасыйпов 1912-1913 еллардан драма һәм проза жанрларына өстенлек бирә башлый. Бу вакытларда аның «Имчеләр корбаны» һәм «Ышанычсыз юлга бер адым» исемле ике драма әсәре, «Өзелгән өмид» повесте дөнья күрә, мәшһүр «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» исемле романы языла башлый.

«Өзелгән өмид» (1913) повестенда вакыйга XX гасыр башында бара. Әсәр шәһәр бакчасын, андагы «шагыйранә манзаралар»ны сурәтләү белән башланып китә, бакчадагы иркенлекне, сулыш алу өчен рәхәтлекне, табигать хозурлыгын бәян итә. «Күңел ачып, саф һава йотып» кайтучыларның күбесе яурупалылар булуы, биредә татарларның аз күренүе сөйләнелә. Моның нигезендә татар халкының борынгыдан килгән гадәтләре, канунлаштырылган ирексезлеге ятуы аңлашыла.

Повестьның үзәгендә – Сара язмышы. Ул – төскә-биткә бик чибәр, азрак русча да укыган һәм заманы өчен шактый иркен үскән кыз бала. Сюжет сызыгы Сараның әхлаксыз бәндәгә алдануы һәм шулай итеп бәхетсезлеккә таруы, хурлыктан котылыр өчен үз-үзен үтерергә омтылуы белән бәйле вакыйгаларны үз эченә ала. Сараның бәхетсезлегенә «эчендәгесе тышында бер кыз булуы», беркатлылыгы, тәҗрибәсезлеге һәм кызның шәһәр бакчасындагы әхлаксыз гамәлләре (дусларыннан, туганнарыннан аерылып, таныш булмаган ике әфәнде белән «култыклашып агач арасына китү, озын үләнле, караңгы, куе агачлы җиргә җитү, «квас» килү, аннан бераз эчү, төрле сүзләр сөйләшеп бераздан мөһим мәсьәләгә күчү, әфәнденең мөселманлыкка чыгарга ризалыгын ишетү, аның фидакарьлегенә исе китү, бераздан белешмичә муенына сарылуга кадәр эш җитү...») сәбәпче була. Г.Монасыйпов яшь кызның авыр сынауларга дучар булуында беркатлылык кебек сыйфатның һәм XX гасыр башы мохитенең тәэсирен күрә.

«Таранчы кызы яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» романы (1918) – авторның иң күренекле әсәре. Г.Монасыйповта, Голҗадан Казанга кайтып төшкәч, «сан җәһәтеннән күп булмасалар да, төрек-татар милләтенең иң зирәк вә мәдәниятккә кабилиятле бер кисәге булган таранчыларның хәятләре вә кыска гына булса да тарихлары, гореф-гадәтләре җентекләнергә тиешлеген» күздә тотып, «таранчылар арасында торган вакытта ишеткән вә хәтерендә саклаганнарны» язу фикере туа. Әмма эш 1912 елның декабрендә генә башланып китә. «Бәгъзе бер сәбәпләр» һәм Беренче Бөтендөнья сугышы «Таранчы кызы...»на нокта куелуны чигендерә килә, әсәр 1915 елның урталарында гына тәмамлана. Роман аннан соң да тиз арада нәшер ителә алмый, укучылар аның белән танышу мөмкинлегенә бары тик 1918 елда гына ирешә.

Г.Монасыйповның «Таранчы кызы...» романы композицион яктан шактый үзенчәлекле: әсәрдә әдәби һәм публицистик катламнарның синтезы күзәтелә. Романтик әсәрдә әдәби катлам Казан тарафыннан Шәркый Төркестанга килеп урнашкан татар егете белән яшь уйгыр кызы арасында кабынган мәхәббәтне тасвирлауга багышлана. Романның икенче катламы – таранчылар, кытайлар, калмыклар хакында бирелгән тарихи-этнографик мәгълүмат.

Автор китапның сүз башында болай ди: *«Үз халыкларын башкалар золымыннан, үз туфракларын ятларның пычрак аяклары астында тапталудан коткару юлында шәһит булган таранчы каһарманнары рухына багышлана»*. Әлеге эпиграф әсәрнең эчтәлеген тулысынча ачып бирә.

1913 елда Габделгазиз Монасыйповның ике драма әсәре дөнья күрә. **«Имчеләр корбаны»** исемле бер пәрдәлек пьесасы, әле басылып чыкканчы ук, 1912 елда «Сәйяр» труппасы тарафыннан Казан сәхнәсенә менә. 1913 елда аны Буа яшьләре дә сәхнәләштерергә әзерли, ләкин патша хакимияте аларны куып тарата. Әсәр 1918-

Г.Монасыйповның әтисе «Габдерахман мәзин Галәведдин углы» (1864-1930) каберенә куелган таш

Габделгазизнең әнисе «Бибисабирә Әхмәдгалләм кызы» (1866-1890) каберенә куелган таш

1919 елларда М.Фәйзи оештырган яшьләр түгәрәге көче белән Җүкәйдә һәм Юлыкта куела. Драманың үзәгендә – искелек һәм яңалык көрәше. Пьесада конфликт чахотка белән авыручы егерме яшьлек Хәсән образы, аның тормышы аша ачыла. Иске карашлы әнисе белән агасы Гариф егетне табиб китертеп дәвалауга каршы төшә, аны күкрәгенә авыр кургашыннар бастырып куеп, тәлинкә юган салкын су эчертеп терелтмәкче булалар. Ырымнар белән дәвалау аянычлы нәтиҗәгә китерә – укымышлы, акыллы егет Хәсән үлә. Ул үзенең сәламәтлеге, киләчәге өчен көрәшми. Әлеге образ, безнең карашыбызча, артык мескен кыяфәттә бирелгән. Ул: «Мин нишли алам соң?» – дигән сорау бирүдән һәм әнисе белән агасының төрле имчеләргә ышануларына зарланудан ары уза алмый.

Г.Монасыйповның икенче сәхнә әсәре – **«Ышанычсыз юлга бер адым»** (1913) исемле дүрт пәрдәлек драма. Ул Әстерхан һәм Омск сәхнәләрендә уйнала. Драмада авыр тормыш шартларына, хокуксызлыкка, рәнҗетүләргә түзә алмыйча тормыш төбенә тәгәрәгән, фахишәлек юлына баскан хатын-кыз образларын сурәтләү үзәккә алына. Әсәрдә, ирексезләп, үги ана хәйләсе белән җаны-тәне тартмаган бер байның исерек угылына кияүгә бирелгән Сәлимә язмышы бәян ителә. Ире эчә, чит хатыннар белән чуала, Сәлимәне кыйный. Яшь хатын беркемнән дә яклау таба алмый: әти-әнисе ачулана, хәзрәт: «Күп такылдама! Ир булсын да, кыйнамасын да, имеш. Үзеңнең килешмәгән йирләрең бардыр. Югыйсә, кыйнамас иде», – дип кенә җавап бирә... Рәнҗетелүләрнең соңгы чигенә җиткән, чарасызлыктан ни кылырга белмәгән Сәлимәгә яшь хатыннарның «кулларына сары пачпорт тоттырып», аларны урам хатынына әверелдерүче карчык очрый. Ул төп геройны «ышанычсыз юлга бер адым» ясарга этәрә.

Г.Монасыйповның 1913 елда, татар халык шагыйре Габдулла Тукай вафат булгач, аңа багышлап язылган «Тукай хатирәсе» исемле мәкаләсе басылып чыга. Язмада автор шагыйрьне җирләү мәрасименнән репортаж бирә: *«Без ул табутны мәкъбәрәгә кадәр*

илттек. Анда әллә нәрсәләр булды, халык бер шаулады, бер тып-тын торды. ... Мин дә шул халыкның арасында идем. Икенче төрле итеп әйтсәм, якынрак, алдындарак та идем»[2]. Г.Монасыйпов шул ук мәкаләдә 1911 елның ахырында Казандагы «Новый клуб»ның иске бинасында Г.Тукай белән беренче мәртәбә күрешүен дә искә ала.

1913-1917 еллар татар вакытлы матбугатында Г.Монасыйповның театр, драматургиягә багышланган тәнкыйди мәкаләләре («Артист кисәкләре», «Татарча театрлар» һ.б.), яңа нәшер ителгән китапларга рецензияләре басыла. Ул рус язучысы И.И.Мясницкийның «Мәхәббәт өчен сугыш» комедиясен дә иҗади тәрҗемә итә. Пьеса беренче тапкыр 1913 елның 19 июлендә Панаевлар бакчасында сәхнәләштерелә һәм тагын 1914, 1916 елларда уйнала[3], 1914 елда Казанда аерым китап булып басылып чыга.

Габделгазиз Монасыйпов 1917 елда Бөтенрусия мөселманнары Хәрби Шурасы оешкач, аның сәркатибе итеп сайлана. Хәрби Шураның боерыклары астында, Ильяс Алкин белән янәшә, «солдат Габделгазиз Монасыйпов» имзасы да куелган, ә кайчакта ул рәис вазыйфаларын да үтәгән.

1917 елның 29 маеннан Хәрби Шура карамагындагы «Безнең тавыш» газетасы сентябрь аена чаклы Г.Монасыйпов мөхәррирлегендә әзерләнгән, биредә ул актив автор да булган. Газета битләрендә аның докладлары, боерыклары, баш мәкаләләре, публицистик язмалары дөнья күрә. Аларда шул заманның мөһим мәсьәләләре күтәрелә, илдәге сәяси хәлләр, халыкара вакыйгалар, туган халкының ирек өчен көрәше яктыртыла.

Монасыйповның илдә барган сәяси вакыйгаларны аңлап эш итүе, халыкара хәлләр, башка милләтләрнең азатлык көрәше тарихлары белән яхшы таныш булуы «Болак арты республикасы» эшчәнлегендә дә чагылыш таба. Ул, мөселманнарны берләштереп, Болак артындагы хәрәкәткә туплауда алгы сафларда тора. 1918 елның февраль-март айларында, канлы бәрелешләрне булдырмыйча, Совет хакимияте белән сөйләшүләр алып баруда да әдипнең өлеше зур.

Хәрби Шура Совет хакимияте тарафыннан куып таратылгач, Г.Монасыйповның иҗтимагый эшчәнлеге кысыла. Язучы күпмедер вакыт әле Казанда була яки Казан тирәсендә яши. Моңа дәлил: 1918 ел урталарында, әйткәнебезчә, «Таранчы кызы...» басылып чыга, ә аның кереш сүзе ахырында «Казан, 1918 ел, май» диелгән. Әлеге китапның галим-тюрколог С.Е.Маловка бүләк ителгән нөсхәсендәге автографта 1919 елның 27 гыйнвары күрсәтелгән. Димәк, Габделгазиз бу көннәрдә әле Казанда булган[4].

ВАФАТЫ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘР

1920-1922 елларда Ташкентта эшләгән М.Бәдәйли үзенең «Псевдонимнар сүзлеге»ндә Г.Монасыйповның 1922 елда Ташкентта ниндидер типографиядән бер машина кәгазь урлап тотылуын һәм атып үтерелүен яза[5].

З.Рәмиев моңа охшаш вакыйганың 1920-1930 елларда Ташкентта яшәгән һәм иҗат иткән татар язучысы һәм шагыйрь Зариф Бәширинең 1927 елның 16 августында язып тәмамлаган «Кара тараканнар» повестенда урын алуын язып үтә. Әсәрдә: *«Аннан соң сүз «Советтан үч алу өчен», ялган документлар белән, матбага складларыннан кәгазь урлап йөргәндә тотылып аттырылган Монасыйпов «фаҗигасе»нә күчте:*

---

[2] Монасыйпов Г. Тукай хатирәсе // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / Төзүчеләр: Р.Ф.Исламов, Җ.С.Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – 2 т.: Мәкаләләр, шигырьләр, төрлеләр. – Б.23.

[3] Мәхмүтов Һ. Октябрьгә кадәрге татар театры / Һ.К.Мәхмүтов, И.И.Илалова, Б.Ф.Гыйззәт. – Казан: Тат. кит.нәшр., 1988. – Б.400.

[4] Рәмиев З. Тагын бер фаҗигале язмыш / З.Рәмиев // Мирас. – 1996. – №1-2. – Б.140.

[5] Бәдәйли М. Псевдонимнар сүзлеге / М.Бәдәйли // ТӘҺСИ Мирасханәсе. – 619 фонд. – 80 кол. – 1 тасвир. – 31 эш берәмлеге.

Г.Монасыйповны туган авылы Байкалда онытмыйлар. Әдипнең тууына 130 ел тулу уңаеннан оештырылган фәнни-әдәби очрашудан фоторепортажны **beznenmiras.ru** сайтында (яки QR код буенча) карарга мөмкин.

– Егет! Шанлы үлем белән дөньядан үтте, ичмасам! – диештеләр. Ләкин бу да «милләт кайгысы» белән сынган күңелләрне тулы рәвештә юата алмады»[6], – дигән юллар бар.

Г.Монасыйповның үлеме хакында башка мәгълүмат та бар. Аны 1989 елда Ташкентта Марсель Әхмәтҗановка педагог һәм тел белгече Сәхи Рәхмәтинең хатыны Мәрьям ханым сөйләгән: *«Мин Габделгазиз Монасыйповны «Өзелгән өмид» исемле китабын укып белә идем. Бу китап миңа бик нык тәэсир итте. Андагы вакыйгалар Ташкент шәһәрендәге Татар бистәсенең Таҗетдинов фамилияле бай гаилә тормышыннан алып язылган. Хикәядә Таҗетдиновларның Гафифә һәм Гайшә исемле кызларыннан берсенең тормышы чагыла. «Өзелгән өмид» басылып чыккач, алар, Габделгазиз Монасыйповка үчләнеп, зур җәнҗал чыгарып йөрделәр һәм язучыны Нәваи урамындагы Салар елгасы аркылы салынган күпер янында үтерелгән килеш таптылар. Халык арасында, аны Таҗетдиновлар үчлек белән үтерткәннәр, дигән сүзләр таралды. Бу хәлләр егерменче елларда булды, елын төгәл хәтерләмим»*[7]. Г.Монасыйповның туганнары да әлеге фикердә тора[8].

Алда китерелгән мәгълүматларга нигезләнеп, Г.Монасыйпов 1922 елда Ташкентта үтерелгән, дип әйтергә мөмкин.

РЕДАКЦИЯДӘН: *Г.Монасыйповның хатыны Зәйнәп белән төшкән фотосын биргәне өчен – **Искәндәр Камал**га, Байкал авылы зиратындагы кабер ташларының фотосын тәкъдим иткән өчен, **Арча шәһәрендәге «Казан арты» тарих-этнография музее хезмәткәрләре**нә олы рәхмәтебезне һәм чиксез ихтирамыбызны белдерәбез.* ■

---

[6] Бәшири З. Кара тараканнар / З.Бәшири. – М.:Центриздат, 1930. – Б.59.
[7] Әхмәтҗанов М. Энҗеләр эзләгәндә / М.Әхмәтҗанов // Татарстан. – 1993. – №9. – Б.86.
[8] Марат Монасыйповның Г.Ф.Төхфәтовага язган хатыннан. – Канада, 2010. – 18 сентябрь. Хат Г.Ф.Төхфәтовада саклана.

Без – мираслы халык!

*19 декабрь көнне «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры **Андрей Кузмин**, аның урынбасары **Сөмбел Таишева**, Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе **Ринат Закиров**, Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре **Разил Вәлиев**, баш мөхәррир **Ләбиб Лерон**, республикабызның башка мөхтәрәм әдипләре һәм галимнәре, редакция хезмәткәрләре катнашында журналыбызның редколлегия утырышы узды.*

***Хөрмәтле укучылар!** «Безнең мирас» журналында сез нинди мәкаләләр укырга телисез? Мирасыбызның кайсы катламы сезнең өчен аеруча кызыклы? Бу сорауларга җавапларыгызны, гомумән, басманы камилләштерү (ә камиллекнең чиге юк!) турындагы фикер-тәкъдимнәрегезне язып, безнең почтага (yanamiras@mail.ru) сала аласыз.*

Хәзер исә сүзне редколлегия әгъзаларына бирик. Фоторепортаж – beznenmiras.ru сайтында.

Равил Фәйзуллин, *«ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры киңәшчесе, Татарстанның халык шагыйре:*

– Декабрь аенда «Безнең мирас» журналының 300 нче саны чыкты. Басманың һәр саны бер китап дигән сүз. Төрле елларда дөнья күргән журналның үз стиле бар, әмма миңа хәзерге «Безнең мирас» күбрәк ошый. Бу – фәнни-популяр, әдәби-нәфис, документаль журнал. Академик журналга караганда, мондый төрлелек укучыларны җәлеп итү өчен иң кулай вариант. Хәзер халыкка гыйлемне шприц белән кертмәсәң, аны укытып булмый. Яшьләрнең милли әдәбиятны укуы кимеде. Дөрес, аның объектив сәбәпләре дә бар. Элегрәк: «Китап – белем чишмәсе», – дип әйтә идек. Ә хәзер бу мәкаль актуальлеген югалта бара, шуның өстенә, татар теле кысыла, ә татар авыллары бик саекты, аларның хәле буш күкәйне хәтерләтә. «Безнең мирас» үзенең төрлелеген, яхшы мәгънәсендә әйткәндә, чуарлыгын югалтмаска тиеш!

Зиннур Мансуров, *Татарстанның халык шагыйре:*

– Төрки халыклар арасыннан татар халкы мирас җәһәтеннән иң бай милләт. Ул мирас яндырылган, урланган, әмма аның шуннан калганы да бихисап. Сибгат Хәким: «Без, татарлар үз мирасыбызны таптап йөрибез», – дигән иде. Бу чыннан да шулай. Журнал, үз юнәлеш-концепциясен булдырып, татар халкына хезмәт итә. Ул – үзенә күрә кечкенә генә бер энциклопедия. Миңа аның һәр саны да кызыклы, журналны үземдә саклап барам. «Безнең мирас» үзенең ярымфәнни булуы белән дә әһәмиятле. Аның сәхифәләрендә халыкка бөтенләй таныш булмаган, кояш нурын күрмәгән чыганаклар басыла. Чит төбәкләрдәге мирасны барлау җәһәтеннән дә журналның географиясе киңәйде.

Фәнзилә Җәүһәрова, *Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе, галимә:*

– «Безнең мирас» журналы хәтта тышлыкта да үзенең йөзен тапты: һәр сан саен аерым рәссамның иҗатына урын бирә. Журналда безнең үзәкнең дә махсус рубрикасы бар. Сәнгать фәннәре белгече Эльмира Каюмова берничә ел дәвамында музыка уен кораллары турында язды, 2019 елдан әлеге эшне «Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе Ринат Гыйләҗев дәвам итәчәк.

Ел дәвамында Курган өлкәсенә бәйле мәкаләләр циклы басылды. Бөтенроссия авыл Сабан туе булачак җирдә милләттәшләребезнең мирасы ни хәлдә? Алар анда ничек яши? Без бу сорауга җавапны «Безнең мирас» журналы сәхифәләреннән таптык. Сабан туена барганчы ук, әлеге төбәкнең тарихы, мәдәнияте белән таныша алдык.

«Безнең мирас» журналы татарның юкка чыгып бара торган этник төркемнәренә дә игътибар итсен иде. Мәсәлән, Себердәге бараба һәм тар татарларының саны елдан-ел кими бара. Яңа гына бараба татарларының бик үзенчәлекле музее ачылды. Татар этнотуристик брендларын пропагандалау эше дә журналның бер бурычы булырга тиеш. Фольклор материаллары белән үзебез дә ярдәм итә алачакбыз.

Журнал редакциясе хезмәткәрләре гарәп язуында булган мирасны үзләре үк текстологик яктан әзерләп, аны халыкка кайтара. Бу – сезнең бәхетегез! Хәзерге көндә гарәп графикасында язылган текстларны, аеруча кульязмаларны укучылар саны бик сирәк.

Данил Салихов, *Татарстан Язучылар берлеге рәисе, күренекле драматург һәм прозаик:*

– Әгәр дә хәзерге көндә «Татнефть»нең «Рухият» фонды Ризаэддин Фәхреддиннең китапларын ел саен бастырмаса, «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре мәшһүр галим һәм дин эшлеклесенең мирасын пропагандалауга җиң сызганып керешмәсә, ут күршеләребез булган башкортлар аны күптән бездән тартып алган булыр иде. Чөнки Риза хәзрәт китапларының күбесен Уфада язган, архивы да шунда саклана...

Без башка халыклар татар мирасын бүләргә җыенганны алдан сизәргә һәм үз укучыларыбызны теге яки бу шәхес иҗаты белән берничә ел алданрак таныштырырга тиешбез. Ә «Безнең мирас» журналы моның өчен бик әйбәт мәйдан!

«Безнең мирас» журналы – җитәкчеләргә ияреп дөньяның төрле почмагына бара торган һәм «бу – безнең тарихыбыз!», «бу – безнеке!» дип горурланып әйтергә мөмкин булган бердәнбер басма. Без бүген: «татар үзбәкне укыткан!», «татар казакъны укыткан, аңа аң-белем, мәгърифәт керткән!» – дип мактанырга яратабыз. Ә кемнәр ул мөгаллимнәр, имам-мөдәррисләр? Нигә шулар турында «Безнең мирас»та язып, аны Үзбәкстан яки Казакъстан дәүләт җитәкчесенең кулына тоттырмаска?! «Татбригада атка менде...» дигән рухтагы җырлар белән тәрбияләнгән нәфрәт, «Фрунзе белән килеп, сез безне тар-мар иттегез», дигән сүзләр үзбәк күңеленә уелып калды, ә татарның аң-гыйлем, театр алып килүе онытылды...

Фәйзелхак Ислаев, *тарих фәннәре докторы, профессор:*

– Соңгы елларда Бөтендөнья татар конгрессы ярдәмендә авыллар тарихы белән кызыксынып киттек. Китаплар да күп чыкты. Һичшиксез, «Безнең мирас» журналына авыл тарихын системалы рәвештә яктыртырга кирәк. Төбәк тарихын язучылар журналның даими укучылары да булыр иде.

Кызганыч, авыл, төбәк тарихын яктырту телевидение-радиода да, вакытлы матбугатта да тиешле дәрәҗәдә куелмаган. Башкортларның бу юнәлештәге эшчәнлеге көнләшерлек! Чатнап торган татар авылларыннан да: «Мин – башкорт!» – дигән кешене табып, шуның белән башкортлыкны пропагандалыйлар. Ә безгә Башкортстандагы, башка төбәкләрдәге татар авыллары турында күбрәк язарга, сөйләргә кирәк.

Разил Вәлиев, *ТР Дәүләт Советы депутаты, Татарстанның халык шагыйре:*

– Безнең хәзерге көндә моңыбыз телебезгә караганда да күбрәк югала бара. Телсез милләт булмаган кебек, җырсыз-моңсыз милләт тә була алмый! Моңыбызның нигезе бөтенләй бетеп бара... Мирас буларак, аның тамырларын эзләргә иде. Татар музыкасы ялгыш юлдан китте: ул, үз тамырларын

онытып, Европага йөз белән борылды. Ә бит татарның музыкасы шәрыктан килә! Ул кытай, японныкы белән тәңгәл. Ни өчен безнең пентатоника аларныкына шулкадәр якын икән? Европа музыкасы нигезендә үсәргә тырышабыз, ә Көнчыгышныкын бөтенләй диярлек өйрәнмибез. Югыйсә, бу халыкларда музыка сәнгате искиткеч югары дәрәҗәдә! Европа артистларын гастрольләр белән чакырабыз, ә шәрыкныкын юк. Бу өлкәдә алар безнең туганнарыбыз булырга тиеш!

Журнал шәхесләр темасын бик иркен яктырта. Аларга моның өчен рәхмәт! Әмма безнең әле дә актив иҗат итүче мөхтәрәм шәхесләребез бар. Мәсәлән, Казакъстанда яшәүче Мөнир Ерзин. Ул – борынгы кытай телен белгән бердәнбер татар галиме! Надир Дәүләтнең искиткеч бай шәхси архивы бар. Анда Исхакыйларга мөнәсәбәтле фотолар, документлар, хатлар саклана. Аның белән дә уртак тел табып, материалларын «Безнең мирас»та бастырырга кирәк. Журнал татар мөһаҗирләре мирасын яктырту белән киңрәк шөгыльләнсен иде.

ТРда «Матди булмаган мирас турында» закон кабул ителде. Бу канун безгә зур мөмкинлекләр бирә. Аның кысаларында үзегезнең проектларыгызны гамәлгә ашыра аласыз.

Ләйлә Минһаҗева, *филология фәннәре докторы, КФУ галимәсе:*

– 1990 нчы елларда Флүн Мусин энциклопедик, затлы фәнни «Мирас» журналын чыгарды. Бүген «Безнең мирас» фәнни булырга тиешме, түгелме, дигән сорау куела. Әмма татар мирасы турында язылган басманы башка журналлар дәрәҗәсенә төшерүгә мин каршы. Чит илләрдә, аеруча Төркия һәм Казакъстанда «Безнең мирас» белән кызыксыналар. «Котадгу билик»не «Безнең мирас» бастырмаган булса, без аны кайдан табып укыр идек?! Журнал сәхифәләрендә мин башка басмаларда дөнья күрмәгән, фәнни, фактик материалларны күбрәк укырга телим.

Дамир Нотфуллин, *ТР Мәдәният министры урынбасары:*

– Әле күптән түгел генә «Безнең мирас»ны укып, Арчадагы «Казан арты» тарих-этнография музее хезмәткәрләренең, мәдәният белгечләре белән берлектә, Байкал һәм Шурабаш авылларында Габделгазиз Монасыйповның тууына 130 ел тулу уңаеннан мәдәни чара оештыруларын белдем. Татарстан музейларында 2 миллионга якын экспонат бар. Аларның нибары 3-4 проценты гына халыкка күрсәтелә. Музейларда елына йөзләгән мәдәни чара уза. «Безнең мирас»та Татарстан музейларына, аларның фондына бәйле махсус рубрика оештырып булмасмы? ■

ЧЫН ГАЛИМНЕҢ СҮЗЕ КАЛЫР, ҖУЕЛМАС ЭЗЕ КАЛЫР*

Фәнзилә Җәүһәрова

Без, татарлар – берничә мең елларга сузылган тарихта язма мәдәниятле булуыбыз белән аерлып торган халыклардан. Шунлыктан без тарих битләренә язмача уелган сүзгә, фикергә шактый сак һәм ихтирам белән карыйбыз. Әдәбият, мәдәният тарихыбыз төпкелләрен дә бик ерак чорлардан, һуннар заманнарыннан алып исәпләүне мәслихәт күрәбез, ул гына да түгел, әлеге фактларны дәлилләрлек яңа чыганакларны табып, фәнни әйләнешкә кертә торабыз. Иң куандырганы шул – ул эзләрне барлап, аларны тел, тарих, археология фәннәре казанышлары аркылы дәлилләрлек галимнәребез дә бар. Ошбу мәкаләдә без шундый галимнәр плеядасының күренекле вәкиле Марсель Хәернас улы Бакиров турында сүз алып барырбыз.

Бүген олуг галимебезгә кагылышлы җитди фикер әйтергә бик күркәм бер форсат та бар. Ул күптән түгел саллы нәтиҗәләргә бай фәнни иҗатта узган бәрәкәтле гомеренең бик матур бәйрәмен – 85 яшь тулуны билгеләп үтте. Марсель Хәернас улы – киң кырлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, профессор, филология фәннәре докторы, күренекле фән эшлеклесе, Россия Гуманитар Фәннәр академиясенең академигы, Россия Федерациясенең югары профессиональ белем бирү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре дәрәҗәсенә лаек булган шәхесләрдән. Гомер юлларын татар әдәбияты, мәдәнияте, сәясәте өлкәләрендә хезмәт итүгә багышлаган күренекле милләттәшләребез арасында Марсель абыйның әдәбият белеме, татар фольклорына кагылышлы мавыктыргыч дәресләрен тыңлаганнар саны да берничә меңнән артадыр. Миңа калса, ул һәр шәкерте хәтерендә нәзакәтле юмор остасы, киң эрудицияле галим, һәркем белән дустанә мөнәсәбәт кора белүче татар агасы буларак сакланадыр. Аның ярты гасырдан артык Казан дәүләт университетының башта татар бүлеге, аннан татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты мөгаллиме буларак башкарган хезмәте республикабызда мәгариф һәм фәнне үстерүдә мөһим урын били. Казан университетында педагогик һәм фәнни эшчәнлек алып бару белән беррәттән, Марсель

* Халык мәкале.

КДУның татар тел һәм әдәбияты кафедралары галимнәре. 1980 нче еллар

Хәернас улы XX гасырның ахырларында, бөтен Совет илендә милли үзаң үсү белән бәйле хәрәкәттә актив катнашып, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршында татар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау Дәүләт үзәген оештыру эшләрен башкара. Әлеге Үзәкнең эш юнәлеше концепциясен төзү, Уставын булдыру, кадрлар туплау эшләренең барысы да диярлек аның акылы, кулы аша уза. Әйтергә кирәк, 1991 елда оешкан Үзәкнең әлеге үсеш концепциясе хәзер дә актуальлеген җуймады, 3 дистәгә якын вакыт узса да, XX гасыр ахырындагы алда аталган планнарның тормышка ашып беткәне юк әле.

Марсель Хәернас улы, мөгаллимлек хезмәте белән беррәттән, менә инде 27 ел буе үзенең фәнни куәсен Татар фольклоры дәүләт үзәгеннән үсеп, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенә әверелгән оешмага куя килә. Биредә ул татар халкының традицион мәдәниятен өйрәнү һәм популярлаштыру өлкәсендә киң кырлы эшчәнлек алып бара. 2007 елда оешып, соңгы 10 ел дәвамында фәнни яктан җитдилеге, таләпчәнлеге белән танылган яшь фольклорчылар мәктәбенең фәнни остазы да ул. Тынгысыз җаны, фәнни фикерне төрле яктан колачлап әйтә алырга омтылышы, объектив дәлилләр табу сәләте аңа халык иҗатын, төрки-татар шигъриятен тирәнтен өйрәнгән олпат галим буларак үз урынын яуларга мөмкинлекләр бирә. Марсель Хәернас улының фәнни җитәкчелегендә фән кандидатлары, филология фәннәре докторлары гыйлем дөньясына юл ала. Искиткеч кешелекле, мәрхәмәтле, олы йөрәкле, шул ук вакытта нәфис сүз серләренә төшенгән остаз буларак, ул хезмәттәшләре, укучылары һәм республика җәмәгатьчелегенең хөрмәтен казана.

Әдәбиятыбызның күренекле вәкиле Фәнис Яруллин, үз башыннан кичкәннәргә таянып, «Җилкәннәр җилдә сынала» дигән әсәрен иҗат иткән иде. Марсель абыйның да канатлары җилләрнең бик зәһәрендә, илебезнең иң хәвефле елларында – бар киңлекләрдән «халык дошманы» эзләп, аларны төрмәләргә утырту, сөргеннәргә сөрү, атып үтерү вакытларында чыныга башлый. Ул заманның җилләре аның ба-

Марсель Бакиров

лачагын «халык дошманы улы» дигән мәсхәрәле карашлар белән үреп иссә дә күңелен явызлык белән мәкергә, үпкә-үрсәләнүләргә күмми, киресенчә, аны хезмәткә, гыйлем туплауга этәреп, дөньяның әллә нинди серле йомгакларын күреп алып, аларны үтә сабырлык белән сүтәргә өйрәтә, самими күңелле ир-ат буларак чыныктыра. Марсель Хәернас улы гаилә өстенә килгән хәсрәтне газиз әнисе, абый-апасы, туганнары белән бергә кичерә, нәселдән килгән үҗәтлек, хыялга тугрылык аңа, сикәлтәләрдән торган юлларны горур узып, Казан дәүләт университетына башта укырга керергә, тора-бара аспирантураны, аннан укытучы-галим хезмәтен сайларга мөмкинлек бирә. Студент елларында ук күренекле галимнәр, шул исәптән аның фәнни җитәкчесе Хатыйп Госман да, Марсельнең башкалардан фикерләвенең төпле булуы белән аерылып торуын сизеп алалар һәм аны әдәбият белеменең шактый четерекле юнәлешенә – шигърият төзелешенә кагылышлысына кертеп җибәрәләр. Бу елларны ул «фәнни иҗатымның тамырларының тирәнгә төшеп үсүен тәэмин иткән уңдырышлы туфракка орлык салган чорларым», дип атый. Ни дисәң дә, аның фәнни һәвәслеге татар, аннан соң төрки, борынгы төрки поэзиянең корылыш үзенчәлекләре тирәсендә бара. Әлбәттә, борынгы поэзия, төрки шигъри эзләнүләр Марсель Хәернас улын фольклорчы буларак та танытты. Ул, поэтик фикерләүнең чишмә башы халык иҗатында икәнен бик яхшы аңлаган галим буларак, татар фольклористикасындагы шигъри юлларга корылган ырымнар, арбаулар кебек жанрларның да үзенчәлекләренә бәйле төпле фикерләре белән фәндә үз сүзен әйтә алды. Болгар-татар мифологиясе, йола фольклоры, лирик җырлар, мөнәҗәтләр, риваятьләр һәм легендалар турында да кызыклы хезмәтләр язды. Аның бу өлкәдәге эзләнүләре тарихи җырлар, дастаннар жанрларына кагылышлы фикерләр белән дә баеды. Шуларның нәтиҗәсе буларак, татар фольклористикасында беренчеләрдән саналган бик саллы «Татар фольклоры» (2008 ел) исеме астында дәреслек тә иҗат итте һәм югары белем бирү уку йотлары студентлары өчен иҗат ителгән ошбу әсбап, тиз арада рус теленә тәрҗемә ителеп, кабат басылды һәм бүгенге көндә ул Казан дәүләт консерваториясе, Казан мәдәният институты студентлары тарафыннан иң актив кулланылучы уку әсбапларыннан исәпләнә. Марсель аганың башка галимнәрдән аерып торган үзенчәлекле ягының берсе – ул чын мәгънәсендә энә белән кое казучы. Аның коесы гомумтөрки тамырлар булса, энәсе – киң эрудициясе, тарихи фактларны табу гына түгел, аларны дәлилләү өчен факт өстенә фактларны фольклор, тел гыйлеме, тарих, археология кебек фәннәргә кагылышлы даирәләрдән китерү, беренче карашка табарга мөмкин булмаган чыганакларны табу. Шушы максатыннан чыгып, ул – Мәскәү, Санкт-Петербург, Алма-Ата, Баку, Ереван, Бишкек, Ташкент, Уфа, Чабаксар кебек шәһәрләрнең үзәк китапханәләрендә дөнья кадәр фәнни-теоретик хезмәтләр

Марсель Бакировның кандидатлык диссертациясе яклавына бәйле мәҗлестә татар зыялылары: Хәсән Туфан (сулдан беренче), Диләрә Тумашева, Мөхәммәт Гайнуллин, Хатыйп Госман (диссертантның фәнни җитәкчесе), Гази Кашшаф. 1972 ел

һәм фактик чыганаклар өйрәнүгә күпме гомерен сарыф иткән шәхес тә. Әлбәттә, аның тырышлыгы берсе артыннан берсе дөнья күрә башлаган бик тирән эчтәлекле фәнни хезмәтләрендә ачык чагылыш тапты. Аларның һәрберсенең исемнәре үк эчтәлектәге фәнни фикернең колачына җитди ишарә ясый. Мәсәлән, 2001 елда аерым китап булып басылган «Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары», 2014 елда дөнья күргән «Древнетюркская поэзия: не разгаданные тайны устного и письменного творчества» хезмәте һәм әле генә беренче сигнал данәләре галимнәр кулына килеп кереп, шул арада сенсацияле китап буларак бәяләнә башлаган «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» (2019 ел) кебек фәнни иҗат җимешләрен атау урынлы булыр. Марсель Хаернас улының ошбу соңгы хезмәте аны дөньяга эзләнүләренең тирәнлеге белән аерылып торучы тюрколог галим буларак таныта. Бирелә ул тарих фәнендә моңа кадәр төркиләрнең килеп чыгышына, таралыш ареалларының формалашу этапларына, территорияләренә кагылышлы фикерләргә шактый дәлилле фактлар белән каршы килә. Фикерен дәлилләү барышында төрки кавемнәргә, аларга тел ягыннан якын торган башка этносларның матди, рухи мәдәниятләренә кагылышлы уртак сүзләр оялары таба. Иң гаҗәпләндергәне – хезмәттә урын алган әлеге сүз оялары сигез йөздән артып киткән. Кайбер галимнәр әйтмешли, бу хезмәт – тюркология, тарих, археология кебек фәннәргә алга таба үсү өчен яңа азимутлар билгеләгән хезмәтләрдән. Ул инде фәнни әйләнешкә кереп китте. Аңа танылуны, төрле фәнни дискуссияләр кузгатырлык укучыларны, әлеге эзләнүләр юнәлешен үстерерлек фикердәшләрне телик. Ә без, үз чиратыбызда, бүген тугызынчы дистәсенең уртасына җитеп, фәнни фикерен саектырмый гомер кичерүче авторга – олуг галимебез Марсель Хаернас улы Бакировка исәнлек-саулык, иҗади уңышлар, бәрәкәтле хәерле озын гомер телик. ■

ИГЕЛЕКЛЕ ХАНЫМ

Ркаил Зәйдулла

Курчак – кеше кебек үк борынгы. Ул, әлбәттә, башта, уенчык булудан бигрәк, төрле ияләрнең, рухларның, өстен көчләрнең гәүдәләнеше итеп ясалган. Мәҗүси әби-бабаларыбызның шундый курчакларны, кадерләп, йортта тотулары, үзләре белән ерак юлларда йөртүләре тарих сәхифәләрендә теркәлеп калган. Шул вакытта ук аларга сабыйларның, бигрәк тә кыз балаларның кулы үрелгәндер. Ислам динен кабул иткәч, әлеге курчаклар, сакраль мәгънәләрен югалтып, уенчык булып калган... Курчак театрының тарихы, минемчә, шул заманнардан ук башлана. Хыялга бай бала үз курчакларына төрле исемнәр кушкан, вазыйфалар йөкләгән, алар булып сөйләшкән. Бу хәзер дә шулай. Ә инде чын курчак театры андый баланың бөтен вөҗүден биләп ала, сабыйның хыял дөньясы тагын да киңәя...

Балачагымда авылга курчак театры килүен әле дә хәтерлим. Чаршау өстендәге курчакларның кыланышы, әкияти могҗиза – аны ничек онытасың?! Син, әлбәттә, беләсең: чаршау артында курчакларны бавыннан тартып кемдер уйната, җырлата, елата, ләкин анысы тиздән онытыла, курчаклар мөстәкыйль тормыш белән яши башлый. Мин әле дә шундый чаршаулы тамашаларны сагынам. Хәзер инде курчакның бавын тартучылар яшеренеп-нитеп тормый, яңа заман, яңа тамашалар.

Роза ханым Яппарованың «Әкият» курчак театрында эшләвенә быел кырык ел тула. Башта ул педагог-оештыручы, аннары әдәби бүлек мөдире булып хезмәт куя. 1993 елда – үзгәртеп кору чоры! – артистлар, театр хезмәткәрләре аны бертавыштан директор итеп сайлап куя.

Һәм уңалар. Әлбәттә, шулай озак еллар «Әкият» курчак театрын җитәкләрмен, дип башына да килми аның. Әлеге вазыйфада бит гадәти хуҗалык эшләре генә түгел, театр директоры булу ул иҗади эш тә... Һәр артист – үзе бер дөнья, ә курчак театрында уйнаучы – икеләтә дөнья. Курчак бавын тарткалаучының күңел җепләрендә буталып калуың да бар! Аларның тибрәнешен тояр өчен аерым бер сәләт, ә иң мөһиме – табигатьтән бирелгән ихласлык кирәк. Монда ялганны, икейөзлелекне аерата тиз тоялар.

Әлбәттә, Роза ханымның курчак театрында төпләнеп калуы очраклы хәл түгел. Театр сәнгатенә мәхәббәте ана сөте белән сеңгән. Аның әнисе дә – халык театрында уйнап, үз төбәгендә мәшһүрлек казанган зат. Кызганыч, ул Роза беренче сыйныфка кергән елда вафат була. Әтисе башка гаиләдә... Ятимлек ачысын кечкенәдән кичерергә туры килә аңа.

Роза ханым Казан университетындагы тарих-филология факультетының урыс-татар бүлеген тәмамлый. Биредә ул киләчәктә татар әдәбиятының йөзек кашы булачак шагыйрьләр белән бергә белем ала, тулай торакта соңгы кисәк икмәкне бүлешә. Шигъриятькә хирыслыгы аның, әлбәттә, балачактан ук килә. Ул әле дә балачагында, яшьлегендә отып алган озын-озын шигырьләрне кирәге чыкканда яттан сөйли. Бик иртә ятим калып, әбисе тәрбиясендә үсүе дә моңлы булуына этәргеч биргәндер... Хәер, аны якыннан белмәгән кеше, кырыс кыяфәтенә карап, «тимер хатын», дип тә уйларга мөмкин. Җитәкче кешегә ансыз да ярамый.

Хәтеремдә, мәрхүм Рәшит Әхмәтҗаннар, Зөлфәтләр ара-тирә: «Розаның хәлен белеп кайтырга кирәк, яңа спектакль чыгарган», – дип, Курчак театры ягына юнәләләр иде. Алар университетта бергә укыган. Кайчагында аларга Мөдәррис Әгъләм дә иярә. Мин хәзер аңлыйм: шигъри дөнья турында фикер алышырга Роза ханымнан да кулайрак кешене табуы кыен. Җитмәсә, ул, тормышының төрле ваккыйгаларын искә алып, шулкадәр тәфсилләп, тәмләп сөйли ки, авызны ачасың да каласың. Хәзер инде әлеге тарихларда Зөлфәтләр үзләре каһарман булып катнаша...

Шагыйрьләрне автор буларак та Курчак театрына тартырга тырыша Роза ханым. Биредә Зөлфәтнең берничә әсәре куела: «Җен

Яңа бина ачу тантанасында яшь тамашачылар белән. Сулдан уңга: Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, театр директоры Роза Яппарова, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов. 2012 ел

кызы», «Гасырдан озын бу көн» , «Ат өреккән шомлы төн», ә «Таңга – Чулпан, айга – Зөһрә» әкияте әлегә кадәр уңыш белән уйнала.

Мөдәррис Әгъләмне генә театрга ияләштерә алмаган ул. Шулай бер килүендә, курчаклар өчен пьеса язарга димләгәч, Әгъләм, гадәттәгечә, кәпәчен батырып кигән дә: «Тормышыбыз – курчак уены!» – дип, башын кыңгырайтып китеп барган.

Роза ханым мине дә театрга җәлеп итте. Ләкин курчаклар өчен әсәр язу җиңел түгел. Шигырь белән язылган «Ике башлы дию» исемле әкиятемне ул да, театрның баш режиссёры Илдус Зиннуров та ошатмады. Анда җеп, шырпы ише персонажлар; Роза ханым сорады: «Син боларны үзең курчаклар буларак күз алдына китерәсеңме?» Мин, акланып, нидер мыгырдадым бугай. Мөгаен, театрга моңарчы бөтенләй күрелмәгән яңалык алып килергә теләгәнмендер! Ләкин, чыннан да, җепне курчак итеп уйнап буламыни? Һәр өлкәнең үз кануннары бар. Күпме генә мөгез чыгарырга теләсәң дә, син аларга буйсынырга мәҗбүр. Ниһаять, Илдус Зиннуров кабат-кабат эшләткәч, «Бүре җиләге» дигән әкиятемне курчаклар нәни тамашачыга җиткерде. Аннары Роза ханым миңа Фәнис Яруллинның 2-3 битле генә «Йолдыз тапкан кыз» әкиятен пьеса итеп язарга тәкъдим итте. Фидакарь язучыбызның туына сиксән ел тулган көннәрдә Курчак театрының игелекле эшләреннән берсе булды ул. Театр, шулай итеп, бакыйлыкка күчкән шагыйрьләрне дә онытмый. Монда Зөлфәтнең туына җитмеш ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә дә бик кызыклы үткән иде. Роза ханым хәзерге шагыйрьләрнең иҗаты белән дә кызыксынып тора, әсәрләрен укый. Яшьләрдән Рүзәл Мөхәммәтшаны да театрга тартты ул. Аның «Өрә белмәгән көчек» әкияте шулай ук театр репертуарында. Менә быел Илгиз Зәйниев иҗат иткән «Әлфия» әсәре сәхнәдә куелырга әзерләнә. Әсәр мәрхүмә җырчыбыз Әлфия Авзалова турында. Режиссёры да Илгиз үзе...

Безнең кайбер театрларда еш кына директор белән баш режиссёр тыныша алмый.

Күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләре арасында. Сулдан-уңга: театр режиссеры, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Людмила Дьяченко, композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгудә Шәмсетдинова, драматург, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин. 2003 ел

Бу җәһәттән Роза Яппарова белән Илдус Зиннуровның иҗади хезмәттәшлегенә сокланмый мөмкин түгел. Аларның иң төп мәсьәләләрдә фикердәш булуы эшнең нәтиҗәсенә дә тәэсир итә. Биредә Роза ханымның иҗат кешеләрен аңлый белүен дә, кайчагында юл бирү сәләтен дә искә алырга кирәк. Ул иҗат кешеләренә эшләргә мөмкинлек бирә, аларга уңай шартлар тудырырга тырыша. Кайчагында мин аны Камал театрының онытылмас директоры Шамил Закиров белән дә чагыштырам. Болар – шул татар әдәбият-сәнгатенә ихластан гашыйк, фидакарь затлар токымыннан. «Ләкин соңгылары!» – дип әйтәсе килми. Алардан үрнәк алган яшьләр дә килер әле, дигән өмет яши. Чөнки үзләре турыдан-туры иҗат итмәсәләр дә, әдәбиятны-сәнгатьне алга этәрүчеләр, иҗат кешеләренә хәерхаһ булучылар һәрвакыт кирәк. Аларсыз иҗат дөньясында уңышка ирешеп булмый.

Театр һәрдаим фестивальләрдә катнашып килә. Былтыр, «Ханума» спектакле белән, Оренбургта үткәрелгән курчак театрлары фестивалендә, өлкәннәр өчен спектакльләр арасында, «Әкият» өч приз алып кайтты. Быел театр алты фестивальгә чакырулы. Гомумән, алар үзләре куйган спектакльләрне төрле төбәкләргә алып барырга атлыгып тора. Мөмкинлек туганда чит илләргә дә чыгалар, ара ерак дип тормыйча, Рәсәйнең ерак өлкәләренә дә юл тоталар. Көньяк Сахалинга, Барнаулга, Улан-Удэга, Омскига, Нерюнгрига, Магнитогорскига... Фестиваль ул башкаларга үзеңнең иҗат җимешләрен күрсәтеп бәһа алу гына түгел, бүтәннәр белән аралашу да, үзгә иҗат төркемнәренең тамашаларын күреп сабак алу да.

«Әкият» курчак театры үзе дә 2013 елдан бирле «Шомбай fest» дип исемләнгән фестиваль үткәреп килә. Быел Франция белән Төркиядән дә курчак театрлары килергә тиеш.

Шомбай, дигәннән, Петербург режиссёры, «Алтын битлек» премиясе номинанты Светлана Дорожко быел «Шомбай» әкиятен биредә сәхнәләштерергә җыена.

Шагыйрь, драматург, журналист һәм театрның якын дусты Равил Бохараев белән. 2003 ел

Театрның 2012 елда архитектор Светлана Мамлеева проекты белән төзелгән яңа бинасы чын-чынлап әкият сарае ул. Курчак театры өчен мондый бина кайда гына бар икән?! Ул, тыштан ук алгысытып, үзенә чакырып тора.

Эш, әлбәттә, гел макталулардан, уңышлардан гына гыйбарәт түгел. «Әкият» курчак театрын да әледән-әле тәнкыйтьләп торалар. Асылда аны куелган әсәрләрнең сыйфаты өчен түгел, ә татарча тамашаларның аз булуында гаеплиләр. Әлеге мәсьәлә хакында сүз чыкса, Роза ханым дулкынлануын яшерә алмый, бу хакта ул сәгатьләр буе да сөйли ала. Бу – аның авырткан җире. Хәер, барыбыз да аңлыйбыз ләса, мәсьәлә татар теленең хәзерге хәленә барып тоташа. Күбебез үз телебезне санламыйбыз, кирәксенмибез. Курчак театрына иң олы түрәләрнең дә балалары, оныклары килә, йә, кайсысы гына татар тамашасына керә икән? Юк алар! Балык башыннан чери. Димәк, өйдә, гаиләдә милли тәрбия юк. Ә бит нәкъ менә шулар югары мөнбәрләрдән татар теленең язмышы өчен борчылган булып кылана, ниндидер чынга ашмый торган тәкъдимнәр белән күз буйый.

Нәни балалар өчен сәхнәгә куярлык драма әсәрләренең кытлыгы да үзен сиздерә. Роза ханым бу хакта да әрнеп сөйли:

– «Әкият» «Бәби-театр» проектын башлады. Биредә 1 яшьтән алып 3-5 яшькә кадәрге балалар өчен тамашалар күрсәтелә. Әлегә барлык тамашалар да урысча бара. Сәбәбе нидәме? Нәниләргә күрсәтерлек хәзерге заман әсәрләре юк! Язарга атлыгып тормыйсыз бит. Дөрес, балалар өчен язу җиңел түгел. Автор үзе дә балачак дөньясыннан аерылмаган булырга тиештер моның өчен... Без инде менә шуңа күрә шагыйрьләргә мөрәҗәгать итәбез... Ә нарасыйларга тамаша кую тагын да авыррак. Әлегә «Бәби-театр» проектының урысча гына эшләве бары тик тиешле кимәлдәге сыйфатлы пьесаларның булмавына гына бәйле. Юк бит балалар өчен яза торган драматурглар! Көндез шәм белән эзләсәң дә табып булмый аларны.

Урыс труппасында – 22, татар труппасында 11 артист безнең. Яшерен-батырын түгел, урыс труппасы акчаны күп эшли. Безгә еш кына татар тамашалары аз, дип

«Җыен» хәйрия фонды директоры Фоат Рафиков (сулдан беренче), Россиянең һәм Татарстанның халык җырчысы, Тукай премиясе лауреаты Илһам Шакиров, баш режиссер Илдус Зиннуров белән. 2012 ел

дәгъва белдерәләр. Әлбәттә, аз. Мин аны яшермим. Сәбәбе дә билгеле: татарча гына тамаша куйсак, театр бөлгенлеккә төшәчәк.

Без татарча тамашаларга җәлеп итәргә бик тырышабыз да... Соңгы вакытта бик яхшы әсәрләр дә куелды. Татарчага аз йөриләр, чөнки укытучыларга да урысча тамашаларга йөртү кулайрак бит, баш миен артык эшкә җигәргә кирәкми. Аларның күбесе татар теленә кул селтәгән. Юкса, урысча тамашага килүчеләрнең байтагы татарчаны азмы-күпме аңлый, ләкин аңлап бетермәгәнне үзләштереп, бераз кыенлык кичереп утырасылары килми. Мәктәпләрдән татарчага киләбез дип ашкынып тормыйлар. Югыйсә, татар телен камилләштерер өчен безнең тамашалар үзләре бер дәрес бит инде. Аннары татар сәнгате белән таныштырыр өчен дә менә дигән форсат. Юк, аларга урысча гына кирәк. Менә быел татарча Яңа ел тамашасы бары тик өчәү иде, шуларга да ай буе билет саттык. Ә урысчаларына көнендә сатылып бетте.

– Татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә гастрольләргә чыгарга да мөмкин бит, – димен.

– Гади көннәрдә безнең билет бәясе 220 сум булса, ялларда – 350 сум. Әмма авылларга йөргәндә билет бәясе 100-150 сумнан да артмый. Татар труппасының гастрольләре гел «минус»ка китә. Районга кайтсак, кунакханәләрдә кунып чыгу 700-1000 сум тора. Эшләгәнебез кунакханәгә түләгән акчаны да капламый.

Без авылларга еш йөрибез. Кимендә елына дүрт тапкыр чыгабыз. Башлыча район үзәкләрендә булабыз, авылларда 100 бала да укымый. Зур мәктәпләр чакырса, рәхәтләнеп риза булыр идек.

Курчак театрының проблемалары олыларга барып ялгана. Ләкин ул кыенлыклар Роза Яппарова башкарган игелекле эшләрне каплап китә алмый. Балаларны олы сәнгатькә җәлеп итүдән, миһербанлы булырга өйрәтүдән дә игелеклерәк нинди эш булырга мөмкин?! Күптән түгел генә гомер бәйрәмен үткәргән милләт хадимәсенә исәнлек-саулык телик. ■

Безнең мирас №2 февраль 2019

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

ҮЛЕМ ҖӘЗАСЫ ҺӘМ ҖАВАП ҖӘЗАСЫ

Кытайларда үлем җәзасы һәм җавап җәзасы күренеше бар. Үтерү вакыйгасы расланса, үтерүченең үзен дә үтерәләр. Моннан тыш, башка төрле гаепләләргә дә үлем җәзасы бирү түрәләр кулында. Кирәк булса – теләсә – һич гөнаһсыз кешене дә үлемгә хөкем итү зур түрәләрнең кулыннан килә торган эш. Кытайларда гаебе булган кеше өчен үлемгә хөкем ителү ул кадәр авыр түгел, тик чәчен кисү җәзасына хөкем ителсә – шау-шу куба. Чәч шулкадәр дә изге булып санала икән. Мин Харбинда яшәгәндә, берничә кешегә үлем җәзасы биреләсе икән, дигән сүз чыкты, тик бик үрсәләнгән кеше күрмәдем. Ә менә Пекинга килгәч, берәүнең чәчен кискәннәр иде, шулвакыт бөтен газеталарда махсус мәкаләләр бастырылып кына калмады, атналар буе бу хәбәр телләрдән төшмәде.

Үлем җәзасы бирелгән гаеплеләрне үтерер алдыннан төшереп алынган бер рәсемне биредә укучылар игътибарына тәкъдим итәм.

Бу рәсемдә күргәнебезчә, шул рәвешле утырып торган гаепле кешеләрнең өчесенең башын берьюлы кисеп төшерәләр.

Үлемгә хөкем ителгән кешеләр

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Әгәр җәлладның кылычы бер селтәнүдә башны кисеп очырса, бөтен кеше кычкырып көлә: «Шанко! Шанко!» – дип кычкыра, кул чабып алкышлый.

Үлем җәзасы кытайларда канун буенча каралган, шуңа күрә ул бөтен кеше тарафыннан кабул күрелә, бөтен җирдә тормышка ашырыла. Хәтта кайбер зур түрәләр дә, мәсәлән монгол илендәге Ванлар, мәхкәмә карары белән генә түгел, үз карарлары белән дә тиеш дип тапкан кешеләрне үтертә алалар.

ФУДЗЯДЯН МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ХӘЛЕ

Алдарак та искә алып үтелгәнчә, Фудзядян Харбинның бер өлешен тәшкил итә, биредә идарә эшләренең барысы да кытайлар кулында. Бу районда бер кечкенә генә мөселман мәхәлләсе дә бар. Монда яши торган мөселманнарның хәле да нәкъ Цицикардагы кебек, болар да җаһиллек һәм шапшаклык эчендә. Тик биредәге ахун, бераз булса да гарәпчә аралаша алуы белән, Цицикар ахунынннан шактый аерылып тора. Ахун әфәнденең кытайча исеме Ван-Хун-Бен, гарәпчә исеме Нур Мөхәммәт икән. Бу кеше гарәп телендә шактый аңларлык итеп сөйләшә ала. Телнең бөтен нечкәлекләрен белә, дип әйтеп булмый, ләкин шулай да сүзләрне шактый дөрес куллана.

Моннан тыш, Нур Мөхәммәт әфәндeнең фикере – кытай мөселманнарын бу гафләт йокысыннан уятыр өчен, Русиянең эчке өлкәләрендә яшәүче мөселманнар белән бәйләнештә тору кирәк. Мондый фикергә ия кешеләр кытай голәмәсе арасында бик аз булганга, мин Нур Мөхәммәт әфәнде җәнаплары кебек шәхеснең булуыннан файдаланырга булдым: әлеге кеше белән даими бәйләнештә булу максатында, хәбәрләшеп тору өчен адресын алдым, үземнең дә илдәге адресымны бирдем. Бу максатымда нык торачакмын. Фудзядян мөселманнары бик фәкыйрь, бай кешеләре бөтенләй юк икән. Шуңа да карамастан, мәчет һәм мәдрәсәләре бар. Мәдрәсәдәге шәкертләр, нәкъ Цицикардагы кебек, 15-20 яшьлек кешеләр. Фикһ (хокук белеме), гарәп теле укыйлар, ике кәлимә гарәпчә белмиләр. Боларны күреп, өметсезлектән башка берни уйлый алмыйсың. Төньяк Кытайда, бигрәк тә төньяк-көнчыгышта һәм Маньчжуриядә җаһиллек киң таралган, ул шул дәрәҗәгә җиткән ки, үз җаһиллекләреннән үзләренең хәбәрләре юк. Боларны уяту һәм уята алачак кешеләр җибәрү – алдынгы фикерле мөселманнарның вазыйфасы булып тора. Бигрәк тә Ислам хәлифәлегендәге мөселманнар һәм Шәйхел-Исламлык боларга ярдәмгә җитешергә, боларны җаһиллектән коткарырга тиеш, югыйсә, боларның киләчәкләре куркыныч астында. Әйтүләре буенча, Маньчжуриядә алты миллионга якын мөселман яши. Тик бу алты миллион эчендә намаз дип кабул ителәчәк кадәр Коръән укый ала торган алты кеше дә юк. Боларның хәлләре дөньялыкта да, ахирәттә дә җан ачысы, болай барса һәм читтән берәр ярдәм килмәсә, боларның киләчәге миссионерларга җим булачак. Мин бу җәһәтләрне, Кытайның эчке төбәкләрендә күргәннәремне дә өстәп, алга таба җентекләп сөйләп аңлатачакмын, шуңа күрә биредә бу кадәре белән чикләнәм.

ТАНЫЛГАН СӘЯХӘТЧЕ ЛАДЫГИН[1] БЕЛӘН ОЧРАШУ

Харбинда яшәгәндә, мин русларның танылган сәяхәтчесе Ладыгин җәнаплары белән очрашып сөйләштем. В.Ф.Ладыгин 1899 елда Русиянең География җәмгыяте тарафыннан, җитәкчелегенә тапшырылган 34 кешедән торган төркем белән бөтен Кытай Төркестанын һәм Тибет тарафларын ачу һәм өйрәнү өчен, төгәл өч ел җирләр гизеп, 1902 елда сәяхәтен төгәлләгән. Кытай телен һәм төрки телләрне бик яхшы белүче бик

[1] Ладыгин Вениамин Фёдорович (1860-1923) – Тибет һәм Монголия экспедицияләрендә катнашкан, кытай телен камил белгән, төрки телләрдә дә иркен аралашкан сәяхәтче, ботаник (тәрҗ. иск.).

Харбин. Вокзал

мәшһүр кеше. Бу кеше белән күрешеп сөйләшүдән бик канәгать калдым, чөнки бик күп мәгълүмат алдым.

Ладыгин җәнаплары миңа зур ихтирам күрсәтте, арабызда гаять самими сөйләшү булды. Үзенең әсәрләре белән дә таныштырды, сәяхәтләре турында да сөйләде. Үзе төзегән Кытай картасын күрсәтеп, миңа юллар аңлатты. Арабызда күп сүз сөйләшелде. Ладыгин миңа уйларын яшермичә әйтте:

– Бу юлларда Сезгә 90 процент куркыныч яный, – диде. – Кая гына барсагыз да бик зур кыенлыкларга дучар булачаксыз. Бигрәк тә мөселман булганыгыз өчен, Сезгә тагын да зуррак куркыныч яный. Чөнки бөтен Кытайда миссионерлар Сезгә бик начар мөгамәлә күрсәтәчәкләр. Хәтта Сезне үтерттерүләре дә бар. Бигрәк тә көньякка таба барсагыз, Сычуаньнан өстәрәк яши торган Католик миссионерлар бик әшәке, Сезнең мөселман булуыгызны белеп алуга, әллә ниләр эшләүләре мөмкин.

– Андый куркынычлар мине һич куркытмый, – дидем. – Чөнки безнең Ислам инанулары буенча, *Лән йусыйбәна илла ма кәтәбәллаһу ләна* [Аллаһының безнең өчен язганнарыннан тыш, безгә берни булмас] (Тәүбә: 51). Мин кая гына юл тотсам да, инануым – һәрвакыт бу инану.

– Сездә мондый ышаныч булгач, тыныч булыгыз, Сезгә берни булмас. Шулай да, мин Сезгә бер киңәш бирмәкче булам. Сез үзегез белән күп итеп револьвер алыгыз. Үзегезгә кирәге чыкмаса, кытайларның дәрәҗәле кешеләренә тәкъдим итәрсез, бик теләп кабул итәләр.

Ладыгин җәнаплары миңа бик хөрмәт күрсәтте, үзенең «Сәяхәтнамә»сенең бер нөсхәсен бүләк итте.

Бу бик самими сөйләшүдән соң, кичке тугызларда, Ладыгин белән саубуллашып, Хөсәен әфәнде Агишевның өенә кайтырга дип кузгалгач, Ладыгин җәнаплары миңа:

– Безнең Харбин урамнары Тибет тауларыннан тынычрак түгел, ваемсыз булмагыз, – диде.

Өйдән чыктым. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Урамнарда фонарьлар юк. Илле адым атлаган идемме икән, каршыма килүче берәү кычкырып җибәрде:

– Тукта! Туктамасаң, атып үтерәм!

– Нәрсә кирәк?– дидем. – Мин үз эшем белән, үз юлымнан барам.

– А-а, гафу итегез, Сез кем? Мин кур-

куым белән Сезне дә куркыттым бугай.

Мин үземнең кем булуымны әйттем.

– А-а, нихәлләрегез бар? Менә бу ичмасам очрашу!

Бу сүзләрне ишетеп, аптырап калдым. Артык караңгы булганга, бу кешене күреп тану мөмкин түгел.

– Сез кем? – дип сорадым.

– Тиколин мин, – дип җавап бирде. – Маньчжурия станциясеннән Цицикарга кадәр Сезнең белән бергә килгән идек. Кабат сорыйм, зинһар гафу итегез, мин Сезне куркыттым.

– Зыян юк. Мин мондый хәлләрдән курыкмыйм.

Бу бичара үзе дә курка-курка килә икән, мине дә куркуга сала язды.

КЫТАЙЛАРНЫҢ БЕР СӘҮДӘ КОНТОРЫНДА

Беркөнне Харбин урамнарында йөри идем, бер кытай конторына кердем. Бу язуханәнең (контораның) урам ишегенә рус һәм инглиз телләрендә «Контора, Господин Ху-Шин» дип язылган иде. Әлеге сәүдә язуханәсе тышкы яктан да, эчтән дә бик төзек, матур күренә. Ишектән кердем, бу зур гына бүлмәдә берничә генә кеше бар. Бер кырыйда гаҗәеп вәкарьле һәм озын чәчле бер егет, аякларын сузып, креслога җайлап утырган, газета укый, ачык газета бөтен йөзен каплаган, чәчләре генә асылынып тора. Тагын бер-ике кеше дәфтәр хисабы белән мәшгуль иде. Мин газета укучы әфәнде янына килдем. Ул, мине күреп алуга, урыныннан сикереп торды, бик мөлаем елмаеп, утырырга урындык тәкъдим итте дә русча: «Рәхим итегез!» – диде. Кулында тоткан газетага күзем төште, Маньчжуриядә чыга торган биржа газетасы иде. Өстәл өстендә кытай, рус газеталары да бар. Танышканнан соң, шактый гына әңгәмә корып алдык. Сәүдә эшендә дәфтәр тоту ысулының әһәмияте турында да сүз булды. Шулвакыт мин бу сәүдә дәфтәрләрен нинди телдә язулары турында сорадым. «Кытай телендә, чит ил кешеләре белән мөгамәләдә кулланыр өчен инглиз телендә алып барыла торган дәфтәребез дә бар», – дип җавап бирде.

– Бөтен сәүдә конторларында да бу ысул белән эшлиләрме?

– Чит илләр белән сәүдә итүчеләр бу ысул белән эш итәләр һәм инглиз телен генә кулланалар. Ләкин сәүдә эшендә чит илләр белән бәйләнеше булмаганнар кытай теленнән башка бер генә телгә дә ихтыяҗ тоймыйлар.

– Кытайлар арасында чит илләр белән сәүдә итүче сәүдәгәрләр күпме?

– Зур сәүдәгәрләр чит илләр белән генә сәүдә итәләр.

– Кытайларныкы, ләкин бары тик кытайларныкы гына булган фирмалар бармы? Зур капитал ияләре бармы?

– Безнең Харбинда бик зур капиталистлар юк. Капиталы биш йөз мең булган һәм иң күбе бер-ике миллион булган фирмалар бар. Тик Тяньцзинь, Шанхай, Наньтун шәһәрләрендә зур фирмалар, зур капиталистлар бик күп. Пароход фирмалары бар. Шулай булса да, хәзергә безнең кытайларда бик зур эшләр белән шөгыльләнүчеләр юк дәрәҗәсендә. Ләкин шулай дәвам итеп торсын әле, бер көн килер, хәтта Европа үзәкләрендә дә кытайларның сәүдәсе үз урынын биләр. Иң алдынгы европалылар белән ярышка керешәсе көннәр киләчәк әле.

– Гафу итегез, Сезнең исемегезне дә сорамаганмын, исемегез ничек?

– Ван-Тьян-Тан.

– Ван-Тьян-Тан әфәнде! Хәзерге вакытта әйләнә-тирәдә гел яшәү өчен көрәш бара. Мәдәни һәм алга киткән милләтләр, технологик җитештерү товарларын сатар өчен, Кытай кебек артта калган милләтләр арасында базар ачып җибәргәннәр. Фән һәм технологиядән хәбәре булмаган милләтләр бервакытта да көрәш мәйданында урын били алмаслар шул.

– Безнең кытайлар соңгы вакытларга кадәр Европа илләренә чыкмадылар, әмма табигый сәләтләре барлыгы билгеле иде. Хөкүмәт халыкны тәрбияләү өчен бик күп чаралар күрде. Ләкин безнең кы-

тай халкының табигате шундый: берәр төрле афәт кичермәсәләр, күнегелгән хәлләрен үзгәртергә бик атылып тормыйлар. Изге дип санасалар да, Бугду ханга да бик баш иеп тормыйлар. Әле күптән түгел генә императрица кытайларга чәчләрен кисәргә дигән фәрман чыгарган иде, бер генә кеше дә кабул итмәде һәм кабул итмәячәк тә. Безгә чит илләрнең мәдәнилеге һәм алдынгылыгы кирәк түгел. Безнең кытай халкы бу соңгы сугышта гаять көчле һәм беркайчан да бер генә кытай кешесенең дә хәтереннән чыкмаячак йодрык ашады, инде Европа мәдәниятенең ни икәнен бик яхшы аңладылар. Моннан соң безнең европалыларга карата мөгамәләбез бөтенләй башка төрле булачак. Без фән һәм технологиягә булган ихтыяҗыбызны аңладык, үз күзләребез белән күрдек, моннан соң инде бу өлкәдә кирәк булганны бар итәргә тырышачакбыз. Тиздән, бик тиздән үзебезгә кирәклесен алып, бозык әхлакларын үзләренә кире тоттырачакбыз. Европалыларда мондый әхлак бозыклыгы булганда, тиздән алар үзләре безнең бүгенге хәлебезгә төшәчәкләр. Икътисадка игътибар бирү безнең элек-электән табигатебездә бар, фән һәм җитештерүне алга җибәрсәк, күтәрелүнең иң югары нокталарына ирешәчәкбез. Аннан соң безгә берничә ел хәзерлек кирәк, эчке эшләребезне яңадан корырга кирәк, боларны башкарып чыга алсак, ярышка керешү генә түгел, үчебезне алырга да тырышачакбыз.

– Кытайларда андый ук сәләт күрмим. Бүгенге көндә, кая карама шунда, кытай – хезмәтче, русларга хезмәттә иң гади эшне алар башкара. Руслар хәтта боларга Иван, Симён, Сидор дип рус исемнәре тагып бетергәннәр. Болай дәвам итсә, миллиятләрен дә югалту ихтималы бар.

– Безнең кытайлар эштән курыкмыйлар, эшләү һәм шул юл белән фикерләрен киңәйтү, яктырту һәр кытай кешесе өчен зур уңыш булып тора. Әйе, русларга хезмәт итүче кытайлар бик бичаралар, ләкин моның ахыры безнең өчен хәерле булачак. Хәзерге вакытта инде руслар да кытайларга алай бик кимсетеп карамыйлар. Япон сугышына кадәр, болар кытай кешесен шулкадәр хур күрәләр иде ки, иң бай миллионер кытайны иң гади хезмәтче рустан да түбәнрәк саныйлар иде. Шуны да әйтим: Харбинда кытайлар юк. Болар, бу якларда яшәүчеләр – бар да маньчжурлар. Төп кытайлар – Кытайның эчке төбәкләрендә, Тяньцзинь һәм Шанхай якларында яшиләр.

– Сезнең кытайлар бик куркак милләт. Чит ил кешесеннән шулкадәр куркалар ки, кыргый җәнлекләр, диярсең. Мин моңа бик гаҗәпләнәм. Ни өчен шулкадәр куркалар?

– Бу хәл кытай халкына түгел, киресенчә, кытай хөкүмәтенә хас. Сәбәбе исә шул: элек Европа илчеләре (безнең Пекин сараена сүзләрен үткәрә башлаган көннән алып): «Безнең миссионерларның берсенең генә борыны гына канаса да, канын таләп итеп, үч алачакбыз», – дип әйтә килгәннәр. «Мондый фетнә чыгуга сәбәп була күрмәгәек», – дип, Кытай хөкүмәте европалыларга карата сак булырга кирәклеген кисәтеп торган. Миссионерның кем икәнен дә халык ул вакытларда бик белмәгән, алар исә безнең кытай халкына карата төрле золым эшләгәннәр: кыйнаганнар, сукканнар, кул белән, аяк белән, тел белән һәр минут, һәр сәгать кимсетеп, хурлап торганнар. Максатлары исә, фетнә чыгару. Ул кыерсытуларга түзә алмыйча, безнекеләр кечкенә генә бер каршылык күрсәтсәләр, шунда ук европалыларның хәрби флоты килеп җитә. «Безнең милләттәшебезне кимсеттегез, кыерсыттыгыз», – дип, сугыш ачу белән куркыта башлыйлар иде. Без шулвакыт кая гына мөрәҗәгать итсәк тә, хаксыз булып чыга идек. Миссионерлар гына түгел, кайчак чит ил офицеры да кытай кешесенең чәчен кисә, кайчак исә башын кисә иде. Ә хөкүмәт хәтта ни өчен киселгәнен дә сорамый. Бервакыт бер офицер (исемен дә сөйләгән иде), Хар-

Харбин. Пристань янындагы Кытай урамы

бин урамында берәүнең башын кискән. Шулвакыт бу офицерның юлдашлары моннан: «Ни өчен кистең?» – дип сораганнар. «Кылычымны сынап карадым», – дип, көлеп җавап биргән. Менә мондый кыргыйлыклар, европалылык кыргыйлыгы була торып, безгә сылтанган һәм, нәтиҗәдә, хәлләр бу соңгы сугышка килеп җиткән. Моңа охшаш хәлләр әлегә кадәр күренгәләсә дә, моннан соң инде озак дәвам итә алмас.

– Әлегә кадәр бармы?

– Булгалый иде. Ләкин инде япон сугышыннан соң, юк, дип әйтә алабыз. Инде безнең кытайларда да ул дәрәҗәдәге ахмак сабырлык калмады.

Ван-Тьян-Тан белән шул рәвешле ярты сәгатьләп сөйләшеп утырганнан соң, фирмаларының агымдагы хисап дәфтәрләрен дә карадым, шактый бай мәгълүмат туплап, саубуллашып чыгып киттем.

Харбинда ике атналап тордым. Ноябрь аеның 7сендә Харбиннан Владивостокка китәргә, дип карар кылган идем. Чит илләргә чыгып йөри алу өчен, чит илгә чыгу паспорты сорап, Харбин мәхкәмәсенә мөрәҗәгать иткән идем. Мәхкәмә хезмәткәрләре белән сөйләшкәннән соң, паспорт бирә алачакларын әйтсәләр дә, рус түрәләренең каршы төшүләре сәбәпле, бара-кайта, ике көнемне шул мәхкәмә юлында әрәм иттем.

Ул көннәр кытайларның Яңа ел башы бәйрәменә дә туры килде. Русларның да Яңа ел башы бәйрәме якынлаша иде. Шулай итеп, бәйрәмнәрнең икесен бергә диярлек үткәрдек. Күз алдыбыздагы манзара менә мондый иде: руслар, Яңа ел бәйрәмен котлап, нәкъ бер атна исереп йөрделәр, урамнарда, кая карама, шунда пычрак эчендә аунап яттылар. Кытайлар исә Яңа ел башын бәйрәм итеп, җем-җем утлар аттырып, уйнадылар, көлделәр, олысы-кечесе бергә, төркем-төркем, төрле-төрле чаралар белән күңел ачтылар. Юлчылыгым ике көнгә соңга калганга, мин дә бу бәйрәмнәрне күрдем һәм ул көннәр минем өчен яңа мәгълүмат чыганагы булды.

Дәвамы бар

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

БАШКОРТ КЫЗЫ

(Әсәр кыскартып бирелә)

Хәсән Сарьян

Без шаулашып, көлешеп, кунак өенә кайтып кердек. Кунак өе дигәннәре финский тибындагы өч бүлмәле стандарт йорт иде. Түрдәге иң зур бүлмәдә, ап-ак ашъяулыклар җәеп, егерме-егерме биш кешелек табын әзерләгәннәр. Берсеннән-берсе чибәр биш кыз борынгы керәшен күлмәкләре киеп, укалы сүрәкә, чигәчәләре өстеннән яулык бәйләп, тач көмеш тәңкә, мәрҗән тезелгән яка, күкрәкчәләр тагып, атлаган саен чеңләп-чылтырап, кухнядан бүлмәгә аш-су ташып йөриләр. Без үткән беренә йотылып карап, телсез калдык.

– Чукынсам, чукынырмын – берсен озатмый калмыйм!.. – диде Фәридун.

Без гримлы битләрне юып, төзәнеп-таранып, өстәл әйләнә утырыштык. Өстәл караучы керәшен кызлары бишесе биш җиргә урнашты. Шулай итеп, тамакка ризык, күзләргә ямь, җанга ләззәт биргән табын башланып китте. Бу табынга бер милләтнең төрле тарихи сәбәпләр аркасында мишәр, татар, типтәр, керәшен булып йөргән балалары җыелган; шулар эчендә башкорт кызы Таңсылу да чит түгел, үзебезнеке иде.

Мин, янымда булса гел карап булмас, дип, аның нәкъ каршысына утырдым. Аның күз янындагы бит сөяге аз гына калкып-киңәеп тора, кара бәлзәмдәй чын кара күзләре елкылдап янып киткәндә, шул киңчә яңаклары әллә нинди көч, таләпчәнлек белән ихтыярны үзенә буйсындыра, хисләремне утлы тойгы эченә сала иде. Минем сулышым кибеп, тамак төбемә астан нидер менә дә нәкъ аркылы килә дә утыра – төкерек тә йота алмый интегә башлыйм. Бер кабат Таңсылуның да күзләре гөлт итеп кабынып, битләреннән алсу каны уйнап үтте. Шунда ул гел карап утырма, дигән ым белән сизелер-сизелмәс кенә башын кагып куйды.

Инде башкалар ашау-эчүдән туктап, йөзләрен табынның түбән очына борган иде. Шунда мин бер Азалинең генә бөтенләй кире якка – миңа текәлеп утыруын сизеп алдым. Күзләр күрешмәсен өчен күземне тиз генә кеше караган якка юнәлттем. Азалинең миңа төбәлеп каткан йөзе чалынып кына калды. Азалидән башка бөтен табын теге таба караган иде. Ишек төбендәге стена буена алсу ак йөзле, гөләндәм буйлы керәшен кызлары тезелеп баскан, ә бер читтәрәк, аларга яны белән, үзләренең баянист егетләре утырган иде. Биш кызның бишесе бергә, саф авыл тавышы белән, безнең беребез дә ишетмәгән озын керәшен көе җырлап җибәрделәр:

Җирәнчәккәй аткайның а-ай башында
Тимер чатлы гына-а-ай дилбегә.
Бергә чакта җырлаплара-ай калаек,
Җырларыбыз калсына-ай билгегә.

Иске керәшеннәрнең телендә дә, җырлары, киемнәрендә дә борынгылык күбрәк сакланган, дип язалар. Мин дә, җыр башланып җыр беткәнгә хәтле, биш матурдан күзем алмыйча: «Мөгаен, безнең кадим болгар кызлары да шушылайрак киенгәннәрдер, көйләре дә шушылайрак булгандыр», – дип уйлап утырдым. Төрле моң, төрле бизәкле халкым өчен җаным-тәнем белән горурлык хисе кичердем.

Табын җырга күчте. Безнең һәркайсыбыз диярлек үзе яраткан бер көй җырлап чыкты. Ә мин, хуҗалар үзләре үтенгәч, Наҗар Нәҗминең «Татар теле» шигырен сөйләдем.

Ниһаять, чират Таңсылуга җитте.

– Мин йырлай белмәйем бит, иптәштәр, – дип караса да, иркенә куймадылар.

– Башкорт та булсын – җырлый да белмәсен!.. – дип, чатябыштылар.

Ахырда Таңсылу күнде:

– Башкортча җырласам, гаеп итмәссез бит?

– Нинди гаеп, ди, җырла гына! Башкорт көен без бик яратабыз, – диешеп, табын гөҗләп алды.

Алмас, елтыр баянын күтәреп, Таңсылу янына килеп баскан иде инде. Ул, Башкортстанның Яңавыл районыннан булып, үзен башкорт дип йөрүче, чын урыс йөзле бер татар егете иде.

– Нинди көй боерасыз, кара күз? – диде ул.

– «Таштугай»ны беләсеңме?

– Мин белмәгән аз булыр – Бохарадагы таз булыр! – дип, Алмас тибрәтеп уйнап та җибәрде.

Таңсылу тирәннән чыңлап чыккан, үтә самими башкорт тавышы белән «Ташту-

гай» көен башлады. Бу тавыш бөтенләй башка: салмак та, көчле дә, моңлы да иде. Болай итеп фәкать чын башкортлар гына, аның да Таңсылу атлысы гына җырлый аладыр, мөгаен! Мин, бала чакта тигез тугай өстенә чыккан салават күпере күргәндәй таң калып, әсәрләнеп югалдым... Тик Таңсылу ике генә куплет җырлады да:

Ялан еркәйдең ай кәккүге юк,
Үд Уралкайыма кайтайым...

– дип, чын сагышын җиренә илтеп туктады. Шунда нидер ирегемә куймыйча Таңсылудан күзем алырга мәҗбүр итте. Карашым, үзем дә сизмәстән, Азалигә төште. Аның ике күзе тулы яшь, үзе шул яшь аркылы әллә кая текәлеп, күңеле белән бу табыннан киткән иде. Кеше кул чаба башлагач, исенә кайтып, ипләп кенә ул да кушылды, ике бите буйлап яшь агып төште: яше белән бергә миңа булган мәхәббәте дә юылып төште, ахры: миңа төбәлгән күзләрендә чиксез сагыш кына торып калган иде. Миңа капылт әллә ничек булып китте. Ләкин тиздән ул онытылды – күңел күзем Таңсылуда гына иде.

Табын сәгать өчтә генә бетте. Төннең иң кыска чагы бу. Аяз булган булса, инде, салкынайтып, яктыра башлаган булыр иде. Тик көне дә, төне дә аяз түгел, шуңа әле караңгы. Без килгән халыкны озата чыктык. Бер Азали генә чыкмады. Ул, өстәл яныннан халык кузгалу белән, беркем күзенә чалынмыйча, бүлмәләренә кереп киткән. Өлкәнрәк абыйлар, апалар капка төбендә үк юкка чыктылар. Берзаман капка төбендә без, яшьләр генә торып калганбыз. Башта без төркемебез белән бер якка киттек. Аннары кем кая аерыла башлады. Иң әүвәл Фәридун, соңра Алмас, аерылып, кызлар озата киттеләр. Парлыларыбыз да кире борыла башлады. Бераздан без Таңсылу белән икәү генә торып калдык.

Без бу өч көн дәвамында шактый якынайган идек инде. Ләкин бу фәкать эштә, юлда якынаю гына: чын хисләремне мин бары тик уен-көлке аша гына, анысында да бик саклык белән генә сиздереп киләм. Тик Таңсылу берни белгертми, күңелле чаялык белән уенга уен каплап тик тора: мине бу борчый да, икеләндерә дә, әмма иң куркытканы – күктәге болыттай агылып кына үткән көннәр иде! Менә өч көн үтте дә! Ә дүрт көннән без аерылышачакбыз. Ул аяусыз көн күңелемә тап булып ябышкан. Сүнүсез-сүрелүсез янган йөрәгем Таңсылу белән тизрәк аңлашып калырга әйди башлады.

Иптәшләрем кызурак киткән саен, без акрыная төштек. Йөрәгем каты итеп тибә, шулай да җәелеп-иркенәеп типми, аны нидер кыскан, җибәрми тотып торган төсле; бер йөрәгем генә түгел, уйларым да эздән чыккан иде инде. Тын алган саен сулышымны бүлеп, гомердә беркем әйтмәгән иң матур, иң ягымлы сүз әйтергә җыенам. Тик...

– Телеңне йоттыңмы әллә, Касыйм? – диде шунда Таңсылу. – Йә, берәр нәрсә сөйлә инде.

– Аһ, ни сөйлим соң, Таңсылу!.. – дидем мин. – Тиздән аерылышыр көн килү миңа тынгы бирми... Синнән аерылгач, нишләрмен мин.

– Куйчы, юкны сөйләмәче. Йә, ышандырып куярсың...

– Их, ышансаң иде, Таңсылу! Менә өч көн инде мин утта гына янам...

– Татар – үткер халык, ышан сезгә!

– Иптәшләрем белә: мин Дон Жуан түгел...

– Уйнап кына әйттем, үпкәли күрмә тагын, – диде Таңсылу.

Ул да, мин дә тынып калдык.

– Бер сүз әйтимме, Касыйм?

– Әйт, Таңсылу...

– Сине бит Азали ярата.

– Кем әйтте аны сиңа? Әлмирамы?..

– Аны кеше әйтәсе юк. Минем үз күзем дә бар.

– Кара күзлек кигән идең ләбаса! – дип шаяртмакчы иттем.

– Атак! Күңел күзем капланмаган иде лә!

– Кызык, – дидем мин. – Мине кем яратуына хәтле күргәнсең, ә яныңда янып йөрүемне күрмәгәнсең!..

– Әллә күргәнмендер дә...

– Аһ, Таңсылу, күрсәң икән!

– Күрсәм, ни булыр иде?

– Аңлар идең.

– Мин сине аңлыйм, Касыйм. Тик – нигә? Әйдә, әйбәт дуслар булып кына калыйк.

– Яратышсак, дошман булырбыз, дип куркасыңмыни?

Таңсылу көлеп җибәрде.

– Әлләче. Бәлки, дошман да булырбыз. Син бит әле мине бөтенләй белмисең. Мин бик усал бит.

– Булмас.

– Бар инде. Үзем беләм. Бергә эшләгән иптәшләр дә «усал, кыргый», диләр.

– Кая, бир әле кулыңны, нинди икәнлегеңне момент әйтеп бирәм. – Мин аның кулын тотып алдым. – Инде тыңла. Син усал түгел. Син – моңлы, нечкә күңелле кыз. Ә усаллыгың – шул нечкә күңелеңне адым саен җәрәхәтләтмәс өчен каплап йөргән бер тышча гына. Шуңа күрә күп вакыт синең күңелең кеше күзенә күренми кала.

Ул кычкырып көлеп җибәрде.

– Ә син каян күрдең?

– Әле синең күңелең катлаулы түгел. Чөнки без синең өчен бүген бар, иртәгә юк кешеләр. Әгәр инде без бергә эшли торган кешеләр булсак, ул чакта син тышчаңны салмас идең... Йә, чегәнлегем бармы?

– Бар... – диде Таңсылу. – Сине тыңлавы да күңелле.

– Рәхмәт, – дидем мин.

Мин аның кулын җибәрмәгән идем әле. Шулай тотып торган килеш, ипләп кенә тартып, йөрәгем өстенә китердем. Таңсылу үзе дә, тартылып, миңа якынрак килде. Әллә инде күз караңгыга ияләште, әллә таң беленә башлады, – мәгәр мин Таңсылуның күзләрен аермачык күрдем. Ул күзләрдән, төнге күл өстедәй тулып-ялтырап, билгесез сагыш бөркеп тора иде. Йөрәгем тагы кысылып тибәргә тотынды.

– Кара, нинди калтырыйсың!.. – диде Таңсылу.

– Хәзер үтә ул... Нигәдер өшеп киттем...

Ләкин үз тавышымны үзем танымадым: тын юлымнан нидер суырылып менеп, күз яшедәй, тамак төбемә утырды. Инде тавышым гына түгел, мин үзем дә үзем түгел идем. Шунда мин, тоташ калтыранган көе, кинәт Таңсылуны суырып алдым да күкрәгемә кыстым. Үзе дә сизми калды, ахры: «Ай!» – диде дә сеңде. Мин аның куе, каты чәчләреннән сыйпап үттем, аннары битемне сак кына тигереп, шома тәнле каты яңагыннан йөртә башладым. Иренемә якын килүемне тойгач, йөзен әкрен генә читкә алды.

– Кирәкми, Касыйм. Җибәр...

Җибәрсәм, тагын калтыратып «бизгәк» тота башлаячак иде. Сулышым кабып, эссе тыным белән Таңсылуның битенә пышылдадым:

– Мин сине яратам, Таңсылу!..

– Аһ, Касыйм...

Ул башкача йөзен читкә алмады, битен битемә төрткән килеш, йолкынмый-нит-

ми тынып калды. Шунда мин иренемә Таңсылуның салкын иреннәре ягылганын сиздем; шунда мин бөтен тәнем белән тагы бер калтырап куйдым да, шул салкын иреннәрнең шаштырып исерткеч кайнарлыгын суыра башладым. Таңсылу, этеп җибәрергә җыенган кешедәй, учын терәп кулларын күкрәгемә куйган иде. Әкрен генә кулы савылып төшә барды, ләкин тәмам төшеп бетмәде, капыл кирегә таба, күкрәгем, иңбашларым буйлап сыйпалып менде дә кинәт муенымнан кысып, кочаклап алды. Кечкенә туп тай тыгыз күкрәкләрен күкрәгемә терәп, нәфис биле, тыгыз ботлары белән майдай ягылып, үзе дә мине үбә башлады; үпкән саен, башы артка, китә бара, авыр чәчләре дә судай агылып артка төшкән иде. Бүген ул алдан – тигез шома, арттан – төймәле, якасыз, ләкин муенын бөтенләй каплаулы итеп тегелгән нәзек постау күлмәк кигән; аркасыннан буйдан-буйга эре төймә тезелеп төшкән иде. Кулларым әле биленә, әле аркасына өзлексез күчеп-шуып йөри, – кая гына күчмәсен, әлеге шул төймәләргә сыйпалып үтә иде. Мин, янып, дулкынлана башладым. Таңсылу да сизде моны, бөтен гәүдәсе белән сыланып, бер суырып үпте дә, тал чыбыктай суырылып, кочагымнан чыкты.

– Җитәр, Касыйм. Әйдә, кайтыйк. Әллә ни уйламасыннар тагы.

Минем ят өйгә кайтасым килми. Минем Таңсылудан да аерыласым килми. Кабат кочагыма бiләп, тәнем белән тәнен, йөрәгем белән йөрәген тоясым килә. Ләкин бу инде мөмкин түгел. Мөмкинен эшләдек. Аһ, ул утлы ләззәте белән ялмап алган минутлар! Бүген мин кабат – ничә елдан соң кабат! – мәхәббәт дигән утның эссе ялкынын, ялкында яну бәхетен тойдым. Инде кулымның саксыз тиюеннән дә куркып, Таңсылуны өф итеп кенә култыклап алдым.

Таң беленеп килә иде инде. Көнчыгыш офык өсте чатнап ярылгандай ачылып, буйдан-буйга аяз мәйдан хасил булган, ул киңәйгәннән-киңәя бара иде.

– Таң күз бәбәген ачкан, көн әйбәт булырга охшый!

– Бирсен Ходай! – диде Таңсылу.

***

Иртәгесен мин финский йортның киң тәрәзәсеннән туп-туры битемә төшкән кояш җылысына, йомык күзләремне чагылдырган иркә яктысына уянып киттем. Якъягымдагы егетләр дә, икенче бүлмәдәге кызлар да уянмаган иде бугай әле, – шылт иткән тавыш та юк иде. Ләкин минем соң ятсам да, йокым туйган, бүлмә эче генә түгел, минем дә эчем тулы нур, шатлык иде. Мин, сикереп торып, – кем инде шушындый якты иртәдә йоклап ятсын! – егетләрне уятып бетердем. Аннан соң без барыбыз бергә ишегалдына чыгып, кем ничек гимнастика ясый башладык. Йа, Ходаа, дөньяның киңлеге! Яздан бирле болыты, яңгыры кысып, җиргә иңеп төшкән караңгы күк ачылып, әллә кая зәңгәр югарылыкка ашкан иде. Шушылай була икән ул аяз көн!

Юынып, киенеп бетәргә өлгермәдек, тыштан ук шаулап-дөпелдәп Максимов белән комсомол секретаре килеп керде.

– Җә, ничек йокладыгыз? Йокылар туйдымы?.. – дип сораша киттеләр. – Палак түти, кунакларга чәй дә куймадыңмы әллә?..

Пелагея түти, гаепле тавыш белән:

– Самавырым күптән көйләп утыра. Әле яңа гына тордылар бит, – диде.

– Әйдә, алайса, чәеңне чыгара башла, – диде Максимов. Аннары миңа әйтте: – Сәгать унбергә машина килә. Шуның белән җәйләүгә сыер савучылар янына барып кайтырбыз. Бик чакырдылар. Павел Кузьмич та бик үтенде.

– Аның хәле ничек?

– Шул көе диярлек. Ул сезнең концертны азагына хәтле тыңлаган. Бик яраткан.

Терелеп киткәндәй булдым, ди. Рәхмәт әйтергә кушты.

– Исән булсын. Үзенә дә рәхмәт әйтегез.

Без барыбыз да, бигрәк тә Фәридун, Пелагея түтигә булыша-булыша чәй әзерләдек. Өстәл янына утыргач, Фәридун, капыл аптырап:

– Ә Азали кайда соң, кызлар?.. – дип сорап куйды.

– Азали авырый, – диде кызлар.

– Ә нигә аны әйтми торасыз?

– Ә нигә күзеңне акайттың әле? – диде аңа Әлмира. – Без сезнең кызларга ни дәрәҗәдә игътибарлы икәнлегегезне сынадык.

– Тапкансыз эш! – диде Фәридун. Сикереп торып, Азали янына кереп китте.

Ул анда, бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр, байтак торып чыкты.

– Ята... Башым авырта, ди... Температурасы да бар кебек, – дип сөйләнә-сөйләнә куе итеп чәй ясап, тагы кереп китте.

Ул арада җилкапка төбенә аксыл зәңгәр «Волга» белән «газик» килеп туктады. Без Пелагея түтигә Азалине әйбәт кенә карарга кушып, машиналарга чыгып утырдык.

– Азали үпкәләмәсә ярый ла инде? – диде Алмас.

– Ул андыйлардан түгел, – диде Фәридун.

Без башта салкынга үсә алмыйча яшел уҗым килеш утырган бодай басуы эченнән бардык. Аннары, басу бетеп, имәнлек башланды. Аны үтеп юлдай тар, баздай тирән чокыр белән Кама тугайлыгына төшеп киттек. Аннары, кисенте бетеп, юл ачык сыртка чыкты. Көтү таптап йөргән болынлык, өем-өем таллык башланды. Сул ягыбыздан төнбоеклы, камышлы күл сузылып китте. Без озак бардык. Җәйләүләре аргы очында икән. Без килеп туктаганда, ике көтүче сыерларны иләмсез зур аранга куып кертә, савымчылар күл буенда чиләк-бидон юып торалар иде. Безне күргәч, елмаеп каршы алдылар. Сыерларга кадәр безгә карап тора кебек иде.

Хуҗалар машина багажнигыннан иттер-нидер алып, юлдан аста, күлдән өстәрәк янып яткан ике учак янына илтеп куйдылар.

– Хәзер аш салып җибәрәбез, – диде Максимов. – Ә сез, кунаклар, аш пешкәнче, кем ничек тели – шулай ял итегез. Тагы кайчан киләсез әле сез? Килеп тә бу болын буламы-юкмы? Йөреп калыгыз әйдә. Ул арада безнең кызлар да сыер савып бетерер, җылы сөт бирерләр. Бәхетегезгә көне дә матур килде.

– Мин беркая да бармыйм, – диде Фәридун. – Миңа монда да күңелле. Мин бәрәңге әрчим.

Аңа карап бер-ике кыз да: «Без дә!.. Без дә!» – дип, авыз ача башлаганнар иде, Фәридун аларны тиз туктатты.

– Бу эшкә берегез дә тыгылмый. Әзегез булмасын учак янында. Кайтуыгызга менә дигән аш пешереп торам.

Чигү чигүгә кадәр белгән Фәридунның аш пешерә белүенә беребез дә гаҗәпләнмәде. Әйдә, пешерсә, пешерсен.

Бу як – көтү йөреп тапталган, без, урап, күлнең теге ягына чыктык. Икешәр-өчәр булып болын өстенә таралдык. Юадыр, кузгалактыр җиткән чор иде. Без, сагынып-тансыклап, һәркайсының тәмен татып карадык. Ләкин бу шөгыль мине тиз туйдырды.

– Әйдә, Кама буена!

– Еракмы соң ул? – диде Таңсылу.

– Ерак булырга тиеш түгел. Әнә бит!

Каманың теге ягы ерактан зәңгәрләнеп күренгән биек тау иде. Без аңа шактый якынайганбыз, бөтен тау битен каплап киткән урман да, инде карасу яшел төс иңеп, ап-ачык күренә иде.

– Әнә, Алмаслар да шунда борылды.

Без, кызу-кызу атлап, Камага карый киттек. Таңсылу, йә алга, йә арткарак китеп, иелә-бәгелә чәчкәләр җыеп барды. Бераздан без, болынның бу кишәрлегеге бетеп, биек коймадай биек, тоташ куе таллыкка килеп төртелдек. Теге ягында Камадыр, дип, таллык ярып кереп киттек. Чытырлыкта Таңсылу күктәге кош, судагы балык кебек иде; янәшәсеннән көчкә өлгереп барам.

Ләкин без яр буена чыкмадык, ишегалды чаклы гына ямь-яшел аланга килеп чыктык. Алан тулы иркә кояш; кул тимәгән үлән кыякларында чагылып нур уйный; яфракларда тамчы җил юк – һәр тараф тын, якты; ни алда, ни янда берни күренмәс булды, гүя бу якта аланда гына түгел, дөньясында Таңсылу да мин генә идем.

– Бүтән бармыйк, – дидем мин. – Бу икебезнең генә алан булсын. Өй булсын...

Без туктадык. Таңсылуның уң кулында чәчкә иде. Мин аны иплəп кенә сул кулыннан алдым. Иплəп кенә үземә тартып китердем. Иплəп кенә тыгыз биленнән кочакладым. Ул, миңа биле белән генә терәлеп, иңбашларын артка җибәрде. Шул хәлендә – башын да артка ташлау сәбәпле йомыла төшкән күзләре белән чәердәй кара керфекләре аша бик озак итеп, сынап, миңа карап торды. Аның өстендә кичәге постау күлмәк, муенына эчтән, якадан әз генә чыгарып, кечкенә ефәк яулык бәйләгән иде. Ат күзедәй төймәләре дә шул ук, тик бүген күкрәкләре генә кыюлана төшкән – нәзек постауны тишәргә җитешеп сулыш ала иде. Мин аның шушы сулап-лепелдәп үзенә өндәп янган күкрәген күкрәгемә кыстым, битләрен, күзләрен шашып үбәргә тотындым. Безнең кабат бер-берсен эзләп тапкан иреннәребез кушылды. Таңсылу, чәчәк тоткан кулын иңбашыма куеп, күзләрен йомды.

Иң башта ул исенә кайтты.

– Тынычлан, сөеклем... Алай үзеңне таларга ярамый... – диде ул. Салкын чәчкә бәйләме белән битемне сыйпап, җиңел генә кочагымнан чыкты. – Мә, үзең ычкындырган төймәңне каптыр әле, – дип, сыгылмалы сылу аркасын бирде.

– Гафу ит, Таңсылу, ялгыш кына... – дидем мин.

– Башка чакта үзеңне ул чиккә җиткермә: кайнарлыгың белән үкенечле эш эшләп куярсың... Мин синнән курка башладым, – диде ул. Ләкин тавышында бернинди ачу, үпкә юк; төймә өчен куркынган күңелем яңадан күтәрелеп китте.

– Әйдә, Таңсылу, кояшта кызынабыз!

– Куйчы. Йә Алмаслар килеп чыгар...

– Чыксын! Күрсеннәр безнең мәхәббәтне. Барысы да күрсен!.. – Мин пинжәгемне салып үләнгә җәйдем. – Әйдә, утыр.

– Алайса, син кызын, мин чәчкә җыеп киләм. Карале, монда чәчкә нинди күп!

– Юк, мин сине җибәрмим, – дип кочаклап, пинжәк өстенә утырттым.

Таңсылу, итәкләрен салып, аягын үлән өстенә сузып җибәрде, яңа кәгазь акчадай ялтырап, нәфис-түгәрәк боты ачылып китте. Мин күлмәк, майкамны бер читтәрәк үскән чәй, мәтрүшкә үләне өстенә салып ташладым да сузылып пинжәк өстенә яттым.

– Йә, сөйлә әле берәр нәрсә, Таңсылу!

– Ни сөйлим?! Сүзгә ул син оста инде.

– Үзең турында сөйлә. Юкса, күрдем – яраттым, ә үзеңне белмим.

– Белмәвең яхшы, – диде ул. Чәчәк бәйләме белән битемне сыйпап алды. – Йә, белсәң, яратмый башларсың.

– Һич югы авылыңны әйт. Качсаң, эзләп табарлык булсын.

– Минем авыл эзләп табарлык кына җирдә түгел.

– Кайда?

– Урал артында.

– Урал, Урал... – дидем мин. – Бик матурдыр инде ул Урал...

– Уралмы?! – дип, Таңсылу кабынып китте, күзләре дегеттәй ургылып кайный башлады. – Дөньяда аннан да ямьле җир юктыр! Әле кара, әле яшел, әле зәңгәргә иңә, уйсулыкларында ап-ак томан; түбәләренә болыт ышкылып, чәчтәй таралып үтә... Мин үзем – Көньяк Уралдан, Йылайырдан. Йылайырын ишеткәнең булмаса да, Сакмар суын ишеткәнең бардыр. Менә шул Сакмар буенда үстем инде мин. Авылның көнчыгышында – Ырымбур даласы, ә көнбаешында – Урал. Кояш чыккан мәлне балкып чагылып Чияле тау битләре, Алтат, Сонтогыш таулары, Әби-Очкан кыялары, Ак кыялар бездән күренеп тора. Иркендә аюлар йөри... Ул Сакмар буеның болынлыгын, таллыгын күрсәң!.. Бездәге таллар да, ничектер, зифа буйлы... Сакмар суы да терекөмештәй саф. Җәеннәр бар...

Мин яткан килеш кенә бер кулым белән аның биленнән кочаклап алган идем. Таңсылу инде, миңа карамыйча, тик алдына – күңелендәге Уралына төбәлгән көе сөйләде дә сөйләде. Таңсылуны тыңлаганда, моңга ереп, бөтенләй онытылдым; шул көй аша, тәмле төш кебек, хыялыма Урал таулары, зифа таллы, чәчкәле, болынлы Сакмар буйлары килеп басты. Таңсылу сөйләп бетергәч тә, әле мин «бу яткан җирем Сакмар буе икән», дигән сәер уй эчендә, Кама буена кире кайта алмый яттым.

– Йә, тагы нинди сорауларың бар, яшь егет? – диде Таңсылу.

Мин торып утырдым.

– Ә бу якка нишләп килеп чыктың соң син, Сакмар кызы, ә?..

– Ризык тартты, – дип көлде ул. Көлеп әйтсә дә, тавышында, зеңләп, сагыш яңгырап китте. – Синең кебек бер татар егете аркасында килдем мин... Без аның белән Уфада бергә укыдык. Ул шушы район егете иде. Кайтып, Алабуга музыка мәктәбендә укыта башлады...

– Кайда соң ул хәзер? – дип, ут йотып сорый алдым.

– Юк инде ул... Үткән җәй батып үлде... Иртәгә без алар авылында булабыз...

Мин, кеше өлешенә тигән бер адәмдәй, нишләргә дә белмичә каушап калдым. Минем кулым да Таңсылуның биленнән әкрен генә җиргә төште. Шунда кинәт, кагылу түгел, сүз әйтергә дә куркып утырганда, Таңсылу үзе миңа борылды да, йөзе белән иңбашыма капланды. Мин, аны да ияртеп, аркам белән җиргә аудым. Ул, шәрә күкрәгемә башын куеп, чәчен муеннарыма, беләкләремә таратып бераз ятты да, кинәт, яшьләнгән күзләрен күтәреп, туп-туры миңа карап торды, аннары үзе үк муенымнан кысып кочаклап, иреннәремнән үбә башлады. Без сөю сәгадәтендә онытылдык...

***

Ул көннәрне мин эчтән генә түгел, тыштан да күренеп үзгәрдем. Кан юлларын киңәйтеп-уйнатып, аяк-кул, күкрәк итләренә әллә каян көч агылып керде. Мин моңарчы да көчсез-канатсыз түгел идем, тотынган эшемне, – янам, көл булам, – җиренә җиткерми туктамый идем. Ә мәхәббәт, яшькелт йолдыз төсле, күңелләрне бетмәс сагышларга биләп, сүнмәс-туктамастан, тик хыялым эчендә генә балкып тора иде. Менә ул янып-атылып юлыма төште, Таңсылу булып куеныма керде һәм мин гөлт итеп кабындым да киттем. Таңда Таңсылу, дип уянам да, көн буена үзен күреп туя алмыйча, тәнем белән тагы кайнар тәнен тоясым килеп, сагынып, кич булуын көтәм; аяк атлап йөрүләремә кадәр очкалактай җиңеләя бара, гүя баскан җирем бу ләпек юл түгел, чөеп аткан туп иде. Сәхнәләргә чыгуым да инде башкача: элек мин үзем өчен дә, башкалар өчен дә күпме көч-иҗтиһад түккәнмен; маңгаемнан, битемнән, якты утка ялтырап, күпме ачы тир аккан икән; ә хәзер мин бернинди көч куймыйм, барысы да үзеннән-үзе килеп чыга иде. Тагы мин шуны сиздем: элек мәхәббәтем бик ерактан, билгесез йолдыз шикелле, сагыш кына сирпеп торганда, мин һәр эштә, мак-

талсам да, бер генә канатлы булганмын, очуның ни икәнен онытып, бер генә җирдә талпынып-бәргәләнеп ятканмын икән. Хәзер миңа канат ярып чыкты, мин, үзем дә сизмәстән, очып киттем. Моны иптәшләрем дә сизде. Сизми буламыни! Әлмира бер көн, гадәттәгечә якын итеп, үзем генә чакта әйтеп алды:

– Ярату үзеңә килешеп тора тагы! Тәре баганасыдай катып йөри идең – җан керде дә китте. Шулай була ул, ничә ел төмсәдәй утырсаң. Күзең төшәр дә үтәр, дип уйлаган идем – тирән баттың, тирән. Инде Азали нишләр? Бөтенләй канаты сынды бит мескеннең.

Мин аңа беренче кабат дөрләп кабындым:

– Нигә әле син һаман Азали, дип аза кубасың? Нигә аны бер мин яратырга тиеш? Нигә мин күзем төшкән, күңелем тарткан кешене яратмаска тиеш?..

– Һәй, чукынсана, миңа димәгәй! Син генә инде әзи бер генәсе! Ярат, әйдә!.. – дип кул селтәп китеп барды.

Иң авыры, әлбәттә, Әлмираның тузынып китүе түгел, Азалинең күңелгә тиеп торуы иде. Аның бөтен халәте хәзер җырда гына иде. Тик күпкә барырмы бу? Бер чигенә җитеп сынмасмы, өзелмәсме? Минем иң курыкканым шул иде. Куркуым чынлап та тикмәгә генә булмаган икән. Ялгызы өйдә калып, без кояшлы болында йөргәннең икенче көнендә ул өзелде. Аязып китте, дигәндә генә, ике-өч кабат гөжләп яңгыр явып үткән, аннан тагы сарка төшкән бер көн иде. Салкын тидеме әллә, дисәң, салкын тиярлек салкын да түгел иде алай. Ләкин, ни булса булды, Азали җырлый алмады: тавышы кинәт юкка чыкты. Грим бүлмәсендә тавышын көйләп караган җиреннән утырды да елап та җибәрде.

– Ни булды? Ни булды?.. – дип, янына җыелдык.

– Булмады... Юк... – ди.

– И малайкаем, температураң бар бит! – дип, иң башта Илеш кызы кычкырып җибәрде.

Аннары бүтәннәр дә:

– Тәнең ут та ут! Хәзер үк кайтып ятарга кирәк... – дип, элеп алдылар.

Концерт башланып кына киткән иде.

– Үзен генә кайтарып җибәреп булмый бит инде, – диде Әлмира.

– Кая, үзем алып кайтам, – дип, Таңсылу плащына үрелде.

Ләкин Азали:

– Юк, мин үзем дә кайта алам, – дип, аягына басты. Тик шундук кире утырды.

Нәкъ шулвакыт Фәридун җырлап чыкты. Ачык ишектән, гөжләп койган яңгыр шавыдай, клуб эчендәге халыкның кул чабуы ишетелеп калды. Мин, айнып киткәндәй, сәхнәгә чыгып йөгердем. Халык шашып кул чаба, аяк дөбердәтә иде. Мин, гадәттәгечә бер читкәрәк басып, Фәридунны көтәм. Ләкин ул чыкмый да чыкмый. Аптырагач, грим бүлмәсенә йөгереп кердем. Керсәм, Фәридуннан җилләр искән, Азали дә юк иде.

– Нәрсә дип халыктан кул чаптырып торасың инде? – дип, Әлмира каршыма килеп басты.

Мин, сәхнәгә чыгып, гаепле бер кешедәй, Фәридунның җырлый алмавын әйттем. Сәбәбен белгәч, халык басылып туктады. Әмма мин хафага төштем: шәп булмады әле бу. Фәридун иң яраткан җырларны халык үтенгәч кенә җырлый торган иде. Аның шулай ярты юлда өзелүе, Азалинең исә бөтенләй җырлый алмавыннан бүгенге концерт шактый ким булачак иде. Минем тәмам кәеф кырылды. Минем кәеф бүген болай да бик шәптән түгел иде. Бу авыл Таңсылуның сөйгән егете авылы булып, Таңсылу бүген бездән аерылды, егетенең әниләренә төште. Көндез ул зиратка да барып әйләнгән. Концерттан соң да егетенең әниләренә кайтып куначак иде. Бер елдан соң да шулай

оныта алмыйча зиратларга барып йөрүе, туганнарын якын итүеннән ике канатым берьюлы сынгандай булды. Димәк, ул тикмәгә генә Уралны ташлап китмәгән!..

Мине дә шулай ярата алыр микән соң ул? Гомумән яратамы әле ул мине?..

Шул уйлар эчендә мин, әйләнчек сарык шикелле, сәхнәгә бер чыгып, бер кереп йөри башладым. Бер чыгуымда иптәшләрем әйләндереп алды да:

– Азали урынына без Таңсылуны җырларга кыстыйбыз. Син дә әйт әле, Касыйм, бәлки, сине тыңлар, – диделәр.

– Чынлап та, Таңсылу!.. – дип, мин дә элеп алдым.

– Бернинди репетициясез-нисез халык алдына ничек чыгыйм инде, иптәшләр? – диде ул.

– Сиңа нинди репетиция кирәк? – дип, Алмас кызып китте. – Тавышыңны беләм, җыр сайлыйбыз да – бетте-китте, кодагый...

– Яхшы, алайса, – диде Таңсылу.

Унбиш минутлык тәнәфес вакытында репетиция үткәреп алдылар. Алмас тикмәгә генә мактанмаган икән: Таңсылу әйткән көйләрнең барысын да белә булып чыкты. Икенче баянчыбыз гына тарттыра алмады.

– Белмәве бик әйбәт, икәү генә чыгарбыз, Таңсылу, – диде Алмас.

Ниһаять, алар башкорттан «Таштугай» белән «Сандугач», татардан «Ай былбылым» көен сайлап алдылар. «Ай былбылым»ны Таңсылу үзе бик ярата булса кирәк: авыз эченнән һаман шуны көйләп йөри иде.

Ул җырларга чыгып киткәч, безнекеләр грим бүлмәсенең ишек авызына килеп өелделәр. Йөзләрендә Таңсылуның хәлен аңлап, дулкынланып, аның йөгенә керү галәмәте ярылып ята иде. Сәхнәдән Урал башкортының үзәкләргә үткеч ачы моңы агылып киткәч, бу галәмәт юылгандай бетте; инде барысы да ишек төбендә җырга бирелеп оеган, әсир булган иде. Мин Таңсылуга, ян пәрдәне чеметеп кенә ачып, бер як читтән карап тордым. Ул бөтенләе белән күбәләктәй талпынып очкан сагышка әйләнгән иде.

Ялан еркәйдең ай кәккүге юк,
Үд Уралкайыма кайтайым...

Кинәт йөрәгем өзелеп сызлый башлады. Бу сүзләрнең асылына яңа гына төшенеп, күкрәгемнән «аһ!» дип ут бөркелде: сөйгәненең үлемен җырлый иде бит бу Таңсылу!..

Чын башкорт көен чын башкорт авызыннан беренче кат ишеткән халык әсирләнеп таң калды. Тик мин генә һушсыз, бәхетсез идем: сөйгәнен юксынып моңлана иде бит бу Таңсылу!.. Инде минем авырып китүем бар иде.

Концерт бетеп халык дөбердәп кузгала башлагач, Таңсылу мине сәхнә артына алып чыкты да:

– Син үпкәләмә, Касыйм. Яме, кадерлем? Әйтмәсәм бер хәл иде – мин сиңа әйттем бит: бүген аларда булам, дидем. Син мине аңларга тиеш, Касыйм... – дип, яңагым, иякләремнән сыйпап-сөеп алды. Мин тагы янып-кабынып, аның кулларына тотындым.

– Аһ, Таңсылу!..

– Бүген булмый, Касыйм... Анда мине көтәләр. Калган көннәрем гел синеке... – Ул, минем кулдан ычкынып, сәхнә артыннан залга чыгып китте...

Ноябрь-декабрь, 1969

Редакциядән: Әсәрне тулысынча ***beznenmiras.ru*** сайтыннан укый аласыз. ■

Безнең тарих белән кызыксыну арта

Лирон Хәмидуллин

Соңгы елларда татар әдәбияты үрнәкләре Россиядән читтәге илләрдә дә тәрҗемә ителә башлады. Аеруча Төркия белән дустанә мөнәсәбәтләр җайга салынуга күңел сөенә. Бер гасыр чамасы бөтенләй дә аралашмый гомер иткән идек бит. Ике арадагы элемтәләргә чик куелган иде. Ә бит Россия мөселманнарының язмышы кыл өстендә торган заманда, унсигезенче йөз ахырларында Төркия солтанаты хөкүмәтебезгә ярдәмгә килгән.

1774 елда Россия белән үзара солых килешүен төзегәндә алар Эчке Россия һәм Себер тарафындагы мөселман оешмаларын берләштереп торырдай идарә (диния нәзарәте, мөфтият) булдыру һәм Коръәнне нәшер итү шартын куйганнар. Бүгенге көндә Төркиядә безнең язучыларның кырыклап китабы нәшер ителде һәм алар арасында аеруча Аяз Гыйләҗевнең тирән эчтәлекле әсәрләрен туплаган дүрт-биш китапның булуы сөендерә. Бу изге арадашлык хезмәтләрен бүген Казанда яшәгән төркияле кардәшебез Фатих Кутлу башкарып килә. Аяз Гыйләҗевнең тагын бер тарихи эчтәлекле «Йәгез, бер дога» романы узган елда венгр теленә дә тәрҗемә ителде. Ул әсәр Совет хакимияте елларында «Сталин лагерьлары»нда иза чиккән кешеләр язмышын чагылдыра. Шундый тоткыннар арасында венгр милләте вәкиле дә булган. Аяз белән алар Караганда төбәгендәге шахталарда бергә эшләгән һәм дуслашкан булганнар. Шуны истә тотып, венгрлар күренекле язучыбызның әлеге әсәрен бастырып чыгардылар һәм, Казанга килеп, әлеге китапны язучының гаиләсенә тантаналы рәвештә тапшырдылар да.

Ә менә 2017 елда Болгария мәмләкәтендә ике күләмле том итеп нәшер ителгән «Кубрат хан» китабының язмышы берникадәр икенчерәк төсмер ала. Ул китапның басылып чыгуын Татарстан халкы һәм язучының каләмдәшләре белмичә дә кала. Мондый хәл, мөгаен, күптән түгел көннәрдә генә гүр иясе булган халык язучысы Мөсәгыйт Хәбибуллинның байтактан бирле авырып түшәктә ятуына да бәйле булгандыр.

Мөсәгыйт каләмдәшебезнең бу романы тәүге тапкыр 1985 елда басылып чыккан иде. Халкыбызның борынгы тарихы белән кызыксынган күпләр өчен әлеге әсәр яңа бер ачыш булды. Унбиш мең данәдә нәшер ителгән ул китап тиз арада сатылып та бетте. Күренекле галимнәребездән Мирфатыйх ага Зәкиев белән Әбрар ага Кәримуллин, бу әсәрнең язылуын хуплап, күләмле генә мәкаләләр дә язып чыктылар. 1990 нчы еллардагы вакыйгалардан соң, беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев тырышлыгы белән, Казанда Кубрат хан каберлегеннән табылган бай тарихи хәзинә белән танышу мөмкинлеге дә булдырылды. Мөсәгыйт ул күргәзмәне берничә мәртәбә барып карады. Бер мәртәбәсендә мине дә алып барды. Шул вакытта аңарда «Кубрат хан» романын кабат бастырып чыгару хыялы туган иде. Аның шундый ук җитди эчтәлекле «Шайтан каласы» исемле, Идел буе Болгар дәүләте чорын чагылдырган романын редакцияләгән кеше буларак, «Кубрат хан»ның икенче басмасын нәшер итешүгә дә мине җәлеп итмәкче иде. Әдипнең яңа басмада Кубрат ханның Кара диңгез буендагы дәүләт эшчәнлеген дә киңрәк тасвирлыйсы, ханлык башкаласының Төньяк Кавказдагы Фанагория каласыннан хәзерге Полтава (ханлык чорында – Балтава) шәһәренә күчү вакыйгаларын чагылдырасы да килә иде. (Бөек Болгар дәүләтенең мәшһүр юлбашчысы Кубрат хан шушы Полтава өлкәсендә җирләнгән дә бит. Хәзер Петербургтагы

Эрмитаж музеенда сакланган, шул каберлектән алынган һәм 1990 нчы еллардан соң гына халыкка иркенрәк күрсәтелә башлаган бай хәзинә дә әлеге каберлектән чыккан ич). Ләкин миңа ул тарихи әсәрнең икенче басмасын нәшер итешүдә катнашырга туры килмәде. Аны чыгару «Мәгариф» нәшриятына йөкләнде.

«Кубрат хан» романының Болгария дәүләтендә нәшер ителгән ике томлыгына яңадан әйләнеп кайтыйк. Ул китапларның беренче томы ханлык башкаласы Фанагория каласында булган вакыйгаларны чагылдырадыр, дип уйлыйм. Чөнки китап исемендә үк әлеге шәһәр телгә алына («Хан Кубрат. Величието на Фанагория», том 1.) Алтмышынчы елларда, иң күренекле тарихчыбыз Альфред Халиков китапларын укыганнан соң, мин бер ел Болгариядә нәшер ителгән «Болгарский язык» журналын яздырып алган, анда төрки төсмерле сүзләрнең байтак булуына сөенгән идем. Хәзер исә хәтеремдә бер сүз генә саклана – болгарларның «тәмәке»не «төтен» (тютюн) дип атаганлыклары гына. Шуңа күрә «Величието на Фанагория» җөмләсенең мәгънәсен аңлата алмыйм, Краснодар краеның Таман ярымутравындагы элекке бер шәһәр исеме булганлыгын гына беләм. Кубрат хан дәүләте барлыкка китерелгәнче бу шәһәрнең Митридат хан (рус язмаларында кенәз, царь диелә) дәүләтенең башкаласы булганлыгы, аның биләмәсенә шулай ук Кырым ярымутравы да кергәнлеге бәян ителә. «Тумышы грек нәселеннән», – дип язсалар да, ул гомере буе Византия дәүләте белән сугышкан һәм үзенең атаклы Иран дәүләте (русча язмаларда фарсы сүзеннән алынган «Персия» атамасы кулланыла) башлыклары Кир белән Дарий токымыннан чыкканлыгын дәлилләргә тырышкан, диелә. Кайбер язмаларда Кубратның да Митридатны үзе үрнәк итәргә тырышканлыгы чамалана.

Китапның икенче томы «Хан Кубрат. Войната с хазарите» дип исемләнгән. Димәк, Болгар дәүләтенең хазарлар тарафыннан яулап алыну чорын чагылдыра. Бу томның 284-290 нчы битләрендә әсәрдә кулланылган кайбер татарча сүзләрнең болгарча аңлатмасы да китерелә. Әлеге томнарны тәрҗемә итүче белән таныштыру вазыйфасын да китапта теркәлгәнчә язу белән чикләнәм: «Превод – Гергана Стойчева-Нуша». Безнең нәшриятлар тәртибе таләп иткәнчә, китапның күләме һәм басылып чыкан данәсе күрсәтелә. Бу очракта мин андый мәгълүматны тапмадым.

Мәрхүм каләмдәшебезнең җан-бәгыре җәннәттә булса иде, дигән теләктә калам! ■

ФӘНЗАМАН БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ!

ИСЕМЛЕ КОШЛАР ХУҖАСЫ

Айдар Хәлим

Мин истәлекләр язу остасы түгел. «Бу вакыйга фәлән елның фәлән көнендә булды», – дип тәмләп, авыз суларын корыта-корыта, еш кына үткәннең беркем беркайчан бернәрсәне дә абайлап өлгерә алмаган томанлы чынбарлыгында кызыгып укыла торган истәлекләр язган каләмдәшләремнән матур көнләшү белән көнләшеп тә, бу сәләткә ия булмаганлыгыма үкенеп тә куям. Чынлап та, яңа кешеләр белән очрашканда, танышканда гына түгел, хәтта алар белән төпкә җигелеп заман йөген тартканда да кичерелгән хис-тойгылар, фикри бәрелешләр һәм башка конкрет очраклар, ничектер, хәтеремә кайчандыр кирәк булачак сәхифә булып сеңеп калмый. Алар минем башыма керми. Минем хәтер бары тик уңай һәм тискәре хисләр, әйтик, бу кешенең «яхшы» яки «начар» булуы, ягъни шәхеслелек-шәхессезлек тирәсендәге вакыйгалар белән чикләнә.

Фәнзаман чордашым һәм кордашым белән дә нәкъ шулай булды. Гомер бергә диярлек үткән, ә ул үтерепләр сагындыра, исләргә төшеп газаплый, анда барысы да «яхшы, уңай, кирәкле», ә менә шул бергә үткән «яхшы» гомердән аерып алып кына сурәтләр вакыйгалар юк кебек. Ә бит үтелгән гомер – үзе зур вакыйга. Бигрәк тә Ватан сугышы чоры, ятимлек башланган чор балаларына. Әйтик, тулгак тоткан хатынын ягылмаган мич арасында билгесезлектә калдырып, ир-егет фронтка китәргә мәҗбүр. Бер гаиләдән дүрт егет сугыш яланында ятып кала, ә менә гаиләсенә иганә акчасы – пособие дә бирмиләр, чөнки ниндидер «дүкәмит-ыспрафкалары» җитешми. Бер караганда, гомере нәкъ менә шундый кызганыч хәҗәт-ихтыяҗлар басымы астында үткән Фәнзаман белән мин танышып та, дуслашып та маташмадым кебек, чөнки без бишектән үк, югарыда әйткәнемчә, нәкъ әнә шул «мич арасында» туган бертуганнардан, яисә туганда ук таныш, дус булып туганнар халәтендә идек.

Фәнзаман безнең – тормышка сугыш елларында аяк басканнар арасында утызынчы еллардан башлап сыйнфый изелүнең иң авыр, иң газаплы, иң кешелексез мисалларына да мисал булып тора алган булыр иде. Дөрес, ул кемнәрдер кебек, бу хакта сөйләнергә, аеруча «сыйнфый изелүләре» турында «горурланырга» яратмый, сирәк очракларда, шартлары җитешкән мизгелләрдә генә чишелә иде. Моның өчен аңа ыгы-зыгыдан азат, тыныч өй вазгыяте, тыңларлык әңгәмәдәш, бигрәк тә муллардан да муллрак аш-су өстәле кирәк була иде бугай. Аның шулай булуына аңарда ун елдан артык

«фатирда» яшәвем чорында күп тапкырлар инандым. Казанда фатирым, Фәнзаман кебек, чын туганлык, якынлык тойгысы белән кабул иткән, тәрбияләгән, ашаткан-эчергән, бертуганнан да артык күргән кешем булмаганлыктан, мин чынлап та шул кадәр гомер искиткеч киң күңелле Фәнзаманда туктала һәм аның белән төн урталарына кадәр әдәбият, язучы һәм язмаучы язучылар турында фикерләшә, бәхәсләшә, еш кына эчләребезне кату алганчы сөйләшә-көлешә идек. Биредә хатын-кыз темасы да читтә кала алмый, чөнки тормышыбызны бизәгән чибәркәйләр Фәнзаманның, бер караганда, авырткан, икенче караганда, аңа рухи ял биргән, аның иң яраткан, нечкә, шул ук вакытта «бәхетле бәхетсез» стихиясе иде. Ул ваклыклардан өстен, көнкүреш мәсьәләләрен, тышка чыгармыйча, үзе генә хәл итә, шуның белән башкаларда андый «вак нәрсәләр»нең ике ятып бер тапкыр төшенә дә кермәгән кебегрәк тойгы калдыра иде. Бер уңайдан, аның мин белгән чорда даими рәвештә ялгызак яшәвен, безнең беркайчан да гаилә темасына кермәгәнлегебезне әйтеп китсәм, артык булмас кебек...

Фәнзаманның аш-су өстәле – үзе бер зур тема. Әйткәнемчә, гомер буе диярлек ялгыз яшәп, ул үзенең өстен-башын яхшы карады, яхшы ашады, «дендиларча» купшы киенде. Кара кәләпүшен киеп алса, мин аны Дәрдемәнд тарантасыннан төшкән татар зыялысы яисә бае итеп олылый идем. Киемнәрдән алганда, Фәнзаманның иң яратканы – кара костюм, галстуклы ап-ак күлмәк һәм аеруча яратканы... ак салам эшләпә иде. Ул, мөмкин булса, бу эшләпәдә йоклаган да булыр иде.

Фәнзаманның аш-су өстәле, дидек. Күз алдыгызга китерегез: бер зур коштабакта, ир-атларча әйткәндә, боты-ботка, канаты-канатка ботарланып «ыргытылган» (чынлап та ыргытылган!) өймәләмә тавык ите, урталай яисә дүрткә ярып пешерелгән кәбестә, сезонына карап, өем-өем булып, гүя базардан үзләре йөгереп кергән башка яшелчә, дөньяның барлык әчкелтем-төчкелтемнәре, җиләк-җимеш, өстәвенә, азык белән ишелеп төшкән суыткычыннан барысы да энәсеннән-җебенә кадәр чыгарылган (сакланган, вакланган, какланган!) ризыклар – болар барысы да Фәнзаманның азык-төлек рецептурасын ярыйсы гына күзалларга мөмкинлек бирә кебек. Әмма шунысы – спиртлы эчемлек юк, Фәнзаман аны кулланмый. Кулланган кешене дә бик өнәми. Бик сирәк, мин үтенгән очракларда гына, хуҗаның рөхсәте белән, өстәлгә бер шешә «сухой» куелуы мөмкин иде. Шушы урында әйтеп китсәм дә буладыр: бу темаларга күпме генә гәп куертсак та, Фәнзаман Батталның үз гомеремдә хатын-кыз даирәсендә юк-бар, бигрәк тә тозсыз (аны теге халыкта «сальный» диләр) сөйләгәнен ишетергә һәм аны аракы-шәраб күләгәсендә күрергә туры килмәде. Дөрес, хатын-кыз җәмгыяте алдындагы уңышлары, бәлки чираттагы «җиңүләре» турында бераз «шыттырыргалап» алырга яратса да, беркайчан да бу гүзәл җенес вәкилләренә кимсетеп карамады, киресенчә, ул аларны кайгыларны алып китә торган сафлык ташкыны итеп зурлый иде...

Әйе, нәкъ менә шундый табын шартларында янып-пешеп, әсәрләнеп, шулай кубарылып, күзләренең үткер нурларын сизгер уйната-уйната, кинәт кенә, ит калҗасыннан майлана төшкән куллары белән селтәнә-селтәнә төшеп китә ул туган гаиләсе, ата-анасы язмышының үтә дә газаплы төпкелләренә. Гүяки шул чорларның кансыз градуснигы, идәнгә төшеп, чәлпәрәмә килә, андагы терекөмеш идәнгә коела һәм терекөмеш, үле булса да, терелә...

Фәнзаман аны йөгертә башлый... Шунысы кызык, ачылардан да ачы юмор-сатирасы, чатнап торган гаделлек, матурлык тойгысы бу чынбарлыкны искә төшерсен, күз алдына китерсен өчен, аңа нәкъ шушындый ризкый муллык һәм шартлар кирәк булган, диярсең!..

1939 елда мал-туары конфискацияләнеп, ике тапкыр сөргендә булып кайткан саф мөэмин-мөслимин гаиләсендә дөньяга килгән ул. Менә, үзе дә сизмәстән, Фәнзаман ашавыннан туктый һәм мулла буларак сайлау хокукыннан мәхрүм ителгән атасы

тормышыннан фельетонга тиң чын хикәятләр сөйләп ала. Мондый чакларда кунак, авызын ачып, ашавыннан туктап кала. Фәнзаман кисәтә: аша, ашамасаң, сөйләмим, ди. Көлсәң – көл, еласаң – ела. Хәер, Фәнзаман иҗатында көлү белән елау икесе бергә йөрде. Ул үзе торганы белән тере фаҗига булса да, яшь аша елмаерга һәм дөньяны яраттырырга тырышты. Шуның нәтиҗәсендәме икән, иситкеч халыкчан, киеренке рухтагы әсәрләр иҗат итә алды. Шушындый бердәмлек һәм бергәлек аңа хәтта сатира белән фаҗигане бербөтен итәргә насыйп итте, нәтиҗәдә, трагизмнан яратылганыннан чыгыпмы, әллә шуңа үч итепме, Фәнзаман татар әдәбиятының иң халыкчан, акыллы һәм көчле сатирикларыннан берсе булып җитеште. Шуларга өстәп, ул газета-журналларның «туймас тамагы»на көн саен соралып торган фельетоннар, мәзәкләр, мәсәлләр остасы да иде. Журналистикада Фәнзаман язмаган жанр калмагандыр. Ул татар журналистикасының остазы һәм үтергеч тәнкыйтьчесе иде.

Фәнзаман дустымның биографиясе татар әдипләре арасында иң фаҗигалеләрнең берседер, мөгаен. Ничектер, алар бары тик тар даирәгә генә билгеле кебек. Мин, мәсәлән, болар хакында бик соңлап белдем. Әйткәнемчә, Фәнзаман аларны ныклап чишелеп китеп сөйләргә яратмый иде. Боларны күпләр, хәтта замандаш каләмдәшләре дә белми иде. Шуңа күрә, әлеге хакта берничә кәлимә белән генә булса да әйтми китү ярамастыр. Аның ата-анасын, башта мулла, аннан «кулак буларак», ике тапкыр сөргенгә җибәрәләр. Соңгы тапкыр сөргәндә Фәнзаманга нибары тугыз гына яшь була. Тере ата-аналарыннан ятим калгач, гаиләдәге биш бала өстенә кызамык дигән афәт ишелеп төшә һәм эне-сеңелләренең барысын бер-бер артлы «кырып-себереп» теге дөньяга алып та китә. Бу хакта ишеткәч, җан өши, тәнгә «бала йоннары» калкып чыга... Тугыз яшьлек баланың берүзенә никадәр фаҗига! Кечкенә малайны Хуҗәмәт детдомына озаталар. Әйе, балалар йорты түгел, «детдом»!

Минзәләне, Минзәлә якларын, аның район газетасын мин Фәнзаманнан да артык яраткан кешене күргәнем булмады. Ул Минзәлә өчен чәчрәп утка керә иде. Ул мәңгелек сөю иде. Мондый сөюдә аңа бәлки шагыйрь Рәшит Гәрәй генә якынлаша алгандыр. Кайвакыт мин Фәнзаманның шулкадәр дә туган җир баласы була алуының серләре турында уйланам да, ул туган җирен бары тик югарыда телгә алынган югалтулар, бигрәк тә бертуганнарын югалтулар аша гына шулай «мәңгелеккә китмәс өчен» үзенә туплый алгандыр, дигән фикергә киләм...

Фәнзаман белән беренче тапкыр танышуым хәтердә түгел. Ул, әлбәттә, Казанда булды. Ә менә аның тумыштан ук «гаделлек баласы» булуы, хаклык өчен чәчрәп чыгуы гел күз алдымда. Ул бары тик язучыларның гаделлек яулый торган Тукай клубындагы җыелышларның берсендә булгандыр, дип уйлыйм. 1967 елның кышында яшь татар язучыларының Бөтенрәсәй күләмендәге конференциясе булды. Без Фәнзаман белән шул көннәрдә чынлап туганлаштык. Әмма теләгәнчә бергә була алмадык, безне аерыр өчен барлык шартлар булдырылган, без көндәлек заман таләпләре тарафыннан таланган, бүленгән хәлдә, «карахтерларыбыз» белән икебез дә тынгысыз «сәях»ләр буларак, тормышта урын табу өчен көрәш уртасында торып калган идек. Бу көрәш бездән эшләгән-яшәгән урыннарыбызны туктаусыз алыштырып, күченеп тору, үзгәртүне таләп итте. Мин, Татарстан Язучылар берлеге киңәше белән, эшкә аякка басып кына килүче Түбән Кама төзелешләренә, ә Казан университетының журналистика бүлеген читтән торып тәмамлаган Фәнзаман Башкортстанның Калтасы район газетасына баш мөхәррир буларак китеп барды. Аннан соң без атаклы «кәмит»тәге «Фигаро монда, Фигаро тегендә» дигән кебек, еллар аша бер-беребез артыннан «куышып» йөрдек: ул килә, мин китеп барам, мин китеп барам – ул килә. 1971 елда мин Түбән Камадан Башкортстанга – Уфага күчендем, Фәнзаман исә Башкортстаннан Түбән Камага килде. Җитмешенче еллар уртасында мине Урал-Себер нефть кудыру идарәсенә өлкән ин-

женер итеп күчерделәр. Бу бетмәс-төкәнмәс командировкалар белән бәйле эш булып чыкты. Сигез-тугыз ел буе бер аягым җирдә, икенчесе күктә булды. Бу чорда Фәнзаман Уфага һәр җәй саен килеп, газета-журналларда эшләштерде. Ләкин заман атмосферасы, әйткәнемчә, безне беркайчан да озакка очраштырмады: йә ул килеп, мин китеп, йә мин китеп, ул килеп торган чакларда гомеребез дә әллә ничек кенә үтте дә китте, дисәм, моңа, кыен булса да, ышаныгыз. Бу бергәлек яшьтән үк кадерен белергә насыйп итмәгән Такташ Мокамайлары кебек якын булган замандашларның үткән гомерләрен үкенү белән искә алу кебек яңгыраса да, һич тә аптырамыйм. Нишлисең, без гомер буе бер агымда булып та биографик яктан бергә була алмадык. Шуңа күрә, соңгы ун елда минем Фәнзаманда «фатирдаш» булып яши алуым миңа Аллаһтан төшкән бер сирәк бәхет булып балкыды һәм шулай хәтердә дә калды. Ләкин бергәлекнең кадере озакка сузылмады, әле җир җимертеп йөргән Фәнзаман дустым көтмәгәндә безне мәңгелеккә ташлап китеп барды. Аны соңгы юлга озату, Минзәлә зиратындагы хушлашу минутлары, авыр кайгыдан бөгелеп төшкән дусларының, туганнарының һәм үземнең әйтелгән матәм сүзләрем төшемдә кебек кенә сакланган.

Әйе, заманыбызның фидакарь улы, халкының сирәк баласы, мәдәниятебезнең ал бирмәс көрәшчесе, әдәбиятыбызның талантлы вәкиле Фәнзаман Батталның иҗатына, тәрәккый мирасына тиешле бәя бирә алганыбыз юк. Бу – алдыбызда торган мөкатдәс бурычыбыз. Ошбу мәкалә шушы бурычны үтәү юлында бер җитди адым, Фәнзаманның ихтыярлы иңенә кунган ак күгәрчен булсын иде.

Искиткеч туры килү: көтмәгәндә генә мәкаләмнең азагына ялганып кергән «Фәнзаманның ихтыярлы иңнәренә кунган ак күгәрченнәр» дигән тәгъбир кайда һәм кайчан яратылган иде икән?! Бу Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән эшләнгән эш булды. Мин бит мондый могҗизаны көтмәгән идем!

Чынбарлыкта исә Фәнзаманның сыйнфый изелүдән ихтыярлы иңнәре дә, иңгә кунган ак күгәрченнәре дә чынбарлыктан, ягъни тормыштан алынган күренешләр иде! Мин бит аларны ун ел буе күреп, үзем аша кичереп яшәдем. Үзләренә күрә кечкенә тарихлары да бар. Һәм менә ул тарих.

...Гадәттә мин Казанга килгәч тә бу хакта Фәнзаманга хәбәр итеп куя идем. Ул: «Бүген сиңа куна барам», – дигән сүз иде. Артык соңга калырга тырышмыйм, чөнки бу мәсьәләдә дустымның талканы коры. Ул мине яктыдарак, үзе чыгып каршыларга, киткәндә озатып калырга, бергәләп кибеткә чыгарга ярата.

Йорт күгәрченнәрен аеруча үз күрә һәм аларны көн саен берничә тапкыр ашата иде. Ул – кош җанлы, күгәрчен җанлы Җан Иясе иде.

...Менә мин аның йортының ишек катына киләм, кыңгырауга басам. Күп тә үтми, ул аска төшә, аның ак салам эшләпәсен күреп алу белән, безгә күгәрченнәр тупламы ташлана, алар, өерелеп, Фәнзаманны уратып ала, иңнәренә куна һәм кесәсендәге даулый башлый:

– Кеше каршыларга да бирмиләр, сабакылар!.. – Ләкин күгәрчен халкын туктатырмын, димә! Фәнзаман абзый кесәсенә керергә һәм булган байлыгын бушатырга мәҗбүр: – Синең өчен шулай дау куптара алар бүген. Күптән килгәнең юк иде синең, сабакы!.. – ди ул миңа, елмаеп. – Болар белән үзең исәпләш!..

Аның күгәрченнәре дә, салам эшләпәле абзалары кебек дустанә һәм сабыр, алар кесәдәге көнбагышның кәтрәсен дә калдырмый җирдән чүплиләр, аннан иңгә, кулларга куна башлыйлар... Күгәрченнәрнең берсе Фәнзаманның иңеннән төшмәскә, аның белән фатирга үтәргә дә каршы түгел.

– Бүгенгә булмый, Әхмәт, – ди ул. – Күрәсең бит, абзаң кунакка килде...

Ихластан да, Фәнзаманның, әсәрләре генә түгел, кошлары да зиһенле, җисемле вә исемле иде... ■

Безнең мирас №2 февраль 2019

Уттан сау чыккан хәтер-хатирә

(Фронтовик әтием язмалары)

Рөстәм Мәһдиев

ҮЛЕМ БЕЛӘН ЙӨЗГӘ-ЙӨЗ*

Язмыштан узмыш юк, диләр. Адәм баласы өчен иң зур сынау яу кырында икән ул. 1418 көн дәвам иткән канкоешта ничәмә-ничә кеше шәһит булганын әле дә булса исәпләп чыгара алмыйлар. Төп-төгәл итеп аны исәпләрлек тә түгелдер. Сигез урынлы саннар фаразлана. Ә бит аларның һәркайсы кемнеңдер газизе иде. Күпме өмет өзелгән, күпме нәсел киселгән, күпме бала ятим калган! Кешелек җәмгыятенә, яшәешкә сугыш алып килгән коточкыч фаҗиганең асылы да нәкъ менә шундадыр. Сугышка кергәндә мин шушы мәхшәрдә исән калырмын, туган илемә кайтырмын, дип, һич кенә дә башыма китермәдем, хәер, бу хакта кем дә уйламагандыр. Ходайның рәхмәте, биш ел ут эчендә йөреп ник бер зыян-зәүрәт күрим! Ә шулай да Газраил фәрештәнең канат очлары кагылып киткән мизгелләр булды. <...>

1943 елның февраль башларында Сталинград өчен барган сугышлар фельдмаршал Паулюс кулга алыну белән тәмамланды. Идел буендагы бу каланы дошманнан саклап калуда йөз меңләгән ватандаш башын салды. Шәһәр, атаклы Зайцев йортыннан кала, хәрабә хәлендә иде. Анда исән адәм заты, хәтта берәр җан иясе дә калмады бугай. Бәрелешнең иң кызган бер көнендә батальонның парторгы безне – бертөркем сугышчыларны блиндажга җыеп, әңгәмә үткәрде, партиягә керергә өндәп чыгыш ясады. Бу орышта исән-имин калу икеле, барыбер мәхшәрдә әҗәлдән котылып булмас, инде корбан булсак, безне коммунист итеп исәпләрсез, диебрәк гариза яздык та, окопларга таралыштык. Шулай итеп «халык дошманы, мулла малае» дигән ярлык та-

Ахыры. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

*Текст, беркадәр кыскартылып, автор редакциясендә тәкъдим ителә.

гылып каһәрләнгән һәм кимсетүләр татыган 25 яшьлек егетегез ВКП(б) әгъзалыгына кандидат итеп алынды. Партия сафларына сугышчыларны кабул итүне ансатлаштыру максатыннан, кандидатлык стажы бер елдан өч айга кадәр кыскартылган иде. Рекомендацияләрне дә, өч ел урынына, берьеллык стажы булган партия әгъзалары бирергә хокуклы булды. Партбилетларны безгә өч айдан соң өләштеләр.

Сталинград өчен барган канкойгыч сугышлар тәмамлангач, гәрчә фронт сызыгы көнбатышка таба коточкыч тизлек белән тәгәрәсә дә, Идел буйларыннан тиз генә китмәдек әле. Хәзер инде чират сапер-минерларга җитте. Безнең подразделениене сугыш кырларын шартламый калган снарядлардан, миналардан чистартырга калдырдылар. Бу апрель ае иде. Яз, кояшлы матур көн. Аяз күктә бер болыт әсәре юк. Югарыда тургайлар сайрый. Миңа, хәрби задание итеп, пакет белән донесение тоттырдылар да, шактый еракта урнашкан штабка илтеп тапшырырга боердылар. Яндагы тимер юл разъездына чыгып, товар поездының ачык платформасына кереп постым. Хәйран юл узгач, поезд барган шәпкә сикереп төшеп калдым. Карта, компас буенча юнәлешне чамалап, үзәнлектәге җепшек карны ерып киттем. Ул вакытта миңа «тавык күзе» чире йоккан иде. Организмда витаминнар җитмәүдән яз көне була торган зәхмәт. Караңгы төшә башлауга, күзләр сукырая, кая барганыңны да күрмисең. Телеграф баганаларындагы чыбыкның зыңлаган тавышы буенча шактый ара үткәч, язгы сулардан шаулап торган елга ярына җиттем. Бер колга табып, шуның белән елга төбен капшап, Аллага тапшырып, көчле агымлы суга атладым. Берзаман тирән чоңгылга эләгеп, көч-хәл белән йөзеп чыктым. Ярга чыккач, биштәремдәге тротил шашканы ягып, киемнәрне киптереп алдым. Янә киенеп, тагы алга таба атладым. Яңадан елга шавы ишетелде, аны да ерып чыктым. Шул рәвешчә шактый баргач, караңгы төшә башлады. Суытып җибәрде. Салкын җилдән саклану өчен бер фанера кисәге табып, шуны телеграф баганасына сөяп, аркамны терәдем.

Җылыну нияте белән чыбык-чабык, кипкән әрем җыеп учак ягып карыйм. Зур өем коры чыбык күкерт урынына күз ачып йомганчы яна да бетә. Төне буе шулай бимазаланып чыктым һәм хәлдән таеп егылдым. Таң алдыннан гына изрәп йокыга талганмын. Кояш күтәрелеп, җылыта-кыздыра башлагач, тургай сайравына уянып киттем. Компас һәм карталар буенча ориентирларны барлагач, юлны дәвам иттем. Дала өсте ниндидер ялтыравыклы утлар белән бизәлгән. Шуның якындагысына барып карасам, камалышта калган фашистларга кыш көне самолетлардан ташлап калдырылган әрҗәләр икән. Алар җиргә төшкән шәпкә ярылганнар да консерв банкалары, таралып, кояш нурларында ялтырап ята. Арада четердәвек кәгазьгә төрелгән ипи, печенье, шоколад һәм шуның ише ризыклар бар иде. Ашамлыкны шулай үтә күренмәле кәгазьгә төрү тәртибе бездә сиксәненче елларда гына керде бугай, ә пөхтәлек, чисталык иясе алманнар ризыкны саклауның әлеге ысулын сугышка кадәр үк кулланганнар. Кар эчендә әйбәт кенә сакланган ашамлыклар иде ул. Тамакны ялгап алдым һәм биштәремә дә тыгызлап тутырдым. Ниһаять, тиешле пунктка барып җитеп, пакетны тапшырдым һәм үзебезгә кайтып киттем.

РОКОССОВСКИЙ

Белоруссиянең калын урманнары. Безнең подразделениегә, юан-юан наратларны аударып, бурап, бер тәүлектә йорт салу бурычы куелган. Эш авыр. Чи бүрәнәләр адәм күтәргесез. Фронт командующие өчен урман куелыгында яшерен ставка төзибез. Бервакыт эшләп ятканда затлы пальто, каракүл бүрек кигән берәү пәйда булды. Бу генерал Константин Рокоссовский иде. Ул, читтәнрәк, безнең эшләгәнне күзәтте. Тәмәке кабызды. Байтак вакытлар карап торды.

Шушы минутларда нәрсәләр турында уйладымы икән ул? Үзенең михнәтле язмышы, гаиләсе һәм якыннары турындамы? Инде бөек «юлбашчы» тарафыннан репрессиягә эләгүе хакындамы? Әллә 1939-1940 елларда НКВД гаскәрләренең полякларның меңәрләгән асыл ир-егетләреннән торган хәрби частьларын кырып бетерүе турындамы? Шушы сазлыклы урманда авыр эш башкаручы, үзенеке кебек ачы язмышлы йөзәрләгән хокуксыз бәндәнең киләчәге турында уйладымы икән? Ул кадәресе мәгълүм түгел иде. Әле хәзер дә булса гаҗәпләнеп куям: нигә шулчакта безгә бер сүз дә эндәшеп карамады икән ул? Безне эш атына, гап-гади солдатларга санадымы, әллә башында илкүләм зуррак фикерләр кайнаган чагы идеме?!

БАТАЛЬОННЫҢ СУГЫШЧАН ЮЛЫ

1941 елның июне-1942 елның апреле – Мәскәү оборонасы. Мәскәү өлкәсенең Истра районындагы Снегири авылы. Үзәк фронт составында Армия генералы К.К.Рокоссовский командалыгында сугышта катнашу.

1943 елның июль-августы – Орел-Курск дугасындагы тарихи бәрелеш. Поныри-Ольховатка торак пунктлары тирәсендә хәрби хәрәкәтләр.

1942 елның ноябре – 1943 елның феврале – генерал В.И.Чуйков командалыгындагы 62 нче армия составында Абганерово станциясе тирәсендә хәрби бәрелешләр.

1943 елның мае – Сталинград өлкәсен миналардан чистарту.

1943 елның сентябрь-декабре – Новгород-Северский һәм Коростень шәһәрләрен азат итү.

1944 елның гыйнвар-марты – Сарны, Луцк, Ровно, Здолбунов һәм Дубно шәһәрләрен азат итү.

1944 елның июле – Львов юнәлешендә немец оборонасын өзү. Владимир-Волынск, Рава-Русская, Рославль шәһәрләрен азат итү.

1944 елның августы – Сандомир шәһәрен азат итү.

1945 елның гыйнвары – Сандомир шәһәренең көнбатышында немец оборонасын өзү һәм Петракув шәһәрен азат итү. Шул ук елның февралендә Одер елгасын кичү һәм Шпротау, Кельце, Зорау шәһәрләрен азат итү.

1945 елның апреле – Нейсе һәм Шпрее елгаларын кичеп, немец оборонасын өзү, Эльба елгасына һәм Берлинга барып җитү, Виттенберг шәһәрен азат итү. Бу көннәрдә батальон сугышчылары союздаш армия – АКШ гаскәрләре белән очраша. Американнарның ачык машиналарга төялеп кара күзлек киеп, фотоаппарат асып, туристик сәяхәтчеләр кебек иркенләп йөргәннәрен күреп шаккаткан идек.

1945 елның мае – Берлинның көньяк-көнбатышында дошман группировкасын тар-мар итү.

Җиңү бәйрәмен батальон Чехославакия башкаласы Прагадан 60 чакрым көньяктарак – Хомутов шәһәрендә каршы алды.

Бу вакытта без 13 нче армия составында 19 нчы Кызыл байраклы Кутузов һәм Богдан Хмельницкий орденлы инженер-сапер бригадасында хезмәт итә идек инде. Соңыннан безгә Казаннан чыгып киткән 1200 кешенең йөз егермеләбе, ягъни нибары ун проценты гына исән-имин әйләнеп кайтуы билгеле булды. <...>

Хәзерге вакытта чикләр ачык, «халыклар атасы» корган «тимер чаршауны» тарих чүплегенә томырдылар. Ватандашларыбыз, зур акчалар түләп, чит илләргә сәяхәт итәләр, турист буларак, дөнья гизеп гыйбрәт алалар. Ил-көннәр тыныч-имин булгач, яшәү рәхәт шул. Ә менә безнең буынга язмыш чит илләрне урап кайту өчен бушлай юллама «тоттырды». Аллаһның рәхмәте, Польша, Чехословакия, Германияләрне

пуля яңгыры, снаряд кыйпылчыклары яңгыры астында түш белән шуышып, үтеп, туган илгә исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп булды.

ТУГАН ИЛГӘ КАЙТУ

Сугыш бетүгә, безне хәрби хезмәттән азат итмәделәр. Бер еллап Украинаның Житомир шәһәрендә хезмәт иттек. Бу чорда частьтан өлкәнрәк яшьтәге фронтовиклар тәртип белән өйләренә кайта башлады, ә алар урынына яшьләр килә иде. Алмаш килеп, хәрби тормышка күнегеп, бездән тәҗрибә туплагач кына туган якларга кайтырга приказ була иде.

Шулай беркөн строй белән өйрәнүләрдән кайтып бара идек. Рота командиры капитан Яков Биберман подразделение белән идарә итүне миңа тапшырды. Бу чакта мин инде кече сержант званиесендә идем. Офицер юлдан читтәнрәк атлый. Мин, гадәтләнгәнчә, җырларга боерык бирдем. Солдатларның бер өлеше җырны күтәреп алды, ләкин яңарак алмашка килгәннәр, авызларына су капкандай, ләм-мим. Арыганнардыр да инде. Өстәвенә, үҗәтлек-сансызлык та бар бит. Мин кабат:

– Запевай! – дип команда бирәм.

Санга сукмыйлар. Минем дә моңа хәтер калды. Әлбәттә, рота командиры да бу хәл белән килешә алмагандыр. Ничек инде ярты Европаны түше белән шуышып узган фронтовикларның сүзләрен сары томшыклы малай-шалай колакка да элмәсен, ди? Капитан казарма ишеге төбенә килеп җитүгә солдатларны стройга тезде дә җырга кушылган егетләр белән миңа кереп китәргә боерды, ә сансызларны аерып:

– Ә менә бу иптәшләр белән үзем бераз шөгыльләнәчәкмен, – дип, алып калды.

Байтак вакыт узып, без ашап, ял итеп туйгач кына тегеләр, мышнап, тирләп-пешеп кайтып егылдылар.

Шулай була ул, өлкәннәр сүзен санга сукмасаң, дип уйлап куйдым... Ачу-үпкәнең әсәре дә юк, чөнки командир егетләрдән бер адым калмый үзе дә, үрнәк күрсәтеп, «кросс»та катнашкан.

1946 елның май азакларында, ниһаять, безгә дә өйгә кайту чираты җитте. Тиешле кәгазьләр җыелды, боерык – кулда, зарыгып көткән туганнар белән күрешү бәхете көтә. Безне әлеге дә баягы товар вагоннарына төяп, тантаналы төстә озатып җибәрделәр. Эшелон Рязаньга килеп җиткәч, без – берничә якташ перронда төшеп калдык.

– Егетләр, нигә әле без Мәскәүдә халык кайнап торган вокзалда авыр биштәр-чемоданнар күтәреп тинтерәп йөрергә тиеш? Әйдәгез, минем арттан, – дидем.

Әйләнгеч булса да юл яхшы, дигәндәй, Горький шәһәренә баручы поездга кереп кысылдык. Ул безне Люберцыга китереп бушатты. Анда шәһәр яны поездына утырып, Муромга җиттек. Вокзал дигәннәре бер кечкенә генә алачык иде. Халык – шыгрым. Касса төбенә үтәрлек түгел, каплап алганнар, этеш-төртеш. Билетлар алу мөмкинлеге чамалы. Аны да состав килгәч кенә сата башлыйлар икән. «Мәскәү-Новосибирск» поезды килеп туктауга, халык вагоннарга ташланды. Кайбер җитезрәкләре хәтта вагон түбәсенә үк менеп кунаклады. Без, аптырагач, ике вагон арасындагы мәйданчыкка урнаштык. Вагон ишегенә фанер чемоданымны терәтеп куйдым да аркамны сөядем. Поезд ыжгырып алга чаба. Җил сызгыра. Бераздан пижамалы таза-таза ирләр тегендә-монда йөри башлады. Янәшәдә генә вагон-ресторан икән. Урынымнан кузгалып, аларга ишек ачып торырга мәҗбүр. Шул рәвешчә шактый баргач, сабырлыгым төкәнде. Проводникны чакырту өчен вагон ишеген каплаган фанераны кага-кага чыра иттем. Шулвакыт тәмәке көйрәтергә чыккан ирләрнең берсе проводник түтәйне чакырды. Ишекне ачуга эчкә бәреп кердек тә, апайны бөтереп алдык:

– Җиңүчеләрне вагонга кертми интектерәсең, бераздан төн җитә, шунда йокы аралаш вагон астына төшеп үлсәк, син генә гаепле буласың, хәзер үзеңне шунда тотып тондырам, – дип тузгыгач, юлдашларым мине тынычландырырга ашыкты:

– Берүк тавыш чыгара күрмә, безне харап итәсең!

Ул бичараларның тоткынлыктан кайтып килеше икән...

Ханым, елый-елый, безне үзенең купесына урнаштырырга мәҗбүр булды. Багажымны өске шүрлеккә томырдым да юыну бүлмәсенә киттем. Көзгегә күз салсам, өс-башым забойдан чыккан шахтерныкы кебек корымга буялып беткән. Юынып, кыяфәтемне тәртипкә китергәч, өскә менеп сузылдым. Берзаман йокы аралаш ишетеп ятам – купега контролерлар кереп билет тикшереп йөри икән. Проводник хатын, миңа таба ымлап:

– Зинһар, теге явызны уята күрмәгез, – дип, тикшерүчеләрне юмалап озатты.

Казан вокзалында юлдашларым:

– Якташ, синең белән рәхәтләнеп кайткан идек, алга таба нишләрбез инде, – дип хушлаштылар.

1946 елның 3 июне иде бу. Кайтып җиттем. Бу көн аерата хәтеремдә калган, чөнки шушы көндә радио: «Бөтенсоюз старостасы», СССР Югары Советы Президиумы рәисе Михаил Иванович Калинин вафат булды», – дип хәбәр итте.

Дүрт ел буе ут-ядрә яңгыры астында йөреп тә ничек исән калганмын? Күрәсең, газиз әнием Бибирәбига абыстайның догаларын кабул иткәндер Аллаһ Тәгалә! <...>

ОСОБИСТ

Фронтта алгы сызыкта гади солдат та, офицер да үзенә күрә бертигез шартларда, Аллаһ Тәгаләнең хөкемендә – даими куркыныч астында иде. Пуля, снаряд кыйпылчыгы, шрапнель «син кем?» дип сайлап тормый.

Әмма алгы сызыкның да язылмаган кануннары бар. Монда да тоталитар система үзенең мәкерле җәтмәсен җәйгән. Күзәтчелек, шымчылык хөкем сөрә. Уйламыйча берәр сүз ычкындырсаң, ялгышып берәр хәрәкәт ясасаң, шунда ук «тиешле урынга» барып җитә. «Тиешле урын» дигәннәре махсус бүлек, ягъни «особый отдел», тагы да киң таралган бер исеме – «смерш». Әлеге гаскәрнең төп бурычы – сугышчылар арасында сәяси һәм мораль вазгыятьне күзәтеп тору, Совет Ватанына каршы шпионлык, террорчылык һәм корткычлыкны кисәтү, хыянәт очракларын булдырмау. Бу бүлектә хезмәт итүчеләр үзенә аерым таифә. Алар аерым өстенлекләргә ия. Кермәгән җирләре, белмәгән әйберләре юк. Өсләрендәге киемнәре дә аерылып тора: ыспай, тәнгә сыланып торган затлы постаудан тегелгән френч, галифе, ялт итеп шыгырдап торган хром итекләр. Мундир якасында чия төсендәге петлица, фуражкасы да нәкъ шул төстә. Ялт итеп көлеп торган киемнәр белән чагыштырганда, йөздә мәрхәмәтнең әсәре дә юк: кырыс, елмаюсыз һәм нурсыз. Билгеле, гади сугышчылар аларны өнәп бетерми иде. Бәлки, шуңадыр, особистлар алгы сызыктан читтәрәк, ул-бу булмагае, дип, ышыграк урыннарда хәрәкәтләнүне өстен күрә. Күпме гаепсез кеше шушы бүлектәге җәлладлар кулыннан җан тәслим кылган?! Кем аларны санаган да, кемгә хаҗәт алар... Ул чорларда халык арасында еш кабатлана торган әйтем: урман кискәндә йомычкага исәп юк...

Алар да безнең кебек сугышта булдым, ватанга намус белән хезмәт иттем, дип кайтты. Аларның да күкрәк тулы орден-медаль иде. Әмма, татар әйтмешли, пәри башка – җен башка, шул, безнең бүләкләр ни дәрәҗәдәге батырлык бәрабәренә дә, боларның орденнарының бәһасе ни хакка...

Шулай да, сугыштан соң байтак вакыт узгач, миңа бер фронтташ «дусны» очратырга насыйп булды. Житмешенче еллар иде, ялгышмасам. Беркөнне Казанның Ирек

мәйданындагы 3 нче мунчага кергән идем. Чишенү бүлмәсендә хәйран нык бәдәнле, пеләш башлы бер яшьтәш игътибарымны җәлеп итте. Бу да чишенеп ята. Йөз чалымнары таныш кебек. Кылт итеп искә төште: нәкъ үзе бит – безнең батальонның «особисты». Фамилиясен дә хәтерлим – Аверкиев. Хуш, мин әйтәм. Барып күрешик, булмаса. Калай ләгәнгә су тутырып тора иде бу, янына якын килеп:

– Сезне каядыр күргән күк тоям. Иптәш майор Аверкиев, Сез түгелме? – дип әйтүем булды, коелып төште, йөзләре агарып китте моның:

– Гафу итегез, Сез мине кем беләндер бутыйсыз бугай, мин Сезне хәтерләмим...

– Икенче Украина фронты, 145 ОШСБ, – дип өстәгәч тә, иптәш майорның хәтер капчыклары сүтелмәде.

Соңыннан:

– Мин бик яхшы беләм Сезнең кайда һәм кем булып хезмәт иткәнегезне, – дидем, тыныч кына.

Әмма аның каравы, майорның хәле шәптән түгел иде. Мин урыныма киттем һәм аның аннан-моннан гына коенып, җыенып чыгып тайганын читтән күзәтеп тордым. Ай күрде дә кояш алды үзен.

Менә шулай, теге вакыттаниләр кылганы кеше хәтерендә саклана, төшләренә кереп бимазалый, тынгылык бирми ул. Ә Кыямәт Көнендә күрәчәкләре – Җәнабел Хак хөкемендә...

***

Әтинең шушы урында язмалары өзелә.

Бәхетемә, заманында үземә дә әтинең фронтташ дуслары белән очрашып танышырга насыйп булды. Кайсын гына алма, саф күңелле затлар, гаярь кешеләр иде алар. Сугыш михнәтләре, югалтулар ул шәхесләрнең бәгырьләрен катылатмаган, холыкларын тискәре якка үзгәртмәгән, ә киресенчә, йомшарткан, сабырлыкларын арттырган гына. Җиңү бәйрәме уңаеннан очрашуларында да булдым. Мәскәү оборонасында торган җирләргә, Ровно шәһәренә дә әтине озата бардым. Очрашуларның эчкерсезлеге истә калган. Чал чәчле фронтовикларның йөзләре шат, күңелләре күтәренке иде бу вакытта.

Әти, сугыш турында сөйләгәндә, гадәтенчә, сүзнең тәмен белеп хатирәләр диңгезенә чума иде. Шунысы гаҗәп: әлеге вакыйгалар моннан биш-алты дистә еллар элек булып узса да, әти аларны көне-сәгате белән хәтерли, вакыйга булган шәһәр һәм авыл исемнәрен яттан белә, һәм үзен сабыр, тыныч тота иде. <...>

Бөек Җиңүдән соңгы тыныч тормышта Габдерәшит Мәһдиевнең хезмәт юлы илленче елларда оешкан Яңа Чүриле районы белән бәйле. Ул Саклык банкында инспектор булып эшли. Гаилә корып җибәрә. Хатыны Нәгыймә Шәрәфетдин кызы белән өч бала үстерә. Казанга килеп, төзелештә балта остасы булып эшли. Берара сәүдә системасында сатучы булып хезмәт итә һәм алтмышынчы еллардан алып лаеклы ялга чыкканчы Казан аэропортының тәэминат бүлегендә инженер-техник вазыйфасын башкара.

Әти иманлы, сабыр холыклы, киң күңелле, тормышны, якыннарын, туганнарын өзелеп яратучы, табигатькә гашыйк зат иде. Ул татар халык көйләрен тальянда өздереп уйнады. Берничә тапкыр Татарстан телевидениесе тапшыруларында катнашу бәхетенә иреште. Язмыш аңа олы сынауларын да бирде вә бәхетле матур җитеш картлык та бүләк итте. Әти гаиләсендә дә, туганнары арасында да олы хөрмәткә лаек иде. Аңа оныкларын күреп, аларны иркәләп сөеп, күңелләрен күрергә насыйп булды.

Әти 2001 елның 26 гыйнварында, бабаларыбыз әйтмешли, «фани дөньядин бакый ахирәткә рихләт тындыйә», ягъни бу дөньядан мәңгелек ахирәткә күчеп тынды.

Кабере нурлы булсын иде! Амин! ■

Безнең мирас №2 февраль 2019

15 ФЕВРАЛЬДӘ СОВЕТ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ӘФГАНСТАН РЕСПУБЛИКАСЫННАН ЧЫГАРЫЛУЫНА 30 ЕЛ

Әфган дастаны

(бәяннан өзек)

Марат Закир

Хәрби машиналар колоннасы, чыгу юлына аркылы куелган колганы пыран-заран китереп, юлга кузгалды. Аягүрә йоклаган сакчының, уянып китеп, урыс матын куша-куша нидер кычкырганы гына ишетелде. Сакчы үзе күренмәде. БМПлардан купкан тузан болыты аны басып киткән иде.

Гадәти тормышта әһәмияте әллә ни шәйләнмәгән вак-төяккә дә сугышта игътибар бирелә. Сакчының шлагбаумны күтәрергә өлгерми калуы, чәрдәкләнгән агач тавышы... Хәерлегә булсын, хәерлегә...

Бу илдә җиләс җилне броняда барганда гына тоемлап була. Аның хәтта үзенә күрә бер романтикасы да бар.

Монда һәммәсе дә ком төсендә: чәнечкеле куаклар да, кояшта уңып, инде чәчәген койган мәк вә лаләләр дә, тузан кубаручы БМПлар да, шау-шу, гарасаттан өркеп, сыеныр урын эзләп чапкан кәлтәләр дә, совет яугирләре дә, аларның башындагы корыч каска да. Ком төсендәге сәфәр... Әмма бу сәфәр белән чикерткәле, күбәләкле чәчәкүләннәрдән кабарып-күбекләнеп торган болын буйлап матайда элдертү арасында Солтан үзе дә аңлап бетерә алмаган ниндидер бер уртаклык та бар. Тик болындагы һәр чокыр-чакыр таныш. Ә мондагы сәфәр үзенең көтелмәгән хикмәтләре белән

күңелне җәлеп итә. Нәкъ менә томан сарган юл сыман. Бу халәт тулаем бер сәфәргә дә, ике-өч сәфәргә дә – кыскасы, үлем исен иснәгәнчегә кадәр сузылачак.

Солтан бу юлы сугышка үз теләге белән китте. Нигә? Мондагы җиләс җил тәмен әллә татыганы юкмы аның? Автомат чакмасына басудан, шул дәһшәтле тимер көпшәсеннән кемгәдер үлем юллаудан әле гарык булмадымыни ул?! Кемдер аңа да үлем юллар. Алла үзе сакласын... Әле моңа кадәр ул бер мәртәбә дә яраланмыйча, контузия белән генә «котылган» иде. Инде – тфү, тфү, тфү... Ничек әле – «Лә иләһә илАлләһ». Изге сүзләрнең шуннан башкасын ул белми. Кирәксенмәде дә. Таҗик егетен әнә шул намаз укыган өчен бит инде күпме тинтерәтеп йөрттеләр. Төннәрен генә качып укый иде, югыйсә, бахыр. Кем саткан? Ә бүген таң алдыннан теге дәфтәрне кем эзләтте соң?

Намаз укучы таҗикны, «ычкынган», дип, кире Союзга озаттылар. Бер уйласаң, мондагы мәхшәрдән котылуың да хәерлерәктер. Ә менә Солтан бүген сугышка үз теләге белән кереп бара... Динле һәр кеше «ычкына» башласа... Якташ – Әбелгаян белән дә шул хәл килеп чыкмагае.... Мондагы «ычкыну» «илеңне сату» белән бер йөри.

Кышлак урамында җан әсәре сизелми. Карт-коры, бала-чага, хәрби колоннаны шәйләүгә үк, шылу ягын карый. Бу кышлак – царандой[1] кул астында. Әмма аларның царандойлыгы да шуның кадәрле генә. Кышлакны чыгар-чыкмас ук, урамда тугыз-ун яшьлек үсмерләр пәйда була. Гел шулай. Менә бүген дә аларны каш астыннан олыларча нәфрәт белән караучы, иңнәренә Калашников автоматы аскан кара-кучкыл, төксе үсмерләр озатып калды. Ук сыман атылган сүзләре генә колонна койрыгына барып ирешә:

– ...Мөртәт... Шоурави... Мөртәт...

БМП гөрелтесе аларның тавышын күмеп китсә дә, бу сүзләрнең әйтелгәнен Солтан яхшы белә. Чөнки гел шулай. Әле таш та атып калалар. Таш кынамы?!

Узган көздә урыс малае Пашка Медведев дөканны (кечкенә кибетне инде) бәрдергән иде. Юл чатындагы дөканда вак-төяк тауар сатып утырган хатын үзе дә, янындагы күкрәк сабые да, БМП астында калып, шундук җан бирделәр.

Нигә бәрдерде? Кызык өченме? Күрә-белә торып бит, югыйсә. Аңгыра урыс! Соңыннан әлеге аңгыралыгы башына да җитте.

Пакыстан чигеннән керүче корал кәрванын пыран-заран туздырып, кан, дары исеннән тәмам гарык булып, рота урнашкан тарлавыкка кайтып килешләре иде. Теге җимерек дөкан турысындарак менә шундый күренешкә тап булдылар: карачутыр ике үсмер чүпрәккә уралган ниндидер төргәк өчен тарткалашыпмы-тарткалаша! Ни әйтсәң дә, бала-чага бит – уенчык-мазар бүлешә торганнардыр... Ул да булмады, өлкәнрәге, төргәкне кечесеннән тартып алды да колонна кубарган тузан болыты арасына кереп тә югалды. Берничә мизгелдән исә шартлау яңгырады. Кайтып баручы колонна тукталды. Шартлау нәтиҗәсендә барлыкка килгән ыгы-зыгы бераз басылгач та, бөтенләй үзгә күренешкә тап булдылар: Пашканың машинасыннан – пыскып-төтәп торучы тимер өеме генә калган да, янә – күңелне айкап ташлаучы ис – янган адәм исе генә...

Канаты каерылган карчыганың кыядан ташланганын күргәнегез бармы сезнең? Дөканчы хатын аның әнкәсе булгандыр, күрәсең, ә күкрәк сабые – нәни энекәше... Кан үче... Кан үче...

[1] Царандой – әфган милициясе.

***

Колонна, Саланг үткелен үтеп, ниһаять, Әхмәт Шаһ Максуд[2] биләмәләренә килеп керде.

Каршыга кавын-карбыз төялгән бурбухайлар[3] очрый башлады. Ә Пәнҗ елгасы буендагы кишәрлекләрдә урак өсте бара. Дәһканнар (игенчеләр инде) өлгергән уңышны монда урак белән генә уралар. Юлларында «Тойота»лар, «Симург»лар (Японеиядә эшләнгән кечкенә йөк машиналары) җилдерә, дөкан базарларында «Панасоник» кебек фирма тауарлары белән сату итәләр, ә монда, имеш – кул урагы. Иге-чиге күренмәгән колхоз басулары булса, бер урак белән генә урырсың, пычагым! Солдатка алынганчы, Солтан үзе дә комбайн йөрткән иде. Әтисе мәрхүм дә гомере буе комбайнда эшләде. Бабасы да игенче булган, бабасының бабасы Мозаффар да – игенче!

Әле дә истә. Иртәгә китәсе дигән көнне Солтан өй чормасына менде. Берәүнең дә авылдан армиягә яңа кием киеп киткәне юк. Мунчага кергәч, карт солдатлар яңасын барыбер талап алып калалар, ди. Тузан җыеп яткан иске киемнәр арасыннан эзләнә торгач, ул, ниһаять, әтисенең кәчтүмен табып алды. Тап-таман. Түш кесәсендә ни-

[2] Мөҗәһитләр гаскәре башлыгы, генерал.
[3] Ике катлы йөк әрҗәсе таккан машина.

дер кабарып тора монын. Һе, менә сиңа вәт – бер уч бодай! Симәнә бодае бу – әтисе мәрхүм үләсе елны чәчүгә йөргән иде бит. Димәк, бу бодай кәчтүм кесәсендә җиде еллап яткан булып чыга! Һәм Солтан, кесәне әйләндереп, бер уч бодайны ишегалдындагы тавыкларга сипте... Шунысы, нигәдер, һаман да истә.

Ә монда вак-вак кишәрлекләр һәрберсе үзенә күрә аерым хуҗалык. Әйтерсең лә Алып батыр тау битенә үзенең яшел-сары ямаулы җиләнен салып калдырган да, Пәнҗ буена төшкән. Тешне сындырырдай салкын тау суы белән сусынны басыйм әле, дип, кул кушырып суга иелгәндер дә, шул көйгә тораташка әйләнеп калгандыр. Кем сихерләде икән аны? Әнә бит, әнә, дугайланып килгән ялангач кыя сырты – Алыпның аркасы инде ул, ә кул-аягы аның...

Әмма шул мәлдә рациядән рота командирының: «Тукталырга! Взвод командирлары – минем янга!» – дигән фәрманы яңгырады. Өлкән лейтенант, ике прапорщик һәм бер сержант (анысы Солтан үзе) Таратута янына ашыктылар.

Ә берничә минуттан рота, БМПларны калдырып, тауга күтәрелә башлады. Тау һавасы киемнәргә сеңгән төтен исен сыпырып алды. Тәмәке төтененнән, тузаннан

туйган үпкә күрекләре иркенәеп, сафланып китте. Баштарак гел шулай. Әмма тиздән, бик тиздән соңгы дым әсәреңне дә ялмап алырга сәләтле Әфган кояшы тешләрен ыржайтып күләргә керешәчәк. Кием белән тән бер-берсенә чат ябышачак, ә култык асларына катлам-катлам тоз утырачак.

Эзгә-эз басып килгән яугирләргә тауда тукталырга ярамый. Туктадың исә, аяклар, хәтта бөтен гәүдәң шундук агачка әйләнә. Үлсәң – үл, әмма су эчмә. Зыянлы. Барып җиткәч, бәлкем, әле ялы да эләгер, суын да эчәрсең.

Яугирләр арасында «арты белән киртә җимерүчеләр» дә очраштыргалый. Кемдер кояш сугудан һушын җуя, кемдер, сукмактан тайпылып, минага тап була, ә кемнедер авырлык сындыра. Устав буенча утыз кило гына каралса да, биек тауга Солтанның үз сыртында иллешәр килолы йөк (су, азык-төлек, корал, сугыш кирәк-яраклары) йөрткәне аз булмады. Ул инде хәзер чын мәгънәсендә сугыш аты, карт алаша, тагы да төгәлрәге – ишәк ул хәзер.

...Җегәре төкәнә башлады, ахрысы, алдарак баручы Әбелгаянның да адымнары сизелерлек үк сүлпәнәйде. Якташ анысы җиңел гәүдәле. Әле өчәр мең метр биеккә – күз күреме җитмәслек тау очларына күтәреләсе көннәре алда...Туксан килолы үзбәк малае Ниязбәк әнә өч көндә алтмышка калды. Җиңел гәүдәнең, әйе, зыяны юк аның. Нәҗес капчыгыдай уңга-сулга тугланучылардан монда рәт чыкмый.

Бу тау әле тау да түгел, ә бары тик баласы – урта бер сырты гына. Сукмак та, әнә, түбәнгә таба тәгәри башлады. Төшүе җиңел, аякларны туктатып булмый. Анысы, тау төшкәндә дә мәкерле хикмәтләр сагалап кына тора. Аягың тыңламаса, сукмактан тайпылуыңны йә булмаса очлы ташка килеп сылануыңны көт тә тор!

Мәгарәле тауга икенде намазыннан соң ярты сәгать узгач та килеп аудылар. Ә нигә соң әле җирле халык телендә «кяфер, шоурави» дип яманаты чыккан бу кавем (совет яугирләре инде) вакытны нәкъ менә намаз кылудан чыгып билгели дә һәм нигә әле – «аудылар»?

Алланың берлегенә вә кодрәтенә инану, җәннәт бакчасы, тәмуг газабы турында уйлану үзбәккә дә, таҗикка да, чеченга да, казакъка да хас. Әмма аларның шәригать кануннары белән ярашмаган гамәлләре дә бихисап. Араларында Эдик кебек үз

кавеменнән йөз чөергәннәре дә очраштыргалый. Бу – кяферләр корган империядә озак еллар иза чигү нәтиҗәсе. Җанлы, әмма ихтыярсыз курчакка (ә ихтыярлы курчакны әле кемнең күргәне бар?) әверелә язсалар да, аларда барыбер иман нуры саклана. Күмәк рәвештә көн күрү карашларны, үтә газиз, үтә үз ниятләрне вакытлыча гына булса да тирәнгәрәк яшерергә мәҗбүр итә. Ә телеңә, үткәнеңә, денеңә битарафлык әнә шул иман нурына гүр туфрагы булып ишелә дә инде. Урта Азия гомер-гомергә ислам җире булып саналган. Һәркем шуңа күнеккән. Шәрыкның кылы нечкә, бик нечкә аның. Һәм ул кыл белән гаҗәеп дәрәҗәдә сак кылану фарыз. Алласызлыкны да, нәсарилыкны да монда үтә сабырлык белән генә гамәлгә ашырырга маташканнар. Ә Рәсәй тырнагына эләккәннәрнең бәгырен гасырлар буе тегесе дә, бусы да, чукый торгач, чукып бетерә язган...

«Ми» дип аталган соры сыекчаң карыша... Ә курчакның мие була димени?! Димәк, син әле курчакка ук әверелеп бетмәгәнсең.

Һәркайда мәчет манаралары күзгә ташланган, һәрдаим азан тавышы яңгыраган бу илдә вакытның мөселман «шоурави»лары тарафыннан әнә шулай икенде яисә ахшам намазлары вакыты белән йөртелүе бер дә гаҗәп түгел. Ел исәбе дә бу якларда бөтенләй башкача. Болар календаре буенча хәзер монда 1367 елның көзе була инде.

Таудан күтәрелә-төшә унбиш-уналты чакрым ара узган яшь яугирләр, гәрчә әле кайчан гына Төркестан хәрби округының кайсыдыр өйрәнү полигонында алтышар ай сынау үткән булсалар да, Мәгарәле тау итәгенә чын мәгънәсендә килеп аудылар.

***

...Аңа кояшта янган каратут йөзле, ярым ай кашлы, киң җилкәле бер зат карап тора иде. Әй, кем син? Кем булсын инде – Солтан үзе! Челтер, челтер... Челтер, челтер... Кырынганда көзге кыйпылчыгыннан гына үз-үзен беркадәр күрергә гадәтләнгән чырай, янә, йотлыгып, суга текәлде. Тау суы шулкадәрле дә чиста, пакь ки, хәтта колак очындагы миңенә тиклем аермачык күренә. Тик шунда салмак су-көзге чәлпәрәмә килде. Янәшәгә йомры таш килеп төшкән икән. Кем атты? Кем булсын – Таратута!

– Вакыт җитте, сержант! Командаңны җый!

«Командаңны җый», имеш. Әйтүе ансат ул. Көч-хәл белән генә сафка тезелгән бу яшь-яшелләрдән ни мәгънә?! Черпаклардан кем бар әле монда? – Дубинин, тагы – Ян Пашаки. Боларыннан бәлки рәт чыгар. Ә бу яшел авызлар күрмәгәнен күрсәтәчәк Таратутага, күрсәтәчәк. Әбелгаян...

– Дубинин, Пашаки – алга! Якташ, син дә чык. Кем ул синең янда?

– Габбазов.

– Габбазов – алга чык!

Дүртәү җитәр. Инде болай да бу ике яшел авызны үз башына гына алды бугай. Хәерлегә булсын, хәерлегә. Юлга, тек, юлга! Сапер Ян – алдан, җилкәсенә АГС күтәргән Дубинин аннан соң, ә ике «яшел» – уртада, иң азактан Солтан үзе барачак.

Биш яугир Анарлы тауга менеп җиткәндә, ерактагы кышлактан кичке азан тавышы да ишетелә башлаган иде инде. Алар текә тауның нәкъ түбәсенә менеп утырдылар. Шулай ышанычлырак та, күзәтү өчен дә уңайлы. Ерактагы кышлакны уратып алган дуваллар да, очлы озын сөңгедәй күккә кадалган мәчет манаралары да, шул кышлактан башланган һәм бормаланып үтә торган тар сукмак та – һәммәсе аермачык булып, уч төбендәгедәй күренә. Менә ул – Солтанның аяк астында ук – текә кыя. Тагы да астарак, шул кыяга чат ябышып, ике агач үсә. Таш кыяда куак түгел, анар тикле анар җан асрасын әле! Бу илдә, анысы, адым саен могҗизага тап буласың...

Башта урнашып бетәсе, аннары исә капкалап аласы булыр. Әмма шул мәлдә өзек-

өзек урыс маты белән ярым чечен, ярым казакъ сөйләше колакка бәреп керде. Ни булды тагы? Артына борылып караса, Габбазов белән Дубинин чәкәләшә! Ул да булмады, озын буйлы, әмма чандыр Әсән тегене сугып та аударды. Дубинин, имән мичкәседәй, җиргә тәгәрәде. Тирәнгә киткәләгәнче, туктатырга кирәк боларны. Тапканнар сугышыр чак!

Дубинин (ул да үзенә күрә түгел – черпак) Габбазовтан АГСына оя казытмакчы булган. Әбелгаянга бәйләнер иде – Солтаннан шүрли, ә Ян – үзе черпак. Кем кала? Габбазов кала. Әмма Дубинин тегенең чечен икәнен истән чыгарган. Әнә шул «хәтерсезлеге» урыс малаен дүрт яугир каршында хур итеп ташлады да инде. Көлешеп торучы бу маңкалар белми генә... Солтан яшь яугир чагында чечен Вәлид әнә бөтен ротаны кулында тотты. Берсендә әнкәсен кимсетеп ике сүз әйткән өчен генә дә ун дембельгә каршы берьялгызы канга батканчы сугышкан иде ул. Искитмәле горур кавем...

Ул да булмады, зур таш артына сыенган Габбазовның шомлы тавышы ишетелде:

– Әне, текени көрип түрсез ба? – Бирәү, екәү, үшеү, төртеү! Солтан, әй, Солтан әкә!

Солтан бормалы сукмактан юыртучы гарәп атларын күргән иде инде. Сигез җайдак, уналты йөк аты! Бәлки корал кәрваннарыдыр, ә бәлки... Кайчагында «дух»лар иң алдан буш корал кәрваны да юллыйлар. Бушы артыннан чыны бара. Беренчесе поскакка (засадага) юлыкса, икенчесе йә эзен җуя, йә, тылдан һөҗүм итеп, поскакны пыран-заран китерә. Сәгать-сәгать ярымнан бу кәрван Мәгарәле тау итәгеннән узачак. Таратута белән рация аша элемтәгә керергә кирәк.

– Йөз унбиш, йөз унбиш! Бу – кырык өч, кырык өч! Төенле җеп... Уналты...

– Кырык өч, кырык өч! Бу – йөз унбиш. Төенле җеп. Аңладым. Элемтә тәмам.

Гарәп атларын алга әйдәүче сукмак тау арасына кереп югалган иде инде. Берничә сәгатьтән, ә бәлки төн уртасындарак – кимендә илле-алтмышлап «дух» озатуында корал кәрваны да пәйда булыр...

Беркавымнан күктә тау бөркете әйләнә башлады. Гомер-гомергә тау иленең күк падишасы булган бу кошка да көн бетте хәзер. Биләмәләремне бер әйләнеп кайтыйм әле, дип канат җилпергә дә өлгерми, бахырның каршына дәһшәти тавышлы диюләр – МИ-8ләр (хәрби вертолетлар, гадәттә, бер-бер артлы парлап очалар) килә дә чыга, килә дә чыга... Бүген, анысы, тынычлыкка-тынычрак. Әлегә...

Шул мәлдә Дубинин Әсәннең СВДсын (мәргән мылтыгын) алып, кошка төбәде.

– Әй, син, куй урынына! Атма! – дип кычкырды аңа Солтан. Әйткәнне ишетеп тә, ишетмәгәнгә салыштымы – Дубинин чакмага салмак кына басты. Әмма кошның ату тавышына һич тә исе китмәде. Ник бер җилпенеп канат каксын! Түбәндәге җан ияләрен үрти-үрти, ул талгын гына югарыга күтәрелүен дәвам итте һәм ноктага гына калып, тәмам күздән дә юк булды.

– Дубинин, кил әле монда!

Тегесе, мәргән мылтыгын җиргә ташлап, ахмак бер елмаю белән елмаеп, теләр-теләмәс кенә Солтан каршысына килеп басты. Кырын яткан Солтан кинәт кенә аның тезенә китереп типте:

– Нигә аттың?

– Ярамый что-ли?

– Башын җүләргә салучыны бездә нишләтәләр, беләсеңме?

–...

– Бар, көрәк ал! Кабер казы үзеңә!

Дубинин АГСы янына юнәлде. «Кабер казы» дигәне «окоп казы» инде ул. Тәртип-

тәрбия дәресе әле моның белән генә төгәлләнмәде. Горур чечен халкы вәкиле Әсән Габбазов та бар бит әле. Бу юлы әңгәмә уратып башланды.

– Син нигә казакъча сөйләшәсең?

– Казакъстаннан булганга!

– Ә үз телеңне беләсеңме?

– Ә нигә белмәскә – беләм!

– Тагы нәрсә беләсең?

– Урысча да беләм.

– Аны димим. Тагы нәрсә беләсең, дим мин сиңа, маңка!

– ...

– Үз коралыңны беркемгә дә бирергә ярамаганын беләсеңме?

– Хәзер беләм...

Шуның белән тәрбия дәресенә нокта куелды. Сабак озаграк саклансын өчен, дип, Габбазовның да тез капкачына эләкте. Дубининның ахмаклыгы кәефне җибәрде, каһәр. Һәр адымыңны үлчәп, кирәк икән, сулышыңны да тыеп тор да, менә сиңа вәт – тот та тиктомалдан күккә ат, имеш. Дубининны ул үзе сайлап алды. Димәк, үз башына. Хәерлегә булсын, хәерлегә...

Мөгаен, Солтан хәзер, Кабул-Ташкент самолетына утырып: «Хуш, мәңгегә, Алла каргаган ил», – дия-дия, туган җиргә юл тотар иде. Үкенүдән ни файда?! Соң... Карчыга борынлы икенде күләгәсе Әсән дә, ахмаклыгы йөзенә чыккан табак битле Дубинин да, салам кибәнедәй түгәрәк, сары Ян да, әнә, башын тагы кырын салган якташы Әбелгаян да, Мәгарәле тау итәгендәге рота да, гаярь Таратута да сиңа өмет баглап, ышанып тора. Ә син, Солтан – исәр, мокыт, хайван, җитте – үз-үзеңне кулга ал! Күңел төшенкелегенә кайткач бирелерсең, Алла боерса, кайткач. Көләрсең, еларсың, тагы әлләниләр кыйланырсың. Кайткач, тик өйгә кайткач...

Ахыры бар ■

Фотоларда – Әфганстан. Пәнҗ, Бәһрам, Саланг үткеле күренешләре. 1988-1989 еллар.
М.Закир архивыннан

НӘБИУЛЛА СОЛДАТ КЫЙССАСЫ

Мәгълүм булганча, Беренче Бөтендөнья сугышы 1918 елда тәмамлана. Россия әлеге сугыштан кабалалы Брест солыхы нигезендә чыга. Әйе, россиялеләр һәм, әлбәттә, безнең татар егетләре дә ул канкойгыч афәттә катнашырга мәҗбүр ителәләр. Нинди генә газаплар кичерергә туры килми адәм баласына! 1914 елда яуга алынган татар солдаты Нәбиулла Сибгатуллинның истәлекләрен укыганда күңелгә ирексездән шундый уй килде. Аңлашыла ки, мактаныр өчен түгел, ә башкаларга гыйбрәт булсын дип язган ул үзе күргән михнәтләр турында. Сүз дә юк, милләттәшебезнең бер гасыр элек кичергән хәлләре теркәлгән әлеге язма кадерле ядкәр булып тора. Аны Нәбиулла абыйның кызы Рәшидә апа Идрисова саклаган. Рәшидә апаның рөхсәте белән, кыскартып, солдат истәлекләрен «Безнең мирас» журналы укучыларына тәкъдим итәм.

Ильяс Салихҗан

1

Мин 1892 елда Акҗегет авылында туганмын (хәзерге Яшел Үзән районы. – И.С.) 1909 елда авыл мәктәбендә укып чыктым. 1910 елда әти белән Алатырьга барып, разноска лимон сатып йөрдем. Җәен кайтып, Себергә Томски каласына киттем. Барганда бөтен әйберләремне урладылар. Шулай да Томскига барып җиттем һәм әни белән бертуган Минһаҗ абыйларга төштем. Алар миңа күлмәк-ыштан бирделәр. Базарда алма сатып йөрдем. Аннан туган авылга 1914 елның сентябрендә кайттым. Октябрьдә солдат хезмәтенә чыгып киттем, ноябрьнең 16сында Себердәге Хабаровски каласына юл тоттык. Бер ай бардык. Анда 39 нчы запасный полкта бик каты өйрәттеләр. 1915 елның март аенда сугышка киттек. Егерме биш көн баргач, Грозныйга җиттек. Шуннан сугышка кердек. Мариопль тирәләрендә йөрдек. Мин 27 нче Себер укчы полкында хезмәт иттем. 1915 елның 26 маенда дүрт кеше пленга эләктек. Безне өч тәүлек Волговещевскида тоттылар да Алманга җибәрделәр. Штардгард дигән каласында тукталдык. Анда өч ай токкач, татар лагерена җибәрделәр – Военвург шәһәрендәге «Сусен» дип аталган лагерьга, анда 17 мең татар җыелды. Кышкы айларны шунда уздырдык. Ашарга бик начар булды, бака да пешереп ашаттылар. Ул лагерьда күргәннәрне язып бетерерлек түгел. Ходай күрсәтмәсен!

2

Май аенда боярларга, помещикларга эшкә тараттылар. Безне Приванцаль округындагы помещикка алып бардылар. Фреер Русиф атлы помещик-офицер җирендә җәй буе хезмәт иттек. Ашарга җитәрлек бирделәр. Көзен бәрәңге алдык, бик уңган иде бәрәңгесе. Шунда, нишләптер, ашауны начарлаттылар, ач эшләтә башладылар. Конвой бик усал кеше иде, Шмидт исемле. Атнага өч көн коры шалкан бирә иде. Селкенергә дә хәл юк, эшләргә дә кирәк. Ачтан үлмәс өчен, без, яшеренеп, бәрәңге пешерергә керештек. Кыш көнен голанка мичендә бәрәңге тәгәрәтеп, ачлы-туклы чыктык. Җәй җиткәч, икенче конвой килде. Некинь исемле иде анысы. Безнең өчен яхшы кеше иде. Шунда эшләвебезгә ел тулганда офицер үзе кайтты – хуҗа булганы. Ашау начар икәнлегеннән зарландык. Ул безне, сугыш вакыты, швайн, дип орышты. Әмма шулай да ашны күп бирә башладылар, бәрәңгене дә арттырдылар. Мостафа исемле иптәшебезне лагерьга җибәрделәр. Без ун кеше эшли башладык. Ике кеше качты. Лагерьдан бер башкорт карты килеп җитте. Бер ай үткәч, теге качкыннарны яңадан алып килделәр. Без тагын

Нәбиулла абзый хатыны Сабира түти, кызы Рәшидә апа һәм улы Тәлгать абый белән. 1979 ел

унбер кеше булдык. Яңа конвой килде, Клещи исемле. Түлке шунысы начар иде: кичке сәгать тугызга хәтле эшләтте ул безне. Тагын ике иптәшебез качып китте. Конвойны алыштырдылар, тегеләрне дә тотып кайтардылар. Бусы да нык эшләтте: йолдыздан йолдызга хәтле, җелеккә үтте.

3

Шунда өчебез – Хәмидулла Уфимский, Хуҗиәхмәт Бугульминский һәм мин – качарга уйладык. 1917 елның 4 нче ноябрендә кичке сәгать 7дә байдан качып чыгып киттек. Төн буе бардык, таң беленә башлагач, урманга кердек. Суык булды. Кич җитеп караңгы төште. Кузгалдык, урманнан чыгу юлын тапмадык. Адашып йөрдек. Кыргый дуңгызлар очрады. Курка башладык, безнең кулда бернәрсә дә юк иде. Хәмидулла карт елый башлады. Бара торгач, бер ут күренеп китте. Авыл икән. Тирә-юньдә сазлык булгач, авылга кердек. Бер хатын очрады. Ул тагын бер хатынны тапкан да, шуның белән безне тотмакчы булып арттан килә башладылар. Тотсалар – тотарлар, дип, чапмадык. Әмма алар безне куып җитә алмадылар, авыл читенә җиткәч, туктап калдылар. Тагын

төн җитте. Бара-бара бер өй янына килеп җиттек. Аның янында печән кибәннәре бар иде, шуның берсен чокып-казып кереп, йокы урыны ясадык. Иртән этләр килеп өреп йөрделәр. Тотсалар да, хуҗабыз ерак, аңа кайтармаслар, дип уйладык. Кибәннән чыгып, тагын юл тоттык. Бара торгач, бер авылга барып кердек. Анда бала-чагалар: «Русский, русский», – дип кычкыра-кычкыра безгә ияреп бардылар да авыл читендә калдылар. Без урманга кереп киттек. Аннан чыккач, атлыны күрдек. Ул тирес төяп килә иде. Без аны көтеп тордык та, немецча исәнләштек. Ә ул рус әсире булып чыкты.

Без аннан юлны сораштык. Аның өйрәтүенчә барып, калага җиттек. Эшләми торган кирпеч заводында урын табып, шунда кичкә кадәр йокладык. Утлар кабынгач, шәһәргә кердек. Урамда кешеләр йөри, ә безне туктатып сорау бирүче булмады. Инде каланы чыкканда, өч немец «марҗа»сы очрады. Без алардан тырыша-тырыша немец телендә, бу нинди шәһәр, дип сорадык. Алар көлделәр, билгеле инде, качып баручы әсирләр икәнлегебезне белделәр. Каланың исеме Иккермюнд, диделәр. Тагын өч чакрым узгач, авыл күренде. Анда бер карт немецны очраттык. Ул безне өенә алып керде, анда бер карчык бар иде. Карчык безне жәлләп елады һәм берәр кружка кофе эчерде. Ашыйсы да, эчәсе дә бик килә иде, яхшы булды. Карт безне бер йортка алып барып, хәрби формадагы кешегә тапшырды. Мылтык аскан дүрт немец шуннан безне Иккермюнд каласы комендантына алып барып тапшырды. «Ник качтыгыз», – дип сорады комендант. «Туган илне сагындык!» – дип җавап бирдек. Сорау алгач, шул йорт астындагы камерага төшереп ябып куйдылар. Иртән йөз грамм ипи һәм кофе бирделәр. Аннары тагын теге хуҗага алып киттеләр. Ике атнадан соң, лагерьдан фельдфебель килеп, мине тикшерде. Качкан өчен өч тәүлек арест бирде. Суык бүлмәдә ике йөз грамм ипи һәм су биреп, өч тәүлек утырттылар. Аннары чыгардылар. Кышны шул хуҗага эшләп уздырдым.

4

Безнең арада ревматизм белән чирләүче карт бар иде. Аяклары авырткач, ул эшли алмый иде. Карт качарга уйлады. Бер көнлек ипиебезне аңа бирдек. Шуннан соң конвой бик ачуланды. Эштән кайтуга, безне бикләп тота башлады. Ә хуҗа – тугыз потлы юан офицер бикләмәскә куша. Шулай да конвой усаллыгын итте. Без өчәү качарга булдык. Минем икенче тапкыр качуым иде, шуңа күрә бар әйберне алдан әзерләдек. Яшертен генә җыендык, бүтәннәргә әйтергә ярамый, алар конвойга җиткерәчәк, чөнки калучыларга читен була. 1918 елның июль аенда, урак башлангач, кичен чыгып тайдык. Ераграк китәргә тырыштык. Әгәр конвой күреп безне атып үтерсә, аңа 25 марка премия бирәләр. Законнары шулай иде. Без, урманга кереп, төне буе бардык, аннары яктыра башлагач, чыршылыкта туктадык. Шунда көн уздырдык. Кичкә таба яңгыр ява башлады, өс-баш манма су булды. Суыкка түзә алмыйча, юлга чыктык. Бара-бара бер помещик хуторына җиттек. Анда салам эскерте күреп, шунда тукталдык. Саламны казып кереп йокладык.

Уянганда яктырган иде. Чыгарга өлгермәдек, бертөркем бала килеп, эскерттә уйный башладылар. Өстән дә сикерәләр, баштан да таптап китәләр. Шактый уйнадылар безне таптый-таптый. Алар китеп караңгы төшә башлагач, юлга чыктык. Шулай алга барабыз: төнлә – юлда, иртән печән эченә кереп качабыз. Бара торгач, бер авылга килеп җиттек. Чиркәү янында мылтык тоткан каравылчы күренде, янында зур эте дә бар иде. Ул: «Һальт!» – дип, безне туктатты. Менә шул авылда тотылдык. Безне бер йортка кертеп яптылар. Анда иллеләп рус әсире бар иде. Иртән аларны эшкә тараттылар. Минем иптәшләрне дә берәм-берәм алып киттеләр. Мине иң соңында бер хатын килеп алды. Өенә җиткәч, бер кружка кофе һәм икмәк өстенә казылык кисәге салып, миңа

бирде. Шуны җайлап ашап җибәрдем. Аннары, чалгы тоттырып, кырга алып китте. Анда бер урыс эшли иде инде. Аның белән арыш чаптык. Ике көннән анысы бетте дә, борчакка тотындык. Бер атналап эшләдек немец «марҗа»сына. Шуннан соң безнең өчен талаша башладылар, чөнки һәрберсенә эшче кирәк. Бу хәл комендантка җиткән һәм ул тикшергән. Анысы безнең турыда лагерьга хәбәр иткән, ахры.

5

Озакламый мине «Сусен»га алып киттеләр. Ник качтың, дип сорагач, туган илне сагындым, дип җавап бирдем. Миңа биш тәүлек арест бирделәр. Ике атналап лагерьда торкач, тагын эшкә җибәрделәр. Яңа команда белән, Берлиннан ерак түгел, бер помещикта эшләдек. Көз җиткән иде, берсендә хуҗа, шәһәрдән кайткач, безгә яңалык сөйләде – тиздән сезне үзегезнең илләрегезгә җибәрәчәкләр, диде. Без бик сөендек. Бер якшәмбе көнне конвойдан шәһәргә барырга сорадык. Ул үзебезне генә җибәрде. Иркенгә чыгуыбызга исебез китте. Калага баргач, рус солдатлары очрады. Алар белән: «Здравствуйте!» – дип исәнләштек, тукталып, сөйләшеп алдык. Шәһәр халкы күңелсез иде, елаучылар да күренгәләде. Падишаһлары Вильгелм Икенче дәүләттән качып киткән икән. Озакламый сугыш бетүе ишетелде.

6

Беркөнне кич конвой кереп, безгә, иртәгә сәгать дүрттә «Сусен»га китәсез, дип әйтте. Россиягә кайтарып җибәрәләр, дип тә өстәде. Ул чыгып киткәч, тотындык Польша әсирләренә артык әйберләрне сатарга, спиртка алыштырырга. Төнне эчеп, җырлап үткәрдек. 1918 елның 16 декабрендә лагерьга кайттык. Төрле җирләрдән эштән безнең кебек командалар кайта. Барысы да шатлана. Ертык-портык киемнәребезне яңага алыштырдылар. Өс-башларыбызны карагач, беркөнне, берәр кирпеч икмәк, егерме биш сухой паек һәм берәр одеал тоттырып, станцага алып киттеләр. Эшелонга төялеп, Россиягә юл алдык. Воронович станцасына җиткәч, төшереп, әбәд ашаттылар. Кичкә таба тагын кузгалдык. Караңгы төшкән иде инде, поезд кинәт кенә шапылдап туктады. Башлар бәрелгәләп бетте. Бераздан вагон күтәрешергә чакырдылар. Алдагы берничә вагон кырылып ята иде. Бер вагон идәнен күтәреп карасак, хәйран калдык: анда сигез кеше такта кебек булып сытылган иде, хәтта күзләре дә атылып чыккан. Аяк-кулсыз калганнарның исә хисабы юк. Без, эшелон ахырында булганга, аумаганбыз. Поезд крушениесен бер еврей ясаган, диделәр. Имгәнгәннәр калмадылар, ыңгыраша-ыңгыраша булса да исәннәр белән бергә рәтле вагоннарга менделәр һәм паровоз әсирләр төялгән эшелонны тагын алга таба тартып китте. Змарински дигән станцага җиткәч, төштек. Шунда немецлар 8 пулемет корып тезелеп яттылар. Әллә сугыш бетмәдеме соң, дип аптырап киттек. Россия ягыннан кызыллар килә икән, шуңа әзерләнүләре боларның. Әсирлектән кайтучы барыбыз да туган илне нык сагынган идек. Шуңа күрә эшелонны көтеп тормадык, чикне җәяү чыгып киттек. Бер станцага җиткәч, безне, товарищи, дип, эшелонга утырырга чакырдылар. Юл үзәккә үтте. Озак кайттык, күмер юк, чи утын ягалар иде паровоз миченә. Көч-хәл белән Мәскәүгә, аннары Казанга җиттек. Өйгә 1919 елның 1 гыйнварында кайтып кердем. Әти-әни исән иде, елый-елый күрештек. Бөтенебез дә сөенештек.

Кереш сүз авторыннан: Нәбиулла солдат өчен сугыш моның белән генә тәмамланмый әле: аны тагын Гражданнар сугышына алалар. Тиф чире дә, ачлык та читләтеп узмый Нәбиулла аганы. 1942 елдан Икенче Бөтендөнья сугышында да катнаша. 1986 елда вафат була. ■

Истә, һаман да истә!

Дирижёр, педагог Җәләл Гаяз улы Садриҗиһановның тууына 110 ел

Дирижёр, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1944), РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1978) Җәләл Гаяз улы Садриҗиһанов 1909 елның 2 февралендә (искечә – 21 гыйнварда) Казакъстанның Җаек (Уральск) шәһәрендә эшче гаиләсендә туа.

Мәшһүр композитор, СССРның халык артисты (1957) Нәҗип Җиһанов (1911-1988) – Җ.Садриҗиһановның энесе.

Җ.Садриҗиһанов 1940-1970 елларда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында дирижёр булып эшли. 1945-1970 елларда исә Казан дәүләт педагогия институтында укыта. 1970-1979 елларда ул шул ук институтта җыр һәм укыту методикасы кафедрасы мөдире вазыйфасын башкара. Иң беренче дирижёрлык иткән әсәре 1941 елда (шулай ук 1943 һәм 1956 елларда да) Н.Җиһановның «Алтынчәч»е (текст авторы – М.Җәлил) була.

Дирижёры Җ.Садриҗиһанов булган кайбер әсәрләр:

«Галиябану» (композиторы – М.Мозаффаров, Мирхәйдәр Фәйзи драмасына нигезләнгән, 1944);

«Түләк» (композиторы – Н.Җиһанов, Н.Исәнбәтнең драматик әсәренә нигезләнгән, 1945);

«Акчарлаклар» (композиторы – Җәүдәт Фәйзи, Ш.Камал әсәренә нигезләнгән);

«Алтын тарак» (композиторы – Әнвәр Бакиров, 1957);

1997 елның 14 февралендә Казанда вафат була.

Татарстан Республикасының халык рәссамы Рушания Мостафа кызы Якупованың тууына 90 ел

Татарстан Республикасының халык рәссамы (2008), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2000) Рушания Мостафа кызы Якупова 1929 елның 3 февралендә Оренбург өлкәсендәге Кызыл Мәчет авылында туа.

СССРның халык рәссамы Харис Якупов – Р.Якупованың ире. Аларның өч улларының икесе – Фәрит һәм Әнвәр Якуповлар да рәссам булып танылды.

Р.Якупова 1953 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый. 1994 елда ул Татарстан Рәссамнар берлегенә әгъза итеп кабул ителә.

Р.Якупованың иң яхшы әсәрләре Татарстан Республикасының Дәүләт музеенда, шулай ук АКШ, Франция, Төркия, Германия һәм Израильдә шәхси коллекцияләрдә саклана.

Рәссам 2017 елда вафат була.

СССРның халык артисты Фуат Ибраһим улы Халитовның туууына 110 ел

Актёр, ТАССРның атказанган (1948), ТАССРның халык (1956), РСФСР (1957) һәм СССРның (1975) халык артисты Фуат Ибраһим улы Халитов 1909 елның 18 февралендә Казанның 4 нче (Зәңгәр) мәчете имамы һәм «Халидия» мәдрәсәсенең соңгы мөдәррисе Ибраһим Мөхәммәтзакир улы Халитов гаиләсендә туа.

1932 елдан Казан профессиональ «Эшче» театрына күчә. Шунда ук студия тәмамлый.

1937 елдан – Татар академия театрында.

1981 елның 15 (кайбер чыганакларда – 16) мартында вафат була һәм Яңа татар бистәсе зиратында җирләнә.

Ул башкарган рольләр: Вәли – «Аршин мал алан» (Г.Хаҗибәков); Гыйльманов – «Миңлекамал» (М.Әмир); Хуҗа, Бики – «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт); Әбделхәмит – «Фатыйма Сабри» (С.Җамал); Сәгъдетдин – «Шамил Усманов» (А.Гыйләҗев, А.Яхин); Әһлиулла – «Миләүшәнең туган көне», Әхтәм – «Ир-егетләр» (Т.Миңнуллин); Шәех мирза – «Американ», Миңлегали – «Зәңгәр шәл« (К.Тинчурин); Мәгънәви – «Синең урыныңа кайттым» (Р.Хәмид) һ.б.

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Флүн Мөслах улы Мусинның туууына 80 ел



Күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1991), Россия Гуманитар фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1995) Флүн Мөслах улы Мусин 1939 елның 23 февралендә Татарстанның Мөслим районындагы Иске Карамалы авылында колхозчы гаиләсендә туа.

1957-1962 елларда М.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының филология факультетында белем ала.

1963 елның маеннан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1996 елдан – Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәдбият һәм сәнгать институты) әүвәл – кече, аннары өлкән фәнни хезмәткәр, баш фәнни хезмәткәр булып эшли.1983 елда М.Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтында «Татар совет прозасында сәнгатьлелек тәҗрибәсенең күчемле үсеше» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. 1993 елда профессор дәрәҗәсен ала.

1991 елдан «Татар мирас фонды» президенты, шул ук елда җәмәгать башлангычы тәртибендә чыгарыла башлаган «Мирас» (хәзер «Безнең мирас» исемен йөртә) журналының беренче баш мөхәррире була.

Ф.Мусин 2009 елның 22 сентябрендә Казанда вафат була һәм Киндерле мөселман зиратында җирләнә.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2019

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ*

Тел курае

* Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

КУРАЙ

Тау куенында, кояш иртәсендә
Кура үсә, пешә, торая...
Чын курайчы аннан курай уя,
Әверелә кура курайга...

Зөлфәт

Ата-бабаларыбыз музыка уен коралларын табигатьтән алганнар. Алар, әлбәттә, җил искән саен кураеп сынган кура үләненнән ишетелгән музыкаль авазларга, нык итеп тарттырылган җәя кылының зыңгылдавына игътибар итми калмаганнардыр. Болар – табигать бүләк иткән иң гади уен кораллары.

Курайга охшаган уен кораллары борынгы төркиләр яшәгән һәм курай ясарга яраклы кура үләне үсә торган урыннарда гына очрый. Алар бер үк төрле мәгънәне аңлата. Алтайлардагы – «каурай», монголлардагы – «хуурай», себер татарларындагы – «курау», венгрлардагы – «koro» сүзенең нигезендә кибеп, корып, курап беткән камыш сүзе ята. Шулай ук безнең татар һәм башкорт халкы да аны, *кура* сүзенә *-ай* кушымчасы ялгап, «курай» дип йөртә.

Көпшә курайлар бу якларга һуннар, соңрак XII-XIII йөзләрдә монголлар белән килеп кергән булырга мөмкин. Чөнки нәкъ курайга охшаган «цуурай», «хуурай» дигән уен кораллары монгол, тыва тарихында күпкә иртәрәк искә алына.

Курай ясау күренеше халык авыз иҗатында да бик кызыклы итеп тасвирлана:

Аягын, башын кистем,
Корсагын тиштем,
Эченә өрдем,
Моңайганын күрдем.
Яисә:
Урманда кистем,
Эчен-бавырын уйдым,
Кабыргасын тиштем,
Әби көен ишеттем.

1768-1769 елларда танылган урыс галиме И.И.Лепехин Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче халыкларның музыка коралларын өйрәнгәндә: «Татарлар «курай» дип аталган музыка коралында яратып уйныйлар», – дип язып калдырган.

Күренекле татар галиме Солтан Габәши 1931 елда Татарстан районнары буйлап оештырылган фольклор экспедициясендә катнаша, онытылып барган халык уен коралларының хәзерге торышын өйрәнүгә аеруча игътибар итә. Татарларның өч төрле курайда (көпшә курай, тел курае, әзер тавыш сыбызгысы булган татар кураенда) уйнауларын әйтә һәм, татар кураеның концепциясен эшләп, Халык комиссариатына тапшыра. Шул ук вакытта башкорт галимнәре дә башкорт кураеның концепциясен әзерлиләр. Башкортстан хөкүмәте башкорт кураен торгызуга җиң сызганып алына, нәтиҗәдә, тиңе булмаган уен коралы – башкорт курае торгызыла. Ә Татарстанда Солтан Габәши эшләп тапшырган концепцияне читкә алып куялар.

Бу урында чын кура үләненнән ясалган курай турында беркадәр тукталыбрак язып үтәсем килә. Беренчедән, татарлар яшәгән бик күп урыннарда чын курай үләне үсми. Татарстанның да бары тик Азнакай, Баулы һәм Бөгелмә тирәләрендә, шулай ук Башкортстанның да көньяк-көнчыгыш районнарында гына үсә ул. Әгәр дә ку-

Кура үләне

райны гомум татар уен коралы дип санасак, элекке заманнарда аны нинди көпшәдән (материалдан) ясап уйнаганнар? Әллә кура үләненнән ясалган бу төр курайларда Татарстанның Кама аръягында яшәүче татарлар гына уйнаганмы? Әллә моңлы курай турында ташка язып калдырган сүзләр, халык хәтерендә сакланып килгән җырлар *әзер тавыш сыбызгысы* булган, агачтан ясалган *татар курае* турында барамы?

Гомумән, татар халкының барлык музыка уен коралларын да үзең ясап, асылына төшенеп, мәгънәсен аңларга тырышасың икән, шундый рухтагы мең дә бер сорау туа да тора. Әлбәттә, аларга җавапны мөхтәрәм музыка галимнәребез, фольклор белгечләре табарга тиеш.

Инде галимнәр турында сүз чыккан икән, тагын бер бик зур һәм кичектергесез мәсьәләне хәл итәргә кирәктер. Әйдәгез, курай уен коралының исемен ачыклыйк әле. Алда әйткәнемчә, татар халкы гомергә өч төрле курайда уйнаган һәм бүген дә уйный: *көпшә курай, тел курае, татар курае*. Моны С.Габәши дә, И.Мусин да, И.Хисамов та ассызыклап әйткәннәр. Мин үзем дә шул фикердә. Әлеге хезмәтемдә дә аларны шул тәртиптә, шул исемнәрдә урнаштырдым.

Бу урында тагын кызыклы гына бер сорау туа. *Көпшә курайны* да, *тел кураен* да *кура* үләненнән ясаганнар. Ә менә *әзер тавыш сыбызгысы* булган бу төр курайларны кура үләненнән ясап булмый. Әлеге уен коралы ни өчен курай дип атала? Әлегә бу сорау да сер булып кала.

Кайбер белгечләр өреп уйный торган күп кенә уен коралларының исемендә «оран», «өрү» сүзе ята, дип саный. Урта Азия, Кавказ халыклары уйный торган «зөрнә» сүзенең нигезендә дә «өреп уйнау» мәгънәсе бар кебек. «Шоор», «соор» сүзләре дә өреп уйный торган уен коралларына әйтелә (кыргызларда ул «чоор» дип атала). Бу күзлектән карасак, «курай» сүзе үзен аклый да кебек. Татар халкы да аларны, агачтан, җиздән, металлдан ясалуына карамастан, «курай» дип йөртә.

Әзер тавыш сыбызгысы булган курайлар халыкта *көпшә курай*лардан аерым, параллель рәвештә яшәгәннәр, камилләшкәннәр. Казу эшләре барышында безнең эрага

кадәр үк сөяктән, металлдан, агачтан эшләнгән һәм курайга охшаган көпшәләрнең табылуы билгеле. Бүгенге Хакасия җирендә бу төр курайга охшаган уен коралында уйнаучының таш кыяга ясалган рәсеме бар. Белгечләр исәпләве буенча, бу рәсемгә 23000 ел.

Нинди материалдан ясалуына һәм нинди җирлектән булуына карап, курайның исеме төрлечә аталган: такыя курай, көпшә курай, кырлы курай, тел курае, Казан курае, сыбызгы курай, җиз курай һәм башкалар.

КӨПШӘ КУРАЙ

Әйтеп киткәнемчә, көпшә курайларда төрки халыкларның барысы да диярлек (шул исәптән, татарлар да) уйнаган һәм хәзер дә уйныйлар. Әмма башкорт халкы әлеге уен коралын аеруча хөрмәт итте, аны ясау, башкару мәктәбен булдырды. Шуңа да бу төр уен коралын халык күбрәк «башкорт курае» дип белә.

Мондый курайны ясау – гаять җиңел эш. Көз айларында аларны үсеп утырган җирендә үк ясап, шунда ук уйнап та булган. Әйтик, ике башы тигез итеп киселгән 600-800 мм озынлыктагы, 15-20 мм диаметрлы өлгергән кура үләне алына. Өлкәннәр сөйләве буенча, тишемнәрне тотым яисә бармак киңлеге буенча үлчәп тишкәннәр. Аның нәзек башыннан уч белән бер тотым (яки дүрт бармак) киңлеге тотасың да, пәке белән бер тишем ясыйсың. Тишемнәрнең диаметры 8-15 мм. Шул тәртиптә 2-2,5 бармак аралыгы калдырып, курайга биш тишем тишелә. Соңгы бишенче тишем өске тишемнәрнең нәкъ аскы ягына урнашкан. Тишемнәрне болай итеп үлчәп тишкәндә тавыш югарылыгы бик туры килеп тә бетмәскә мөмкин. Ләкин һәр останың үз сиземләве була. Кура үләненең озынлыгына һәм диаметрына карап, тавыш югарылыгы төрлечә үзгәрә.

Кура үләненнән ясалган курайлар бик тиз ярыла, сына, ватыла торган булганнар. Шуңа да аларны соңгы елларда агач шпонны төреп ясый башладылар. Шпоннан ясалган курайлар чыдам, тавышы көчле, тембры матур, билгеле бер тавыш югарылыгына көйләү өчен уңайлы. Бу эшне иң беренче тапкыр 1976 елда Уфа каласында гомер кичерүче уен кораллары ясау остасы Вәкил ага Шөгаепов башкарды.

Үзлегеннән башлап ясарга теләүчеләр өчен *ля мажор* кураеның үлчәмнәрен биреп китик. Моның өчен 0,5-0,7 мм калынлыктагы, 30-35 мм киңлектәге, 70-90 мм тирәсе озынлыктагы бер бит *каен* яки *имән* агачыннан ясалган шпон алына. Аны бер тәүлек тирәсе кайнар суга салып тоталар. Судан алып, берничә сәгать торганнан соң, шпонның бер ягын тигез итеп җилемләп (күп очракта казеин җилеме (келәе) кулланыла), алдан әзерләнгән металл калыпка тыгыз итеп чыдам җеп белән ныгыталар һәм җылы урында киптерәләр. Калыпны дөрес ясау бик мөһим. Ул кыру станогы ярдәмендә *бер метрлар тирәсе* озынлыктагы металлдан *конус сыман* кырып эшләнелә. Кибеп җиткәч, җепне сүтәләр һәм әзер көпшәне эчтән дә, тыштан да яхшылап чистарталар. Баш-башын 720 мм озынлыкта кисеп алалар, электр яндыргычы (выжигалка) ярдәмендә тишемнәр тишәләр. Аннан соң инде эчен дә, тышын да лакларга мөмкин. Биш тишемле бу төр курайның әзер тавыш сыбызгысы юк. Баш-башларының эчке диаметры 16 мм һәм 13мм. Димәк, металл калыпның да тышкы диаметры шушы үлчәмгә туры килергә тиеш. Көпшәнең нәзек башыннан беренче тишем арасы – 81 мм, икенче тишем – 143 мм, өченче тишем – 200 мм, дүртенче тишем – 258 мм, аскы яктагы бишенче тишем – 325 мм.

Курайда тел һәм иреннәр белән көйләп уйныйлар. Башта тавыш чыгарырга өйрәнергә кирәк. Өйрәнүче кеше курайның бер як кырыен өске тешләрнең нәкъ уртасына, ике теш арасына тери. Көпшәнең авыз эчендә калган өлешенә аскы яктан яны белән телне куя. Өске аңкау һәм тел арасындагы ярыктан курай эченә «т-ж-ж-ж» дип

һава өрәбез. Өргән һава читкә китмәсен өчен, курайның бер як кырыен иреннәр белән каплап куябыз. Ә авызның икенче яртысы, курайдан чыккан тавышны яңгырату өчен, ачык кала.

Өйрәнүче төрлечә өреп карарга тиеш. Көпшә курай, музыка коралы буларак, бик гади. Әмма аның сихри моңына, аһәңенә ия булу өчен, бик түземле, тырыш хезмәт таләп ителә.

ТЕЛ КУРАЕ

Халыкта шундый ук кура үләненнән ясалган курайның үзгә төрлесе дә яшәп килә. Ул халык арасында «тел курае» дип атала.

Беренче тапкыр тел кураен 1983 елда Актаныш районының Иске Сәфәр авылында яшәүче Нәҗибә апа Солтанова уйнавында очраттым. Ул дүрт тишемле металл (дюраль) көпшәдән ясалган иде.

Азнакай районының Туйкә авылында яшәүче Зөфәр ага Камалов 1980-2000 нче елларда ике тишемле тел курайларын ясауга һәм аны пропагандалауга аеруча зур өлеш кертте. Күп кенә фольклор ансамбльләре һәм аерым башкаручылар ул ясаган курайларда уйнады. Зөфәр ага ураны көздән үк җитәрлек итеп урманнан җыеп кайта, ел буе курай ясый һәм үзе дә искиткеч матур итеп уйный иде.

Тел кураен болай ясыйлар. Өрә торган юан башын кыеклап кисәләр, якынча 8х8 мм зурлыкта тавыш тәрәзәсе уялар. Тавыш чыгару өчен, курайның тавыш тәрәзәсе астына телне куеп, бөке, сыбызгы ясыйлар һәм тел белән көйләп, өреп уйныйлар. Дөрес итеп өрүгә аеруча әһәмият итегез. Чөнки, өрүнең көченә карап, бер үк тишемнән ике, өч югарылыктагы тавышлар чыгарырга була. Шуңа да ике генә тишемле курайда да пентатоник лад аралыгындагы барлык тавышларны һич авырлыксыз уйнарга мөмкин.

Соңгы елларда бу төр курайларны да, көпшә курайлардагы үлчәмнәр буенча, биш тишемле итеп шпоннан ясый башладылар.

ТАТАР КУРАЕ

Татар халкы бик борынгы заманнардан ук *әзер тавыш сыбызгысы* булган курайларда да уйнаган. Бу төр уен коралы безнең өчен аеруча кадерле, чөнки милләтебез аны иң авыр вакытларда да ташламаган, ясаган, уйнап, күңелен юаткан.

Элек татар кураен күп очракта чикләвек, өрәңге, балан агачыннан ясаганнар. Аның озынлыгы 250-300 мм. Тишемнәренең саны икедән алтыга кадәр.

Мин үзем татар кураен да агач шпоннан ясарга тәкъдим итәр идем.

Хәзерге татар курае төзелеше һәм уйнау алымнары белән флейтага бик якын, тик тавыш чыгару җайланмасы гына башка. Димәк, курайны дөрес тотып уйнарга өйрәнсәң, флейта, габой, саксофон кебек музыка коралларына күчү дә күпкә җиңеләя.

Соңгы елларда татар кураена игътибар күпмедер җанланып китте. Сәнгать мәктәпләрендә курай класслары ачылды, талантлы гына укытучылар, остазлар күренә башлады. Халык музыка уен коралларында уйнаучылар өчен район, шәһәр, республика конкурслары үткәрелә. Өметле яшьләребез бар. Әмма башкару осталыгы әлегә тиешле дәрәҗәдә түгел. Халыкара һәм Бөтенроссия конкурсларында катнашып, бүләкле урын алырдай бер генә һөнәри курайчыбыз да юк. Бу бик кызганыч, әлбәттә.

Фидакарь курайчы осталарыбыздан Исмәгыйль Мусин XX йөз урталарында Казанда яшәп иҗат итә, үз чорында татар кураен пропагандалауга аеруча зур өлеш кертә. Ул, үзлегеннән өйрәнеп, татар курае турында искиткеч зур мәгълүмат туплый. Фәнни хезмәтләре, мәкаләләре матбугат битләрендә басыла. Әмма аның эшчәнлеге дәүләт

җитәкчеләрендә теләктәшлек тапмый. Төрле зурлыктагы курайларда (бигрәк тә алты тишемле җиз курайда) башкарган дистәләгән язмалары Татарстан радиосы фондында саклана. 1990 елдан Казанда курайчыларның Исмәгыйль Мусин исемендәге конкурсы булдырылды һәм әлегәчә ике ел саен даими үткәрелеп килә.

Ифрат Хисамов

Танылган композитор, халык музыка уен коралларын ясау остасы, талантлы остаз Ифрат Хисамов 1930-2000 нче елларда яшәде һәм гомерен тулысынча татар кураена багышлады. Курайга иң беренче тапкыр җиденче тишемне ул тиште, 1983 елда, курай ясау һәм анда уйнарга өйрәнү өчен, беренчеләрдән булып, кулланма китап чыгарды. Татарстан Республикасының һәр районындагы авылларда булып, йөзләгән курайчылар, кубызчылар ансамбльләре төзеп, меңләгән яшьләрне уйнарга өйрәткән һәм аларны дистәләрчә еллар дәвамында уен кораллары белән берүзе тәэмин итеп торган фидакарь остаз Исмәгыйль Мусинның да, Ифрат Хисамовның да татар кураен пропагандалауга керткән өлешен без әле, бәлки, соңрак аңларбыз да... Алар – татарны курайлы, кубызлы иткән шәхесләр. Милләтнең чиксез зур рәхмәте булсын аларга!

Аллага шөкер, татар дөньясында курай ясау эше бүген дә тукталып калмады. Бу эшне искиткеч талантлы егетләребез дәвам итә. Шуларның берсе – Казанда яшәүче оста Рафаэль Гайзетдинов. Рафаэль курай ясау эшенә 2000 нче елларның башында тотына. Аңарчы булган курайлардан аермалы рәвештә, ул ясаган курайларның тавыш югарылыгы бик төгәл, тышкы кыяфәтләре заманча матур, уйнарга уңайлы. Ул курайны һәр тональлеккә туры китереп эшли белә, күп эзләнә.

ҖИЗ КУРАЙ

Җиз курай – үзенең кыска гына гомере эчендә татар тормышында матур хатирәләр, мәңге онытылмас моң калдырган уен коралы.

Әлеге курайларны, исеменә карамастан, җиздән кала, тимер калайдан да тимерчеләр, көмешче һөнәрчеләр ясаган. Аның озынлыгы якынча 400-420 мм. Ул конус сыман итеп эшләнелгән, баш-башының диаметры 15-25 мм. (Тональлеккә карап, үлчәмнәр үзгәрә). Әле мин хәтерләгән җитмешенче елларда да җиз курайда уйнаучылар очрый иде. Җиз курайның тавышы ягымлы, тембры йомшак, шуңа да аңарда халкыбызның озын, моңлы көйләре матур яңгырый. Гадәттә, аларны алты тишемле итеп һәм диатоник лад аралыгына көйләп ясаганнар.

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

Дәвамы бар ■

Сүзләр иленә сәяхәт*

(Лингвистик хикәятләр)

Гәрәй Рәхим

Миңа бервакыт ерак таулар арасындагы «Сүзләр» мәгарәсенә барып чыгарга туры килде. Мәгарәнең эче, тау куышында булуга карамастан, якты иде. Бара торгач, каршымда киң сахра пәйда булды. Шунда миңа кемдер: «Сүзләр иле шушы инде», – дип хәбәр итте.

Бу гаҗәеп ил иде. Анда бар нәрсә бездәге шикелле үк – агачлар, таулар, чәчәкләр, болытлар, өйләр, өстәлләр, урындыклар... Ләкин бу илнең гаҗәеп ягы шунда: андагы һәрнәрсә... бары тик сүзләрдән генә тора. Мәсәлән, күк йөзеннән узып баручы болытлар «болыт» дигән сүздән гыйбарәт. Әнә, бер «ак болыт» узып китте, әнә, офыкта бер «кара болыт» тора. Шул мизгелдә күз алдымнан гына «чыпчык» дигән бер сүз очып узды. Шунда ук бу сүзләрнең килеп чыгышы да язылган. Әйтик, чыпчыкка аның «чырык-чырык» яки «чыек-чыек» дип чырылдавыннан алып исем кушканнар икән.

Аннары мин үсеп утырган бер агач янына килдем. Аның калын кәүсәсе «кәүсә» дигән сүздән иде. Агачның ботаклары урынына нибары «ботак» дип язылган. Арада «юан ботак», «нәзек ботак», «корган ботак» дигәннәре дә бар. Яфракларның һәрберсе «яфрак» дигән сүздән тора. «Яшел яфрак»лар бик тә күп, ләкин «кызгылт яфрак», «сары яфрак», «аксыл-яшел яфрак»лар да бар. Күреп алуга, Сүзләр иле кешеләре, мине кунак итү өчен, шушы сүзләрдән «үскән» агач төбенә табын кора башладылар. Аларның

*Журнал варианты.

өстәлләре искиткеч иде. Өстәл өсте «өстәл өсте» дигән сүздән гыйбарәт, өстәл аяклары урынына «өстәл аягы» дигән сүзләр генә. Шуннан Сүзләр иле кешеләре мине сыйлар өчен төрле-төрле ризыклар чыгара башлады. Ни генә тезмәде алар өстәлгә! Ләкин рызыкларның һәрберсе сүздән генә тора иде: «бәлеш», «чәкчәк», «ит шулпасы», «кара уылдык», «балык», «бәрәңге»...

Шуннан соң мин аларга Сүзләр илен күреп йөрисем килгәнне әйттем. Ул кешеләр, ризалык биреп: «Телбизәр!.. Телбизәр!..» – дип кычкыра башлады. Аларның кычкырулары да гаҗәеп иде: тавыш ишетелми, ә һәркемнең авызыннан төрле якка «Телбизәр» дигән сүз чыгып оча.

Шушы шаккатыргыч күренешне карап торганда, каршыдагы сүз-агачлар арасыннан 10-15 яшьләрдәге бер малай йөгереп чыкты. Аның кыяфәте шундый сөйкемле, мөлаем, матур һәм, шул ук вакытта, бик тә... үзенчәлекле иде. Бу әлеге Телбизәр дигән малай булып чыкты. Телбизәрнең бөтен гәүдәсе сүздән генә тора. Аның әгъзалары бик тә кызык төзелгән. Мәсәлән, аягы урынына – «аяк», кулы урынына – «кул», күзе урынына «күз» дигән сүз генә...

Безне таныштырдылар һәм Сүзләр иленә сәяхәтем вакытында аның мине озатып йөриячәген әйттеләр. Алар Телбизәрне бик тә мактадылар: уңган, зирәк, күп белә торган малай, диделәр. Озакламый мин моңа үзем дә ышандым. Телбизәр миңа Сүзләр илендә шулкадәр күп яңалык сөйләде ки, мин аларны көчкә-көчкә генә язып барырга өлгердем. Сүзләр иленнән кайткач, анда теркәп барган язуларны карап утырдым һәм күргән-белгәннәремне аерым хикәятләр итеп язып калдырырга ниятләдем. Сүзләр иленнән алып кайткан язмалардан тыш, әле миңа тагын киштә-киштә сүзлекләр актарырга, төрле илләр, халыклар, милләтләр тарихы буенча том-том китаплар укырга, татар, урыс һәм башка халык галимнәренең татар һәм башка төрки телләргә багышланган бик күп хезмәтләрен, мәкаләләрен күздән кичерергә, Телбизәр шикелле үк матур итеп сөйли белгән күп кешеләр белән очрашып сөйләшергә, кайбер урыннарда үземнең язучылык һәм лингвистик хыялларымны эшкә җигәргә туры килде.

Хикәятләрне язганда мин күп уйландым, үземчә кызыклы гына күренешләргә төшендем. Мәсәлән, сүзләр бер милләт телендә туып, шул милләткә генә хезмәт итмиләр, үз мәгънәсендә көенчә йә булмаса төп мәгънәләрен танып булмас дәрәҗәдә үзгәртеп, күрше халыклар, ул гына да түгел, әллә кайлардагы ерак халыклар телләренә барып керәләр, тора-бара аларның үз сүзләренә үк әверелеп китәләр икән. Безгә инде Европа телләреннән – урыс теленә, урыс теле аша безнең туган телебезгә килеп кергән бик күп халыкара сүзләр (демократия, политика, партия) һәм татар теленә кабул ителгән гарәп-фарсы яки Көнчыгыш халыклары сүзләре (китап, дәфтәр, җәмгыять, сыйныф) бик табигый булып тоела...

Ниһаять, күп хезмәт куйганнан соң, менә шушы хикәятләр дөньяга килде. Алар, әйткәнемчә, бик акрынлык белән, сүзләп, җөмләләп җыелды. Әмма әле шуның белән эш бетте, дип уйламыйм. Киләчәк иҗади юлымда мине Сүзләр иленә яңадан-яңа сәяхәтләр – димәк, яңадан-яңа хикәятләр көтә.

***

Сүзләр илендә акча, гомумән, юк, анда бернәрсә дә сатылмый. Бу илдә бөтен нәрсә сүзләр белән генә үлчәнә. Шулай да, Телбизәр акчага мөнәсәбәте булган татарча «тәңкә», «тиен», «калта» (акча янчыгы), урысча «деньги», «гривенник», «алтынник», монголча «мөңгө» һәм «төгрөк» (акча берәмлекләре) дигән сүзләргә тукталып китмичә түзә алмый...

Беренче чиратта, татар телендәге «акча» дигән сүзнең үзенең үк бүген кулланы-

лышта йөри торган кәгазь, алтын, бакыр акчалар белән бернинди дә уртаклыгы юк икәнен әйтеп китәргә кирәк. Чөнки акча дигән сүз ул теләсә нинди *ак әйбергә* карата әйтелә ала. «Акча» сүзе «ак» дигән сыйфатка *-ча* дигән ясагыч кушымча тагылудан гына килеп чыккан: *ак + ча,* ягъни *ак әйбер.*

Шулай да, «акча» сүзенең көмеш тәңкәләр белән турыдан-туры уртаклыгы бар. Чөнки көмеш, чыннан да, ак төстә. Моннан: «акча» дигән сүз нәкъ менә әйләнештә иң актив рәвештә көмеш тәңкәләр йөргән чакта килеп чыккан, дигән фикер туа.

Гәрчә ак төс турында галимнәр арасында үзгә бер фикер дә йөри. Эш шунда ки, хәзерге татар теленә тарихи яктан шактый тәэсире булган борынгы хәзәр телендә ак төсләр урынына безнең бүгенге телдәге «сары» сүзе дә кулланылган. Хәзәрләр үзләренең башкалаларын *Саркел*, ягъни *Сарыгил* (сары + ил) дип атаганнар. Борынгы төрки халыкларда үзләренең башкалаларын «Ак ил», «Ак кала», ә хан яши торган урынны «Ак йорт» дип атау гадәте булган. Бәс, хәзәрләр *ак* төсне дә *сары* (борынгыча әйтелеше – *сарыг*) дип атаган булгач, «Саркел» сүзе бүгенгечә «Ак ил» яки «Ак йорт» дигәнне аңлата булып чыга. Моны Саркел каласының урысчага тәрҗемә ителеше дә раслый. Урыслар Саркел каласын *Беловежск (Белая вежа)* дип атыйлар. «Белая вежа»ның татарчага тәрҗемәсе нәкъ менә «Ак йорт» дигән сүз була да инде.

Элеккеге *сары* сүзенең ак төскә карата да кулланылуын раслый торган тагын бер мисал бар: борынгы төркилекне яхшы саклаган һәм хәзәрләр белән уртаклыгы булган бүгенге чуаш телендә ак төс «сары» дип атала.

Ә акча мәсьәләсенә килгәндә, киресенчә, алтын тәңкәләр (гәрчә алар сары төстә булса да) «акча» дип атала биргән. Шулай итеп, телдә метаморфоза килеп чыккан – ак әйберләр сары дип аталып киткән (Саркел), ә сары әйбер (алтын тәңкә), киресенчә, *ак(ча)* дип тел әйләнешенә кергән. Соңрак бу сүз татарга бик тә ошап киткән, ахрысы: тарихи шартларда әллә ниткән төсләргә кереп бетсә дә (кызыл, зәңгәр, яшел, көрән һ.б.), без аны һаман, шул ак төскә бәйле рәвештә, «акча» дип калдырганбыз.

Урысларның акча берәмлегенә карата әйтелә торган «алтынник» дигән сүзе безнең «алтын»нан килеп чыккан, моны күрүе кыен түгел.

Ә менә татарларда вак акчага карата әйтелә торган «тиен» сүзенең бүген кулланылышта йөри торган алтын акча белән дә, көмеш, бакыр, кәгазь акча белән дә, гомумән, бернинди төр акча белән дә бер тиенлек уртаклыгы да юк. «Тиен» сүзе турыдан-туры үзенең әйтелеше буенча игезәк булган агачтан агачка сикереп йөрүче матур җәнлеккә барып тоташа. Бу сүзләр, тышкы кыяфәтләре белән генә түгел, килеп чыгышлары белән дә бертуган. Эш шунда ки, бик борынгы заманнарда, әле акча уйлап табылмаган чакларда, төрле халыкларда акча урынына төрле кыйммәтле әйберләр, предметлар йөргән. Җылы яклардагы диңгез буйларында яшәүче халыклар төрле кабырчыкларны, диңгез мәрҗәннәрен акча урынына файдаланганнар. Таулы илләрдә кыйммәтле ташлар, кыйммәтле агачларны акча итеп кулланганнар.

Инде безнең «тиен»гә әйләнеп кайтсак, эш шунда ки, борынгы бабаларыбыз сатуалу эшендә кыйммәтле саналган тиен тиресеннән файдаланган. Тиен тиресе берәмберәм дә, бәйләм-бәйләм итеп тә кулланылган. Бер тире – бер тиен дип аталган, бәйләмдә ике тире булса, ул – ике тиен булган, өч булса – өч... Металл акчалар сугарга өйрәнгәч тә татар бер ияләнгән «тиен» сүзен ташламаган, шул рәвешле, бу сүз бүгенге көнгәчә килеп җиткән.

Алтын, көмеш һәм бакыр акчалар тышкы кыяфәте белән һәр чорда һәм һәр халыкта диярлек түгәрәк булган. Монголлар *түгәрәк* дигән сүзне, үзләренчә аз гына үзгәртеп, «төгрөк» дигәннәр дә, аны акча исеме итеп файдалана башлаганнар.

Борынгы заманнарда акча беркайчан да үзгәрми торган кыйммәтле, мәңгелек әйбер

дип исәпләнгән. Аның бозылмый, тутыкмый торган металлардан (алтын, көмеш, бакыр) ясалуы да бик озак сакланырга, мәңгелек булырга тиешлегенә ишарә ясый. Монголлар исә, акчаны мәңгелекнең үзе белән чагыштырып, аны «мөңгө» («мәңге» сүзенең җиңелчә үзгәртелеше) дип тә атаганнар. Бүгенге көндә *төгрөк* – Монголиядә төп акча берәмлеге, ул 100 *мөңгөгә* тигез.

Әйләнештә бары тик металл тәңкәләр генә йөргән заманнарда урыслар татарның «тәңкә» сүзен, үз телләрендәге әйтелешкә авыштырып, «деньги» дигәнәр дә, аны, гомумән, акча атамасы итеп файдалана башлаганнар.

«Гривенник» сүзе исә безнең чулпы белән бер мәгънәгә барып тоташа. Билгеле булганча, урысларның «грива» дигән сүзе «ат ялы»н аңлата. Борынгы заманнарда бу сүз марҗаларның чәч толымнарына карата да әйтелгән. Төрки халыклар белән аралашып яшәгәнгә күрә, алар да, татар хатын-кызлары кебек, толымнарына тәңкә такканнар. Урыслар бу тәңкәләрне – «гривна», татарлар «чулпы» (чылт-чылт итеп чылтыраганга күрә) дип йөрткәннәр. Гадәттә, чулпылар әйләнештә йөргән металл тәңкәләрдән ясалган. Марҗалар чулпы-гривналарын ун тиенлек тәңкәләрдән ясарга яраткан. Вакытлар үтү белән, урысларда «гривенник» ун тиен күләмендәге акча исеме булып киткән.

Инде турыдан-туры акчага бәйләнеше булган һәм татар теленнән урыска күчкән тагын бер сүзне искә төшереп үтик. Борынгы заманнарда татарлар күннән ясалган акча янчыгын «калта» дип йөрткән. Диалектларда бу сүз әле дә очраштыра. Минем, мәсәлән, балта осталары арасында: «Балтаңа эш булмаса, калтаңа да эш булмас», – дигән сүзне ишеткәнем бар. Кенәз Иван I Даниловичны әлегәчә ешрак Иван Калита дип йөртәләр. Бу кенәз акчага бик хирыс кеше булган, имеш, акчаны үлеп яраткан. Һаман үз кесәсен кайгырткан өчен, татарлар аңа «акча капчыгы», ягъни «Калта» дигән кушамат такканнар.

Шулай итеп, дөнья халыклары арасында акчаның үзе генә түгел, ә аның төрле аталышлары да бик актив рәвештә сәяхәттә йөри. Чын мәгънәсендә хәрәкәтчән акчалар.

Ахыры киләсе санда ■

ЧЕЛЛӘ, ЧИЛӘК ҺӘМ ЧЕЛТӘР

Рәис Сәфәров

Җәйге челлә була, кышкы челлә була. Җәйге челлә 25 июньдә башланып 5 августка кадәр дәвам итә. Бу ара – җәй фасылының нәкъ уртасы. Ул кояш календаре буенча төрки телләрдә, шул исәптән безнең телдә дә Әсәд (арыслан) ае дип атала. Әлеге Әсәд ай – елның иң коры, иң эссе чагы: кояш баш өстендә тора, күләгәләр өч чабатадан да озын булмый, тургайлар күккә күз күренмәслек биеклеккә менеп сайрыйлар, кигәвеннәр котырына – мал көтүләре, эсседән әлсерәп, кигәвеннәр талавыннан котылырга теләп, сыртлары күмелгәнче суга кереп кача. Бу – авыл җирендә. Ә шәһәрдә халык елга

буйларында эссе комда кызына, су керә. Эш урыннарында, бүлмәләрдә вентиляторлар, кондиционерлар, бертуктаусыз выжылдап, һаваны җилләсләтәләр... Бу – җәйге чиллә. «Чиллә»нең кышкысы да бар. Анысы 25 нче декабрьдән башлана һәм 5 нче февральгәчә дәвам итә. Кояш календаре буенча бу вакыт Дәлү ае дип атала. Аның битләрне чеметтерә, колакларны өшетә, төкерек җиргә төшеп өлгерми бозга әйләнә торган ачы салкын зәмһәрир көннәре гыйнварның урталарына туры килә. «Яратырга ярый кышны, Вәләкин зәмһәррире бар», – дигән Тукай да. Кыскасы, җәйге чилләнең дә, кышкысының да табигате, «холыклары» безгә яхшы таныш. Ә менә бу вакытлар, ягъни җәй һәм кыш фасылларының урталары ни өчен чиллә дип аталган? Нәрсә дигән сүз ул, аның эчке мәгънәсе нидән гыйбарәт? Монысын әле күпләр белмидер. **«Чиллә»** сүзенең килеп чыгышын ачыклау өчен алдарак әйтелеп үтелгән вакыт араларын, ягъни 25 нче июньнән 5 нче августка һәм 25 декабрьдән 5 февральгә кадәрге көннәрнең санын исәпләп карыйк. Әлеге сан нәкъ 40ка тиң булыр. 40 саны фарысча «чил» дип атала. Бу «чил»гә «ли» кушымчасы ялгасак, «чилли» сүзе ясала, анысы исә шул ук фарсыча «кырыклы» дигән сүз була. Менә шул «чилли» сүзе безнең татар теленә кабул ителеп, бераз фонетик үзгәреш кичереп, **«чиллә»** яңгырашын алган. Шулай итеп, **«чиллә»** җәй һәм кыш уртасындагы кырык көн, кырыгы, кырыклы дигән мәгънәне белдерә. Сүз уңаеннан шунсын да әйтеп үтик: төрки халыклар яшәгән, ләкин табигате безнекенә охшамаган җирләрдә (мәсәлән, Төркиядә, Кавказда, Урта Азиядә һ.б.) чиллә булмый һәм бу **«чиллә»** сүзе бездәге мәгънәдә кулланылмый, әмма **«кырык көнле», «кырыклы», «кырыгы»** шикелле төп, беренчел мәгънәне саклап кала. Мисал өчен үзбәкләрдә **«чилләси чикъмәгән болә»** – кырыгы тулмаган бала, **«чилләли келин», «чилләли хотин»** – кияүгә чыкканына, бала тапканына кырык көн тулмаган килен, хатын һ.б.

Шулай итеп, **«чил»** (кырык) саны безнең телебезгә шул **«чил»** килеш кергән. Тик фонетик яктан бераз үзгәртелеп, **«чел», «чыл»** вариантларында, фарсыдан кергән ике компонентлы алынма-атамаларда үзенең беренчел асыл мәгънәсендә йөри. Менә берничә мисал: челтәр сүзе – **«чел»** әлеге **«кырык»,** ә икенче компоненты **«тәр»** фарсыча **«тар»** (җеп, кыл) сүзләреннән ясалган. Ягъни ул бик күп, кырыкмаса-кырык җептән, кылдан үрелгән әйбер дигәнне аңлата. **Чылбыр.** Бу сүздәге икенче компонент **«быр»** фарсыча **«вир»** – алка, боҗра дигән сүз. Димәк, **«чылбыр»** фарсыча **«чилвир»** – бик күп, кырыкмаса-кырык боҗрадан, алкадан торган, бер-берсенә ялгап, тагып эшләнгән бау. **«Чәлпәрәмә килү».** Фарсыча **«чилпарә» – «чил»** кырык һәм «парә» – кисәк, бүлемтә, ярчык, өлеш мәгънәсен белдергән компонентлардан тора. Шулай итеп, **«чәлпәрәмә килде»** дигәнне бик күп, кырыкмаса-кырык кисәкләргә ватылды, уалды дип аңларга кирәк. Фарсыча әнә шул **«парә»** сүзе кушылган **«йөрәгемнең парәсе»** дигән тәкъбир дә, йөрәгемнең бер кисәге, аерылгысыз бер өлеше дигәнгә туры килә. Чиләк сүзендәге икенче компонент **«әк»** фарсыча **«як» – «бер»** санының беркадәр үзгәртелеп әйтелеше. Димәк, кырык һәм **«бер»** мәгънәләрен белдергән ике компоненттан торган чиләк, кырыктан бер өлешне сыйдырган савыт булып чыга.

Менә бит ул, әллә нәрсәләр бар сүзләр дөньясына кереп китсәң...

Журналга ***Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет)*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2019

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

ӘБРАР КӘРИМУЛЛИН ТУПЛАНМАСЫ

Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин (1925-2000) – танылган татар галиме, китап белгече, библиограф, тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Кол Гали исемендәге Халыкара бүләк иясе.

Әбрар Кәримуллин 1925 елның 29 маенда хәзерге Татарстанның Саба районына керә торган Чәбия-Чүрчи авылында туган. Бөек Ватан сугышында катнашкан. I дәрәҗә «Ватан сугышы» ордены, ике «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем алганнан соң, 1953-1964 елларда ул әлеге университетның Фәнни китапханәсендә директор урынбасары, 1964 елдан башлап СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр вазыйфасын башкара. Ул, татар филологиясендә беренчеләрдән булып, татар китап белемен өйрәнүгә нигез сала. Матбугатта басылган җиде йөзгә якын фәнни һәм публицистик язмаларында төрле темаларны күтәрә: милли китап тарихы, татар халкының килеп чыгышы, аның дөньяда токкан урыны, татар әдәбиятының Шәрык һәм Аурупа әдәбияты белән бәйләнешләре, тел тарихы, археография, этнография, топонимика һ.б.

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

Ул Татарстан тарихы, татар тел белеме, татар әдәбияты тарихы хакында күп санлы фәнни хезмәтләр, монографияләр язды. Галим һәм әдипләрнең шәхси библиографияләрен төзеде, шәрык кулъязмаларын барлап, аларның фәнни тасвирламасын эшләде. Аның фидакарьлеге һәм тырышлыгы белән татар басма сүзенең тарихы күтәрелде, татар филологиясе тарихын өйрәнүгә яңа юнәлешләр билгеләнде, милләтнең иҗтимагый фикер тарихы күзгә күренеп баетылды.

Галимнең хезмәтләре үз республикабызда, Россиядә генә түгел, якын һәм ерак чит илләрдә дә таралды. АКШ, Англия, Франция, Алмания, Төркия, Мисыр, Япония, Канада, Венгрия, Польша кебек илләрдә яшәп иҗат итүче тюрколог галимнәр арасында ул бик популяр, олы хөрмәткә лаек шәхес иде. Күренекле галим буларак аны АКШ, Канада, Англия һәм Төркиянең фәнни оешмалары халыкара конференцияләргә еш чакырдылар. Анда ул татар халкының тарихы, мәдәнияте һәм әдәбияты хакында хисчән дә, фәнни дә чыгышлар ясады.

Теге яки бу халыкта басма китап барлыкка килү өчен, халыкның әлифбасы, халык арасында укый-яза белүнең шактый дәрәҗәдә таралуы, белемгә булган ихтыяҗның үскән булуы, шактый дәрәҗәдә әдәби, фольклор мирасы булуы кирәк.

Әбрар Кәримуллин

Академик Әбрар Кәримуллин, тынгысыз шәхес буларак, фәнни кысаларга гына сыеша алмыйча, республикада барган иҗтимагый-сәяси вакыйгаларның уртасында кайнады. Газета-журналларда тирән мәгънәле мәкалә-язмаларын бастырды, радио-телевидение аша халыкка еш мөрәҗәгать итте. Аның теләктәш аудиториясе студентлар, галимнәр, гади халык вәкилләре булды; татар теле графикасы язмышы, рухи-мәдәни мирасны саклау, Татарстанның суверенитетын яклау мәсьәләләренә караган ялкынлы чыгышлары киң җәмәгатьчелектә яклау таба, битараф булмаган һәммә кешене ул үтемле сүзе белән халык бәгыренә төбәлдерә белә иде. Хәзерге көндә дә аның фидаи сүз кодрәте үткенлеген җуймаган, бәрәкәтле кайтавазы күңелләрдә яңгырап тора.

Танылган галим, кабатланмас шәхес, татар халкының асыл ир-егете Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 2000 елның 18 сентябрендә 75 яшендә дөнья куйды.

Ул 1991 елдан Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә фәнни киңәшче булып эшләде. Аның җитәкчелегендә кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1722-1917 еллардагы татар басма китапларының җыелма каталогы»н төзү баш-

ланды. Моның фәнни һәм гамәли кыйммәтен бәһаләп бетерү мөмкин түгел. Татарстанның, Россиянең, төрки халыклы илләрнең, Аурупа һәм Американың зур, бай китапханәләрендә сакланган татар иске басма китапларын күтәрү, ачыклау, бөртекләп барлау иде бу – Җыелма каталогны төзү һәм бастырып чыгару. Милли китапханә хезмәткәрләре Әбрар Кәримуллин билгеләгән максат һәм алымнар белән хәзерге көндә дә әлеге изге эшне дәвам итәләр.

Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә академик Әбрар Кәримуллинның үз кулы белән тапшырган архивы, дүрт мең исемдәге китап мирасы һәм татар, башкорт, рус, төрек, инглиз телләрендә чыккан журналлар саклана. Монда – фәнни язмалар, монографияләр, сүзлекләр, белешмә китаплар, тел, әдәбият-сәнгать тарихына караган хезмәтләр урын алган. Тупланмада татар халкының танылган мәгърифәтчеләре Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләре, шулай ук В.Бартольд, И.Крачковский, В.Ключевский, Н.Гумилёв, галим үзе аралашкан замандашлары – М.Зәкиев, М.Госманов, Ф.Гарипова, Я.Абдуллин, Р.Әмирханов, Р.Фәхретдинов китаплары бар.

Шәрык поэзиясе җәүһәрләре (Г.Хәйям, Низами, Нәвои) белән беррәттән, татар әдәбиятының үлемсез үрнәкләре – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, Мөхәммәдьяр, Г.Утыз Имәни, Г.Кандалый, Г.Тукай, Г.Исхакый, Н.Исәнбәт һәм башкаларның җыентыклары тупланмада күренекле урынны биләп тора.

Әбрар Кәримуллинның үз хезмәтләре, китаплары, фәнни кульъязмалары да – галимнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнер өчен бәһасез кадерле чыганаклар. Шәхси китапханәсенә кергән һәр җыентыкны Ә.Кәримуллин, күз нурын түгеп, җентекләп укыган, өйрәнгән, үз хезмәтләрен язганда файдаланган. Китап битләре читендә үз фикерен белдереп куйган тамгалар, өзек-өзек фикерләр шул хакта искәртә. Күп хезмәтләргә ул битараф калмаган, рецензияләр язган. Авторлары култамгаларын куеп, теләкләрен язып Әбрар Кәримуллинга бүләк иткән китаплар да аз түгел биредә.

Академикның вафатыннан соң хатыны К.Г.Батыева, кульъязмалар, көндәлекләр, хатлар, фоторәсемнәр тапшырып, бу тупланманы тагын да баетты. Болар бар да – галимнең олуг мәгънәгә ия тормыш һәм иҗат гомерендә кул җылысын, йөрәк тибешен, күз нурын сеңдереп калган ядкәр-шаһитлар... ■

Безнең мирас №2 февраль 2019

Хотня авылындагы намаз йорты һәм кәшәнә

2016 елның 9 сентябрендә Арча районының Хотня авылындагы Изгеләр чишмәсе янында намаз йорты, ә Петропавел чиркәве янәшәсендә кәшәнә (часовня) ачылды. «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры **Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин** һәм аның җитәкчелегендәге егетләрнең матди ярдәме, игелекле хезмәте нәтиҗәсендә, хәзер бирегә елның теләсә кайсы вакытында килгән сәяхәтчеләр өчен гыйбадәт кылу мөмкинлеге бар. ■

ГЫЙНВАР

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 4 гыйнвар көнне, озакка сузылган каты авырудан соң, Татарстан Республикасының халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2003) Мөсәгыйт Хәбибуллин вафат булды. Әдипнең җәсәде 5 гыйнварда Самосырово-дагы татар зиратында җирләнде.

● 8 гыйнварда СССРның классик көрәш буенча спорт остасы, Россиянең атказанган тренеры, грек-рим көрәше буенча дөнья чемпионы, татар һәм билбау көрәшләре вәкилләренә дә яхшы таныш булган Рәшит Хәбибрахманов 66 нчы яшендә вафат булды. Көрәшченең җәсәде Чаллыда җир куенына иңдерелде.

● 9 гыйнварда классик шагыйребез Фатих Кәримнең башкалабызда яшәгән иң соңгы өе – Казанның Миславский урамында урнашкан 8 нче йорт янында шагыйрьне искә алу чарасы булып узды. Шагыйрь фронтка шушы йорттан китә һәм кире әйләнеп кайтмый... Әлеге йорт диварына, берничә ел элек, шагыйрь истәлегенә таштакта куелган иде.

● 10 гыйнварда Татарстан Язучылар берлегендә балалар әдәбияты, шигърият, проза һәм тәнкыйть остаханәләренең берләшкән утырышы булды. Анда Татарстан Язучылар берлегенең идарә утырышына Республиканың М.Җәлил исемендәге бүләгенә һәм Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ, Җ.Вәлиди, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләренә кандидатлар тәкъдим ителде.

● 11 гыйнварда Татарстан Язучылар берлегендә идарәнең чираттагы утырышы булды. Анда каләм әһеле Марс Яһудин Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды. Гомер буе М.Җәлил иҗатын һәм эшчәнлеген өйрәнгән, пропагандалаган, герой-шагыйрь турында 40лап хезмәт язып бастырган галим һәм шагыйрь Хәнәфи Бәдигый, яшь шагыйрь Булат Ибраһимов республиканың М.Җәлил исемендәге премиясенә тәкъдим ителде.

● 12 гыйнварда «Коръән нуры» хәйрия фонды һәм «Идел» журналы оештырган хикәяләр бәйгесенә йомгак ясалды. Бәйгедә Әтнә районында яшәп иҗат итүче шагыйрә Гөлүсә Батталова җиңү яулады. «Безнең мирас»ның даими авторы Айзирәк Гәрәева һәм шагыйрә Гөлнур Корбанова да призлы урыннарга лаек булды. Котлыйбыз!

● 15 гыйнварда Мари Республикасының Бәрәңге районында район җитәкчеләре һәм дин әһелләре белән очрашулар булып үтте.

● 16 гыйнварда Әлмәттә һәм Кичүчат авылында күренекле мәгърифәтче, дин эшлеклесе, мөхәррир Ризаэддин Фәхреддиннең туууына 160 ел тулу уңаеннан зур чаралар булып узды.

● 16 гыйнварда татар халкының мәшһүр җырчысы, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Илһам Шакиров вафат булды.

● 18 гыйнварда ТР Милли китапханәсендә күренекле әдип Нурихан Фәттахның ике телдә чыккан «Сызгыра торган уклар» китаплары укучыларга тәкъдим ителде.



● 21 гыйнварда Казанда Бөтендөнья татар конгрессы бинасында, бертөркем татар зыялылары катнашында, татар халкының киләчәк язмышына багышланган түгәрәк өстәл уткәрелде. Аны Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев алып барды.

● 22 гыйнварда Азнакай районында күренекле шагыйрь Илдус Гыйләҗевне искә алу чаралары булып узды. Туйкә авылы клуб бинасына шагыйрь истәлегенә элмә такта куелды. Чараларда Казаннан һәм якын-тирә районнардан язучылар һәм шагыйрьләр катнашты.

● 23 гыйнварда Биектау районының 100 еллык мәктәбендә күренекле драматург Хәй

Вахитның туууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булып үтте. ■

Мирасворд

Алтын Урда чорында ханнарның сәяси вассалы, гаскәр башлыгы

Булат Рәфыйковның тарихи романы

Ярым ефәк чуар тукыма

Афзал Шамов повесте

Әйткән сүздә тору, тугрылык (иск.)

Сибгат Хәким поэмасы

Шагыйрьләр ... Әхмәтҗанов, Миңнуллин

... Колый

Борынгы римлыларда император вәкиле, наместник

Борынгы Рим шагыйре

Тәбәнәк, кыска (диал.)

Идел буе Болгары шәһәре

«Кон-...» (Тур Хейердал салы)

Аз санлы төрки халык

Кыпчак ханы

Бер урында даими яшәүче

Ашальчи ... (удмурт шагыйрәсе)

Киләпле җепне йомгакка урaганда кулланылучы җайланма

Яуга чакыру авазы

Европадагы елга

... Гамбәр

Шахматчы ... Галләмова

Латвия каласы

Удмурт (иск.)

XX йөз поляк шагыйре һәм сатиригы

Борынгы грек драматургы

Татарларда язын учак ягу һәм шуның аркылы сикерү йоласы

Икмәк

Кәрт уены

Пальманың бер төре

Кения мәркәзе

Әләк (диал.)



Достоевский, Тютчев

Кәбестә турау, орлык киптерү һ.б. өчен агачтан ясалган тагарак

Гаффарова, Билалова

Җырчы ... Гарифуллина

Мезозой эрасының урта бер геологик чоры

Федерико Гарсиа ...

Рәис Габдулла төзеде.

1 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Султан уңга: көбә, Алиш, Сәяф, әл, Мишкә, поэма, Кадыйр, Дени, имла, Әмир, яри, сонет, «Бова», аболла, мән, Кави, Салахов, «Тәүбә», «Учак», Сәхаб, иде, кари, «Вий».
Өстән аска: Әппәс, бәҗәнәк, Мәдисон, Ха, Байтимеров, Әбрар, шан, най, би, кисәк, өшәләк, Итака, бал, Әсфәндиярова, ым, Лихачев, өйлә, Ади, Ра, Раевский.

Башкалабыз Казандагы Сибгат Хәким урамы

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы /февраль

650 ел элек (1369)

Арал диңгезе белән Җидесу арасындагы биләмәләрне берләштергән Күк Урда дәүләте тәхетенә Ырыс* хан утыра һәм Күк Урда тора-бара тулаем ирекле дәүләт-олыс сыйфатында яши башлый. Әмма ул барыбер әле рәсми рәвештә Алтын Урданың сул канаты санала.

540 ел элек (1479)

Казан ханы Ибраһим вафат була.

155 ел элек (1864)

Шиһабетдин Мәрҗани гарәп телендә төрки Караханилар династиясенә караган «Горфәтел хавакыйн ли-гарфәтел хавакыйн» әсәрен язып, аны Казанда нәшер итә.

110 ел элек (1909)

Бакуда «Мөзаһир» («Ярдәмче») исемле журнал чыга башлый.

95 ел элек (1924)

2-5 февральдә Һади Такташ «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын яза.

75 ел элек (1944)

Икенче Балтыйк буе фронтында «Суворовчы» исемле татарча хәрби газета чыга башлый.

65 ел элек (1954)

12 февральдә Харьков музыкаль комедия театрында Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе куела.

50 ел элек (1969)

«Казан утлары» журналының февраль ае санында Сибгат Хәкимнең «Дуга» поэмасы дөнья күрә.

25 ел элек (1994)

Уфада Татар телле язучылар берлеге оештырыла.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

*Ырыс – борынгы төрки телдә «бәхет» дигәнне аңлаткан.



СОДЕРЖАНИЕ. ФЕВРАЛЬ 2019

Историческое наследие: «Всеобщая история тюркских народов». Х.Габаши**;** «В день празднования пятой годовщины Татарстана»**;** «Изречения Ризаэддина Фахруддина»; «Давайте, сохраним нацию!» Г.Тухфатова.

Татарский мир: «Мы – народ с богатым наследием».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Башкирка». Х.Сарьян; «Растёт интерес к нашей истории». Л.Хамидуллин; «Хозяин птиц». А.Халим.

В глубине памяти: «Афганский дастан». М.Закир; «Легенда солдата Набиуллы»; «До сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Древние татарские национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязев; «Письма с тайной».

Слово – украшение языка: «Путешествие в страну слов (лингвистические рассказы)». Г.Рахим.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Дом богослужения и часовня в деревне Хотня».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. FEBRUARY 2019

Historic heritage: “General history of Turkic people” by Kh. Gabashi; “On the day of celebration of the 5th anniversary of Tatarstan”; “The redes of Rizaiddin Fakhreddin”; “Let´s guard our nation!” by G.Tukhfatova.

Tatar world: “We are a nation with heritage”.

Religious heritage: “Islamic world” by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: “Bashkir girl” by Kh. Saryan; “The interest to our nation is getting increased” by L. Khamidullin; “The owner of noble birds” by A.Khalim.

In the deepest store of memory: “Afgan poem (narrative passage)” by M.Zakir; “The legend of the soldier Nabiullah”; “Still keeping in the memory, still keeping!

Creative heritage: “The ancient Tatar national musical instruments” by R.Gilyazev; “Letters with its secrets”.

Word is a decoration of language: “The voyage to the words’ world (liguistic stories)” by G.Rakhim.

On the guard of the memory: “The National library of the Republic of Tatarstan”; “House of worship and chap in Hotnya village”.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation’s life.

Әнәс Ибраһим улы Тумашев

Әнәс Ибраһим улы Тумашев 1924 елның 25 февралендә Татарстанның Чистай шәһәрендә туа. 1942 елда Казан рәсем сәнгате училищесын, 1953 елда И.Е.Репин исемендәге Ленинград рәсем сәнгате, сынлы сәнгать һәм архитектура институтын тәмамлый. 1961 елдан – СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы. 1975-1989 елларда – ТР Рәссамнар берлеге рәисе. ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1967 ел), Татарстанның халык рәссамы (1974 ел), РСФСРның атказанган рәссамы (1982 ел), Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1985 ел).
2010 елның 12 октябрендә вафат була.

«Гүр-Әмир. Сәмәрканд». 1964. Картон, майлы буяу

«Кама буе. Алмагачлар чәчәк ата ». 1989. Картон, майлы буяу

«Яр буендагы бистә». 1982. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Камил Исхаков – студент.
(Әгъзам Фәйзрахманов «Казанны данлаучы шәхес»).

Бакый Урманче: «Зур эшләргә көч, кабилият, мәхәббәт сизелә үзегездә» (Б.Урманче һәм Ф.Әхмәтова хатлары). Эльмира Шәрифуллина
Мари Илендәге Куян авылы (Бәрәңге районы) тарихы. Фәнил Мусин
Казанны данлаучы шәхес. Әгъзам Фәйзрахманов
Иңнәргә канат куйган еллар. Алсу Хәкимова
Җырлап китте мәңгелеккә. Госман Гомәр

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- ***uslugi.tatarstan.ru*** *сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- ***podpiska.pochta.ru*** *сайты ярдәмендә*

электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*